№ 2 2018

ТУГАРӘК УЕНИ

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ



Җиргә тамган тир –
җәүһәр.

Рифкать Вахитов.
«Чишмә буенда».
Киндер, майлы буяу. 2008 ел.

Татарстанның халык рәссамы Рифкать Вахитов:

«Чын мәгънәсендә яшәү чыганагы булган чишмә – халкыбыз өчен су чыганагы гына түгел, илһам чыганагы да.

Элек-электән чишмәгә атын сугарырга төшкән егетләр чулпыларын чыңлатып суга төшкән кызларны күзләгәннәр, шунда яшерен генә мәхәббәт хатлары тапшырганнар. Чишмә яшьләрнең саф-садә хисләренең беренче шаһиты булган. Яшь киленнәр күңел кичерешләрен чишмә белән бүлешкән – сагыш-моңнарын челтер суларга салып агызган. Шуңа да чишмә образы татар халык авыз иҗатында бик тирән мәгънә алган.

Минем дә күңелемә чишмә шундый серле урын булып кереп калгангадыр, әлеге картина кисәк кенә бөтен тулылыгы белән күз алдыма килде дә басты. Андый картиналарны, күңелдә яшәгәндә, тизрәк язып куясы килә. Монда рәссам өчен гаҗәеп киңлек-мөмкинлек – күңелдәге хисләрне бөтен җителеге белән киндергә төшерергә була. Һәм аны һәркем үз күңел халәтенә карап укыячак».

Җәйге таң хатирәсе

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.

Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;
Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.

Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм япан;
Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан.

Тын гына яткан, ялыккан,төн буенча көн көтеп,
Ялтырап, җәйрәп ята күлләр, сихерле көзге күк.

Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, ләләләр;
Сандугачлардан ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.

Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене
Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;
Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.

№ 2 2018

ТУГӘРӘК УЕН

Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

*«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»*

16+

Гамәлгә куючылар:

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:

Әхмәтҗанов М.И.
Бакиров М.Х.
Вәлиева З.Р.
Вәлиев Р.И.
Гайсин И.З. (Мари Эл)
Деникаева В.А. (Ульян)
Заһидуллина Д.Ф.
Каюмова Э.Р.
Локманов А.Х. (Башкортостан)
Сибагатуллин А.М.
Тукаев М.Р.
Шәрәфиева Р.Г.
Юсупов Ф.Ю.

Директор: **Фәнзилә Җәүһәрева**

Баш мөхәррир: **Илсөяр Иксанова**

Альманахның иҗат төркеме:

Гөлсинә Хәмидуллина
Алсу Тимергалина
Раилә Хәялиева
Мөнирә Кузиева

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Өч айга бер чыга.

Бу санны бизәүдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондындагы, Ә. Бикмөхәммәтова (тышлык), Р. Хәялиева һәм авторларның шәхси архивларындагы фотолар файдаланылды.

Кәгазь форматы 60x90 1/8. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды 24.04.2018 ел. Заказ Е-932.
Тираж 1050 экз.

Редакциянең адресы: 420021, Казан, Тукай урамы, 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин урамы 66/33 йорт.
Телефон: 293-27-99. E-mail: tugarakuen@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар ур., 2.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

КАЗЫНГАН – КАЗНА ТАБАР

4 **Төп йорт**
Раилә Хәялиева
Гарифулла оныклары

7 **Фольклор туган җирдә**
Гөлүзә Хәмзина
Һәр җирнең үз көе, үз биюе...

12 **Малның җаен баккан белер**
Алсу Батталова
Малы барның сые бар

14 **Йолаларыбыз**
Мәхбүбҗамал Акчурина
Кыз егълату

18 *Заһидә Нәбиуллина*
Хатын-кызның күрке – яулык

© «Түгәрәк уен», 2018

22 **Фидакарьләребез**
Гали Рәхим
Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

26 *Илсөяр Иксанова*
Шигъри җанлы абыстай

34 **Кайтаваз**
Нурия Мәннапова
Кадерле ядкарьләр

36 **Хәтер-хатирә**
Сәйфи Кудаш
Казакъ даласында

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

40 *Аяз Гыйләҗев*
Тәрәзәләр

50 **Вакыт көзгесе**
Гөлчәчәк Галимова
Затлы нәсел

52 **Вәгазь-нәсыйхәт**
Мөхәммәт Галләм
Тугры юл

УЕНДА ҖИҢГӘН – ҖЫЕНДА ҖИҢӘР

54 **Фольклор коллективларына ярдәмгә**
Гөлчәчәк Галимова
«Май уны»

58 **Без, без, без идек...**
Зәбәрҗәт
«Ябалак»та кунакта

62 **Өй күрке – аш**
Раилә Сабирова
Юка

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Гарифулла оныклары

Әллә тылсымлы инде бу дәү әтиләр өендә саклана торган тальян гармун?! Кечкенә Рөстәм, дәү әниләренә килеп кергән саен, гел тальян янына тәпили башлый. Шул тальянны шәп итеп тарткалыйсы, өлкәннәрне шаккатырасы килә аның. Әнисе генә һаман, улым, бигрәк кадерле тальян бит бу, аңардан кырыйгарак кит әле, мин сиңа башкасын бирәм, дип зуррак гармун бирергә тырыша. Ярамый имеш! Өч яшен тутырып килгән Рөстәмгә тальян кирәк шул, тальян тарта аны!..

Бүгенге көндә Кайбыч районы Борындык авылындагы төп йортта гомер кичерүче Рамил абый белән Рәмзия апа Гарифуллиннар өчен тальян чыннан да бик кадерле ядкарь шул. Дүртенче буын бабалары Гарифулла рухын саклый бит ул!

1814 елда ук ясалып, бүгенге көнгә кадәр кулдан төшмәгән тальян узган ел «Төп йорт» республика гаилә ансамбльләре фестивалендә дә сәхнә түрендә булды. «Гарифулла оныклары» аның тарихын да сөйләде, тальянга кушылып җырлап-биеп тә күрсәтте. Бию дигәннән, гаилә ансамбле чыгышы вакытында Рамил абыйның җилкенеп-җилкенеп «Ярмәк вагы» көенә «Чабата» биюен башкаруы, аңа кызы Энҗе, кечкенә оныгы Рәфинә, туганнары Зөбәрҗәт апа белән Данис та кушылып китүе иң матур мизгелләрнең берсе булып хәтердә калды.

Күптән түгел без Кайбыч якларында булып, «Төп йорт» фестивалендә өченче дәрәҗәдәге дипломга лаек булган әлеге үрнәк гаилә белән якыннан очрашып-аралашып кайттык.

– Гарифулла бабай – әтиемнең дәү әтисе ул. Аның нәселе ярты Борындык авылына таралып яшәгән данлыклы Хәлит токымына барып тоташа. Хәлит – Гарифулла бабайның бабасы, ягъни, безнең бишенче буын бабабыз була инде. Хәлит нәселе бернәрсәдән курыкмый, кирәк чакта турысын әйтеп сөйләшә торган булуы белән аерылып торган. Шул ук вакытта алар шаян да булганнар, җыр-моң яратканнар, гармунда бик матур уйнаганнар. Безне әле хәзер дә авылда «Хәлитнекеләр» дип йөртәләр, – дип, сүзен гаиләнең ерак тарихыннан башлады Рамил абыйның олы кызы Энҗе. – Гарифулла бабай бик кырыс булган, ялганны яратмаган. Мәкальләр белән, кыска гына әйтеп сөйләшкән ул. Кызганыч, гомере бик озын булмаган шул аның, яшьли дөньядан киткән. Шулай да, Латыйфа әбиебез белән җиде баланы аякка бастырырга өлгергәннәр.

Ә аннан соң, әдәби әсәрләргә генә хас бик кызык тарих дәвам итә...

Гарифулланың беренче хатыны, каты авырудан соң, ике баланы ятим итеп бу дөньядан китеп бара. Яшәргә дә кирәк, балалар кечкенә, алар да әни җылысына сусаган, өйгә дә хатын-кыз кулы җитми. Уйлый-уйлый да, Яшел Үзән районы Мулла Иле авылының затлы нәсел кызы, 19 яшьлек Латыйфа Халитовага өйләнергә була. Латыйфа Борындык авылына

Латыйфа әби.

беренче тапкыр аяк басканда Гарифулланың бер тапкыр өйләнгән, инде ике бала атасы булуын белми шул әле ул. Чаршау артында килен төшкән хөрмәткә май чыжлый, нидер пешә, булышырга кергән күрше хатыннар чыш-пыш килә. Күптән түгел генә әниләрен югалту ачысыннан өзгәләнгән балаларга «хәзер әниегез кайта» дип әйтеп куялар. Латыйфа өйгә кереп бишмәтен элгечкә элеп куюы була, әни дип тилмергән теге ике бала йөгереп чыгып, «Әни кайткан!» дип Латыйфага таба атылалар. Чаршау артындагы хатыннар, балаларның юлына аркылы төшеп, хәлне «төзәтмәкче» була да, әмма Латыйфа барысын да аңларга өлгерә шул инде... Яшь булса да, Латыйфа төпле кыз була. «Әйдә, Гарифулла, утырып бер дога кылыйк та, мин юлга кузгалырмын, тормышны ялганнан башлап булмый», – ди ул йорт хуҗасына. Һәм киенеп ат чанасына таба атлый. Ул да булмый, артыннан теге ике бала янә йөгереп чыгып: «Әни, син дә безне калдырып китмә инде!» – дип аның аягына сарыла. Балаларны кочаклап елый да, язмышым шулдыр, дип йортта кала Латыйфа. Озакламый Гарифулла белән Латыйфаның Мөнирә исемле кызлары туа. Аннан бер-бер артлы дүрт малай: Галимҗан, Фәргать, Габделрәшит, Равил дөньяга килә.

Күп балалы гаилә гомер буе дус-тату яши. Малайлар өйләнгәч, өй матчасына өч бишек элеп, өч киленнең бергә яшәгән чаклары да була. Гомумән, Борындыкта бер йодрык булып яшиләр алар. Өйләре дә бер урамда, бер-бер артлы гына урнашкан. Вакыт су кебек ага гына. Буын арты буын алмашына. 27 онык дөньяга килә. «Без мәктәптә укыганда һәр класс саен апабыз, абыебыз яки туганнан туганыбыз укый иде. Бер-беребезне яратып, ярдәмләшеп тату үстек», – дип искә ала ул чакларны Латыйфаның бер оныгы Чулпан Камалиева. Оныклар, киленнәр, уллар, туганнар... Боларның барысын да туплап торучы кеше, әлбәттә инде, зирәк Латыйфа дәү әни була. Киленнәр дә аңа җылыша, ә ул акрын гына тормыш җаен җайлый, нәсел ныклыгын кайгырта. Алай гына да түгел, әле авылдашлары да төрле йомыш белән киләләр аңа. Кемдер сәдака китерә, кемгәдер күз тигән... Диндарлыгы өстенә, им-том серләрен дә белгән ул. Балаларны туган җиргә, табигатькә гашыйк итеп үстерә. Исән булса, Латыйфа дәү әнигә 126 яшь тулыр иде. Ул яратып 130 оныгын һәм оныкчыгын сөяр, Борындык үзәннәренә какы, кузгалак җыярга алып төшеп китәр иде... Әнә, оныклары аның турында һәрбер истәлекне мәрҗән кебек тезеп саклый, матур бер хикәят итеп киләсе буынга сөйли. Гарифулла нәселенә менә шундый дәвам биргән дәү әни ул Латыйфа.

«Төп йорт» фестивалендә «Гарифулла оныклары» өченче дәрәҗәдәге дипломга лаек булды.

Ә тальянның тарихы болай. Гарифулла улы Габделрәшиткә бераүләрнең мунча чормасы башында Гарифулла бабайның туганы яратып уйнаган тальян сакланганлыгын әйтәләр. Тальян шактый җимерелгән, сүтелгән була инде. Габделрәшит аны кыйпылчыклап җыеп капчыкка тутыра да, Казан осталарына бирә. Шулай итеп тальянның яңа тормышы башлана. Габделрәшит аны бик кадерләп саклый, бала-чаганы якын да китерми. Шуңа күрә ул бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән дә инде.

Бүген тальянны Габделрәшит улы Рамил сайрата. Борынгы тальян тирәсендә бөтерелүче оныгы Рөстәмне: «Биш яшеңә яңа гармун бүләк итәм!» – дип тынычландыра ул.

Рамил абыйның икенче оныгы Рәфинә «Чабата» биюен отып алган. Алар аны бергәләп гаилә бәйрәмнәрендә бииләр икән.

– Биюгә әвәслек нәселдән килә, – ди Рамил абый. – Аяклары авыртса да, әти дә бик матур биегән минем, әни дә. «Ярмәк вагы» көен телевизордан ишетеп өйрәндем. Хәрәкәтләрен дә. Кечкенә чакта Мөнирә апа Халикова безгә төрле милләт биюләрен биеп күрсәтә иде. Егет чакта да гел биедек, биеми яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм.

– «Төп йорт» фестивалендә буыннар бәйләнешен күрсәтәсебез килде, – ди Энҗе. – Безнең гаилә ансамблендә дүрт буын вәкиле катнашты. Иң өлкәнебез – безнең дәү әниебез, сугыш чоры баласы Рауза Нуретдин кызы булды.

Яшьлек елларында тормыш иптәше Габделрәшит белән кавышып 50 елдан артык матур тормыш кичерәләр. Колхозда хезмәт куялар. Бер ул, өч кызларына гомер бүләк итәләр. Заманында авылдагы бер генә мәҗлес тә, бәйрәм дә алардан башка үтми. Габделрәшит – тальянчы, Рауза – җырчы! Икенче катнашучы – минем әти, Габделрәшитнең дәвамчысы Рамил. Әти һөнәре буенча шофер булса да, безнең өчен ул беренче чиратта, оста тальянчы, гармунчы һәм биюче. Өченчебез – әтиемнең сеңлесе Зөбәрҗәт апабыз. Ул балачактан сәнгатькә гашыйк кеше. Оста гармунчы, тел остасы, рәссам, уңган хуҗабикә, өч кызына ягымлы әни, оныкларына яраткан дәү әни. Дүртенчебез – Габделрәшит белән Раузаның өченче кызлары Дилбәрнең улы Данис Зәйнуллин. Ул балачактан җыр сәнгатенә гашыйк. Белеме буенча музыка укытучысы, бүгенге көндә оста оештыручы, җырчы, күп кенә конкурс-фестивальләр лауреаты. Ике улына үрнәк әти. Бишенче кеше дип үземне атыйм инде. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлап, бүгенге көндә Кайбычта Галия Кайбицкая исемендәге музейда директор вазыйфасын башкарам. Алтынчыбыз – минем кызым Рәфинә. Ул ансамблебезнең иң кечкенә катнашучысы иде.

Бу фестиваль безгә тагы бер зур эш башкарып чыгарга этәргеч бирде әле. Латыйфа әбинең 126 еллыгына багышлап, үзебезнең Борындык авылында бөтен нәселебез катнашында концерт оештырырга булдык. Без бит барыбыз да җыр-биюгә оста. Гармунда уйнаучыларыбыз да күп. Безнең нәселнең тагы бер үрнәк сыйфаты – туганлык җепләрен барлап, саклап тору. Туганлык җепләрен өзмичә киләчәк буыннарга ялгый баруны зур бурычыбыз дип саныйбыз. Киләчәк буыннар да безнең гаилә традицияләрен саклап яшәсеннәр, «Хәлитнекеләр» булудан туктамасыннар иде.

Гарифуллиннар кода-кодагыйлары белән.

Гөлүзә
ХӘМЗИНА

Һәр җирнең үз көе, үз биюе...

Яшьтән үк тормышта үз сукмагын тапкан, үзенә тәгаенләнгән юлдан атлап киткән кешеләр сирәктер, мөгаен. Без, адәм балалары, үз-үзебезне гомер буена эзлибез бугай. Һәм... һич көтелмәгән бер очраклылык сине бөтенләй яңа сукмакка бора да җибәрә. Минем белән дә шулай булды: чит телләр факультетын тәмамлап, мәктәптә 8 ел немец теле укытканнан соң, «Гүзәлем» туй агентлыгы оештырдым. Пермь шәһәрендә «Никах теркәү тантанасы» конкурслары уза башлагач, мин дә кызыксынып барып карадым. Татарча никах теркәү буенча бер генә чыгыш бар иде, анысы да бик чиле-пешле. Шунда минем бөтен күңелем актарылды: безнең халкыбызның туй тантанасы белән бәйле әллә никадәр матур йолалары бар бит! Нигә шуларны күрсәтмәскә! Мин менә болай эшләр идем, тегеләй итәр идем, дип, шунда ук бу күренешне күзаллый да башладым һәм, киләсе елга мин моны күрсәтергә тиеш, дип үз-үземә сүз бирдем. Балачактан әбиемнән сеңеп калган рухи тәрбия, татар биюенә булган кызыксыну менә шунда бәреп чыкты! Үз тирәмдәге яшьләрне җыеп, «Гүзәл Чулман» бию ансамбле төзедем дә, никах теркәү йоласын сәхнәләштердек.

Ә инде 2011 елда Пермьда үткән «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивалендә катнашу безгә чын мәгънәсендә яңа бер дөньяга ишек ачты. Анда татар халкының төрле этник төркемнәре белән танышып, һәр төбәкнең үзенә генә хас фольклор үрнәкләрен, костюмнар төрлелеген күреп хәйран калдым.

Икенче елны Самарада узган «Түгәрәк уен» фестиваленнән мин инде алга таба ничек эшләргә икәнлеген тәмам аңлап, максатларымны тәгаенләп кайттым: безгә дә үз җирлегебездә казынырга-эзләнергә кирәк икән бит.

2013 елда татарның мәркәзе Казанда үткән фестивальдә без инде үзебезнең иренсылва татарларының костюмнарын торгызып, бу якларда гына биелгән «Кәтинкә» биюен күрсәтә алдык. Әлеге биюне куяр өчен Орда, Көнгер районнарына фольклор экспедициясе оештырып, җирле халыктан сорашырга, музейларда актарынырга туры килде. (Тырышлыгыбыз бушка китмәде, 2015 елда без фестивальнең иң зур бүләгенә – Гран-прига лаек булдык.) Нәкъ менә шул экспедицияләр вакытында халык хәтерендә, халык күңелендә никадәр бай мирас саклануын аңладым мин. Бу мирасны җыйнап, югалтмыйча киләчәк буыннарга тапшыру безнең бурыч бит, дигән уй яңа эзләнүләргә этәрде дә инде.

Узган 2017 елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Грантын оту исә алдагы эшчәнлегебезгә ныклы нигез булды: Пермь краеның бернчә районына фольклор экспедициясе оештырдык. Октябрь һәм Барда районнарында аеруча күп материал туплый алдык. Төп максатыбыз халык биюен,

бию көйләрен өйрәнү булганга, шактый күп бию үрнәкләрен, бу якларда уйнала торган «Кәтинкә» бию көенең төрле вариацияләрен видеотасмага яздырып алдык. Безнең белән очрашуга милли киемнәрен, борынгы читек-

ләрен киеп, гомерлек юлдашлары булган гармуннарын, тальяннарын кыстырып килгән, күңел байлыклары белән ихластан бүлешкән апа-абыйлар (яндырып биюләрен күргәч, бик олы яшьтәгеләренә дә әби-бабай дияргә тел әйләнми) безнең өчен чын хәзинә булды!

Түбәнавылда гармунчы Әхнәф Булатов, авыл имамы Мәүлиҗан Зимасов, 90 яшьлек Тәрҗемә Маматовалардан кызыклы мәгълүматлар алдык. Сараш Мәдәният йортында Сараш, Солтанай, Башап Түз авылларыннан җыелган абый-апалар бию үрнәкләрен дә күрсәттеләр, такмаклар да әйтеп бирделәр. Матди мирасны да кадерләп саклаганнар. «Әниемнән калган читек бу, 1901 елда тегелгән, бик кадерләп саклап кына киям», – диде Мөнибә апа Мәсәгутова, аягындага читекләргә ымлап. Фәрит абый Туктамышев исә: «Минем гармуныма да инде 50 елдан артык, Бардада эшләнгән, элек гармун ясаучы осталар булган бу якта», – дип, үзенең гармуны белән таныштырып алды да өздереп уйнап та бирде. Биюче апалар: «Бездә болай итәләр», – дип, иң элек түгәрәк сызган төсле берничә адым атлап үтәләр дә, аннан соң гына биеп китәләр. Бу якларда сакланган йолаларны да искә төшердек. Арада бу төбәккә генә хас булган «Тын тыңлау» йоласы аеруча кызыклы тоелды. Халыкта аны «Плаушинья кич» (Благовещенье сүзеннән алынган) дип тә йөртәләр икән. Апрельнең алтысыннан җидесенә чыккан төндә киләчәкне юрау йоласы бу.

Танып авылында «Каенсар» фольклор төркеме (җитәкчесе – Таһирә Әҗмәгулова) күрсәткән «Тастымал», «Бармак төртү» уеннары да, Минзимә апа Габҗәлилова сөйләгән хикмәтле хәлләр дә гаять кызыклы тоелды. Үзенең биюе белән барыбызны да сокландырган Сәкинә апа Латыйпова: «Әниебез оста биюче иде, без – бертуган алты кыз, барыбыз да биеп үстек», – диде.

Барда районында халык хәтерендә дә, гаҗәеп бай музейларында да өйрәнәсе кызыклы мәдәни мирас та, матди мирас та тулып ята әле. Бер экспедиция кысаларында гына аларны барлап бетерү мөмкин түгел, әлбәттә.

Үзләрен «Ботык татарлары» дип атаучы Октябрь районы татарларыннан да бу якларга гына хас шактый кызыклы мәгълүмат алдык. Бары тик Октябрь районында гына әби-бабайлар бүгенге көндә дә татар кадриле – «Общий круг» бииләр. Алар аны нәкъ шулай – «Общий круг» дип әйтәләр, бу бию биредә төрле милләтләрнең (татар, рус, удмурт, мари...) аралашып-кушылып яшәвенең бер күрсәткече. Бары тик Әтнәгуҗи әбиләре генә «Кәтинкә»не авыз гармунында уйнап бииләр. Әри-Түз авылында гына юкәдән чыпта сугу станогын күрә алдык. «Сарыкино бук» (сарык тизәге була инде ул) даруы һәм «Аяклы көзге» турындагы сөйләкләрне дә бары тик монда гына ишеттек.

Ботык татарларыннан язып алган кайбер фольклор үрнәкләрен журнал укучыларына да җиткерәсем килә.

«Әри базар» һәм «Чәт Ярминкә»

Октябрь районында елга ике ярминкә үткәрү йоласы булган. Сабантуйга ике атна кала «Чәт Ярминкә», ә көзен, 20 сентябрьдә, «Әри базар» үткәрелгән. Ярминкәне күреп калган өлкәннәрнең сүзләренә караганда, Әри базарда сәүдә эше гөрләп барган, сату гына түгел, товар алмашу да бик киң таралган булган. Татар авылларыннан күкәй, эремчек, май, балык (Самар авылы), җиләк-җимеш, чабата, чыпта, бау, кәрҗин, көянтә, балта, кисмәк, ат камытлары алып килгәннәр. Аларны сатып, кулга кергән акчага тоз, чәй, эре шикәр, кызыл прәннекләр, «әтәч»ләр; чуен тоткыч, чуен, тукыма, кием-салым, бизәнү әйберләре алганнар.

Әри базарга барулары турында: «Бала чакта, биш тиенлек кызыл су (морс) эчәргә товар поезды белән Әригә бара идек. Ул тәмле суга су буе чират була торган иде...»; «Көянтәчиләк асып җәяү йөри идек инде, күкәйләрне гәҗиткә төреп тутыра идек чиләккә», – дип сөйләделәр Әри Түз авылы кешеләре.

Чәт Ярминкәдә, сәүдә эшеннән тыш, күп төрле уеннар да оештырылган.

Чәт Ярминкә турында Самар авылында мондый хатирәләр язып алдык: «Без Ярминкәгә махсус «Общий круг» биергә йөри торган идек. Бу биюне татарлар гына бии, әмма өндәмәләр барысы да рус телендә әйтелә: «Мужики», «Забрать пары», «Вперед», «Обрат», «Навстречу» һ.б.; «Граммофонга «Краковяк», «Коробочка», «Катюша», «Барыня (Господская)»ларны бии идек».

Халык арасында Әри базар һәм Чәт Ярминкә турында бүгенгә кадәр бик күп мәзәкләр йөри. Аларның күбесе рус телен начар белүдән килеп чыккан мәзәк хәлләр турында.

«Сарыкино бук» (Ишем, Янапай авылларында язып алдык)

Бер оста абзый сарык тизәген буяп, «теш сызлаганнан дару» дип базарда саткан. Кайбер беркатлылар бу төймәләрнең файдасын да күргән хәтта!

«50-100» (Әри Түз)

Бер хатын базарда килосын 150 сумнан эремчек сатмакчы булган. Бәясен «йөз илле сум» дип урысча әйтә белмәгәч, «Күпме тора?» – дип сораучыларга, «Пятьдесят сто» дигән. Кешеләр, 500 сум тора икән, дип, баш чайкап китеп баралар икән.

«Пирожки» (Әри Түз)

Бабайның пирожки ашыйсы килгән. 5 данә алмакчы икән, тик «пять»не оныткан бит. Алай да аптырап калмаган, сатучыга килгән дә: «Дай мне шесть пирожков, но одну не надо!» – дигән.

«Чи күкәй» (Ишим)

Кечкенә малай ачыккан да күкәй урларга булган. Шыпырт кына килеп, күкәйне чәлдергән дә элдергән бу. Сатучы аның артыннан: «Чей парень, чей парень?» – дип кычкыра икән. Моның сүзләрен «Чи күкәй, чи күкәй!» дип аңлаган малай, эченнән генә, «Ә миңа чи дә ярый» дип көлемсерәгән.

«Четыр-мытыр!» (Әри Түз)

Бер егет рус авылына эшкә урнашырга барган. Аны эшкә ялламакчы мужик, бәясен килешмәкче булып: «Четыре рубля» дигән икән, «Мне не надо четыр-мытыр, давай за три!» дигән җавап ишетеп шаккаткан.

Хәрби хезмәткә озату (Ишем, Янапай)

Улларын хәрби хезмәткә озатканда, атаана берничә ритуаль йола башкарган. Рекрут егетне матча астына бастырып, улларына яңа пешкән икмәк тотып, догалар укып, аның тирәли өч кат әйләнеп чыкканнар. Шуннан соң улларына ипидән бер кисәк тешләткәннәр дә калган икмәкне сөлгегә төреп, аулак урынга алып куйганнар. Егет әйләнеп кайтканчы ул шунда сакланган. Егет, әти-әнисенә һәм туган йортына карап (туган нигезгә исән-сау әйләнеп кайту өчен), өйдән урамга арты белән чыккан. Хәрби хезмәткә китәргә берәр атна кала, якын туганнары рекрутны кунакка алып сыйлаганнар. Аны бөтен авыл җыелып, гармун белән

җырлап-биеп озатканнар. Апа-сеңелләре, сөйгән кызлары махсус кульяулыклар чигеп бүләк иткәннәр. Йола буенча, егет бер кульяулыкны артына ташлаган. Яулыкны алган кеше әйләнеп кайткан солдатны һичшиксез ашка алырга тиеш саналган. Ир-атлар булачак солдатка тәңкә акчалар биргәннәр. Ул бу тәңкәне саклап, хуҗасына кайтарып бирергә тиеш булган. (Исән-имин әйләнеп кайту өчен эшләнгән йола.)

Чана ясау серләре (Ишим)

Өлкән буын вәкилләренең чана ясау алымнары турында сөйләүләрен тыңлау бик кызыклы булды. Чана төбендәге фанерага бер кат боз, шуның өстенә тирес катырганнар. Аннан тагын боз, тагын тирес... Шулай итеп 6-7 кат боз-тирес катырылгын чаналар бик ныклы булган, ярылмаган.

Чыпта сугу (Ишим, Самар, Әри Түз).

Октябрь районында яшь юкә кабыгыннан чыпта сугу һөнәре бик киң таралган булган. Үзләре куллану өчен дә, сатарга дип тә махсус зур станокларда чыпта сукканнар. Кечерәк станоклар капчыклар, букчалар, тартмалар сугу өчен җайлаштырылган. Укучы балалар шул букчалар белән мәктәпкә йөргәннәр. Кышларын чана, җәйләрен арба төпләренә чыпта җәйгәннәр. Чыптага салып ашлык ташырга да бик җайлы булган. Ишим авылында чыпта сугу станогының аерым фрагментларын гына күрә алган идек, Әри Түздә тулы станокка тап булдык.

Кәлҗемә (Ишим)

Ачлык елларында кырда калган черек бәрәңгене җыеп, пешереп-төеп кәлҗемә ясаганнар. Ул кәлҗемәне хәтерләүче картларның сүзләренә караганда, аннан да тәмле нәрсә булмаган!

Аулак өй (Әри Түз)

Мондый кич утырулар әти-әнисе кунакка киткән кыз өендә оештырылган. Җыелган кызларның һәркайсы, хәленнән килгәнчә, ни дә булса алып килгән: он, күкәй, май... Егетләр килешкә кызлар җырлый-җырлый пилмән әзерләгәннәр. Гармун уйнап кергән егетләр өйгә бәйрәм рухы алып килгәннәр. Бергәләп биешкәннәр, бер-берсенә тәртмәле такмаклар әйтеп күңел ачканнар. Егетләрдән берсен чишмәгә суга җибәргәннәр, кемдер мичне кабызырга чыра телгән. Егетләр, кызлар бер-берсенә бүләкләр дә бирешкәннәр: кызлар сөйгәннәренә янчыклар, кульяулыклар чиккән, егетләр исә көмеш тәңкәдән үзләре ясаган балдаклар бүләк иткәннәр. Балдак ясар өчен тәңкәнең уртасын тишкәннәр дә махсус җайланмага кигезеп, әйләндергәннәр.

Юрау (Әтнәгүҗи)

Кышын кызлар кияү юраганнар: капка аша итек ташлаганнар – итекнең башы кайсы якка караса, кияү шул яктан килә дип фаразлаган. Караңгы абзарда сарыкны аягыннан тотып, кияүнең яшен дә юраганнар: яшь сарык эләксә, яшь, матур киявең килә; сарык карт икән, кияү дә карт булачак. Мендәр астына пилмән салып йокласаң, киявең һичшиксез төшеңә керәчәк дигән ышану да булган.

Кыз урлау (Янапай)

Гадәттә, егет белән кыз алдан килешенеп урлаганнар, әмма кызның берни белми урланган очраклары да булган. «Егетем белән ике ел очрашып, хатлар алышып йөрдек. Бервакыт, кич белән, әни белән чыпта сугып утырабыз, күршебез кереп: «Күрше авылга артистлар килгән, концерт куялар», – диде. Мин, киемнәремне дә алыштырып тормастан, башыма яулыгымны яптым да, өстемә пәлтәмне элеп урамга чыктым. Берничә метр ара үтүгә, мине гәүдәле өч егет эләктереп алды да чанага салды. Карышып маташуымның файдасы тимәде, булачак ирем мине бик нык тоткан иде. Аның өенә кайтып җиттек, анда инде килен каршыларга барысы да әзер: өстәлдә – самавыр, мичтә – шәңгә. Булачак кайнанам миңа алъяпкыч кидерде дә, кайнатама йөземне күрсәтмәс өчен, башыма яулык каплады. Шулай итеп, бу йортта яшәп калдым», – дип сөйләде бер апа.

Җен алыштырган кыз (Танып, Минзимә Габҗәлилова сөйләгәннәрдән)

Күп заманнар элек булган хәл инде бу. Бервакыт, эңгер-меңгер төшкәч, авыл башындагы хуҗасыз калган иске мунчадан сәер тавышлар ишетелә башлый: мунча эчендә әле кемдер җырлый, әле кемнәрдер сөйләшкән кебек була. Билгеле инде, бу хакта хәбәр бик тиз авылга тарала.

Җәйге кичтә кунактан кайтып баручы егетләр арасында мунчадагы сәер хәлләр турында сүз чыга. Арадан бер егет бик батыраеп:

– Нигә аптырап торырга, керергә дә карарга кирәк, – ди.

– Бик батыр булгач, кер дә кара, әйдә, – диләр иптәшләре.

Әйткән сүз – аткан ук, дигәндәй, шомланса да, егеткә кире чигенер юл калмый. Җитмәсә:

– Мунчага кергәнеңне раслау өчен мунча мичённән бер уч көл алып чыгарсың, – дигән шарт та куялар.

Егет, куркуын җиңеп, мунчага кереп китә. Мунча эче тып-тыныч: беркем дә күренми, тавыш та юк. Мунча мичен ачып кулын сузуы була, кулыннан кемдер бик нык итеп эләктереп тә ала.

– Нәрсә бу? – ди егет аптырап. Куркудан, белгән догаларын да кабатлап ала. Шунда:

– Әгәр миңа өйләнергә сүз бирсәң, җибәрәм, – дигән хатын-кыз тавышы ишетелә.

Коты алынган егет: «Сүз бирәм!» – ди дә чыгып йөгерә. Дусларына булган хәлне сөйләп бирә. Барысы да аптыраушта калалар: нәрсә бу – җенме, кешеме?

Ә төнлә төшендә егетнең колагына мунчадагы тавыш тагын ишетелә. Һәм бу хәл һәр төндә кабатлана башлый. Аптырагач, егет мулла янына бара һәм башыннан кичкән хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Аны игътибар белән тыңлаганнан соң, мулла:

– Хатын-кыз киемнәре алып, мунчага бар да ишекне ачып: «Мин сине алырга килдем», – дип киемнәрне эчкә ыргыт, – ди.

Кичке эңгер төшкәч, егет дуслары белән мунчага юнәлә. Мулла кушканча, барысын җиренә җиткереп үти. Бераздан ишектән сылу гәүдәле, бик чибәр яшь кенә кыз чыга. Барысы да бу хәлгә таң калалар. Егет кызны өенә алып кайтып китә. Яшьләр гаилә корып яши башлыйлар. Яшь килен бик ипле, уңган, якты йөзле, тәмле сүзле булып чыга. Кавышуларына бер ел дигәндә, килен әйтә:

– Әйдә, минекеләрне дә барып күрик инде, – ди.

– Кая барабыз соң? – дип аптырый ире.

Яшь хатынның җавабы кыска була:

– Баргач күрерсең!

Ат җигеп чыгып китәләр болар. Байтак баргач, бер авылга барып керәләр. «Бу минем туган авылым», – ди хатын. Алты почмаклы зур йорт янына килеп җиткәч, «Бу – минем туган йортым», – дип, атны туктатырга куша.

Өйгә узалар. Килеп кергәч тә, килен өй эчендәгеләргә:

– Мин табибә, сезнең авыру кызыгыз булырга тиеш, миңа шуны күрсәтегез әле, – ди.

– Ул инде 18 ел шулай бишектә ята, – дип, аңа кешегә дә охшамаган бер куркыныч җан иясен күрсәтәләр.

– Хәзер, мин аны дәвалыйм, – ди дә, хатын баланы алып идәнгә бәрә. Идәнгә барып төшүгә бала дигәнең вак-вак кыйпылчык ташларга әйләнеп чәлпәрәмә килә.

– Сезнең кызыгыз түгел ул! Сезнең кызыгыз – мин! Моннан 18 ел элек сез мине – нарасый баланы – ялгызымны калдырган идегез... – дип елый башлый хатын. Аны кочаклап, әти-әнисе дә елыйлар...

Телебездәге «җен алыштырган» дигән гыйбарә юктан гына килеп чыкмаган. Бүген дә халык арасында, сабый балаларны да, мәетне дә ялгыз калдырырга ярамый, дигән ышанулар яши.

Әлеге экспедиция вакытында җыйган материаллар безнең өчен бик зур байлык. Алар шулай ук бүгенгә көннең әйдәп баручы татар фольклорчыларында да зур кызыксыну уятты. Шунысы куанычлы, бу табышларыбызны тиз арада дөньяга чыгару форсатыбыз да бар: үзебез тапкан берничә коллективны быел июнь аенда Ульян өлкәсенең Иске Кулаткы бистәсендә үтәчәк Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивиаленә алып барырга җыенабыз.

Әлбәттә, бу соңгы экспедиция булмас. Алда безне яңа табышлар, яңа ачышлар көтә.

Алсу БАТТАЛОВА

Малы барның сые бар

(Дәвамы. Башы 1 санда.)

Беренче кат көтү куу йоласы

Татар халкының көнкүрешендә бүгенгәчә терлекчелек белән бәйле бик күп ышану-йолалар сакланып калган. Гаиләне ит, сөт, тире, йон белән тәэмин иткән мал-туар хуҗа өчен йорттагы иң олы хәзинә булып санала, шунлыктан ул терлекләренең иминлеген һәрдаим кайгыртып тора.

Ышану-йолалар арасында Беренче кат көтү куу йоласы үзенә аерым урын алып тора. Ул көтү чыккан беренче көннең ничек узуына карап (терлекнең көтүдә исән-сау йөрүе, качып кайтмавы, туры үз йортына кайтуы һ.б.), тулаем көтү чорын күзаллаудан гыйбарәт. Шуңа нисбәтле, татар халкы терлекне беренче кат көтүгә озатып, көтүдән каршы алганчы бик күп төрле йолалар башкара.

Без үзебезнең Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге тарафыннан Татарстан Республикасының татар авылларына оештырылган экспедицияләрдәге эзләнүләребез барышында беренче кат көтү куугa бәйле йола-гадәтләрне күпләп очраттык, шуларның бер өлешен журнал укучыларына да тәкъдим итәбез.

Чүпрәле районы татар авылларында без көтүне беренче тапкыр куар алдыннан көтүчеләр тарафыннан башкарыла торган «цирут циртү» дигән йолага юлыктык. «Цирут циртү» йоласы иртәгә көтү чыгасы дигән көнне башкарыла. Бу көнне көтүчеләр бер хуҗалыктан икенчесенә кереп, көтүдә йөриячәк мал санын алалар. Йорт хуҗалары аларга йомырка бирә. Йомырка бирү «Малларым көтүдә шушы йомырка кебек тәгәрәшеп йөрсеннәр, үзебезгә язган маллар булсыннар» дигән теләктән чыгып башкарыла. Бу эш кояш баеганчы бара, көтүче йоланы авылның яхшы күңелле, «җиңел куллы» кешеләре яшәгән йорттан башлый.

«Мыни иртәгә көтү куасы дигән көнне кис белән йомырка җыеп йөриләр иде кем көтү көтәргә була. «Цирут циртәбез» диләр иде. Һәрберсенә икешәр йомырка бирәбез инде. Цирут цирткәндә сау-исән йөрсеннәр дип теләкләр теләп чыгаралар иде (Туктарова Ә.К., Чүпрәле районы, Түбән Каракитә авылы); «Цирут цирткәндә, сыер башын санап йөргәндә, анда йомырка бирәбез» (Камалетдинова М.С. Чүпрәле районы, Түбән Каракитә авылы); «Цирут цирткәндә көтүцегә сәдака иттереп, йомырка бирәләр, кем күпме булдырала, хәллерәкләре күбрәк. Шулай ук укучы әбиләргә хәер бирәсең, сыер сау-исән көтүдә йөресен диеп» (Алеева Ф.Р., Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы).

Без тагын берничә тыюга да тукталып үтәргә телибез. Алар арасында иң үзенчәлеклеләренең берсе малларны көтүгә озата баруга бәйле. Мәсәлән, малларын беренче көн көтүлеккә озата барган һәр хуҗа, терлекләре беркадәр көтүгә ияләнгәннән соң, ягъни инде алар ашый, тәртешми башлагач, терлекләрен көтүчегә ышанып калдырып кайтырга кузгалалар. Йола гадәте нигезенә таянып, малларны көтүгә куганда кулына алган көтү таягын бер генә хуҗа да ташлап калдырмый, йортына алып кайтып, мал абзары кыегына кыстырып куя. Информантларыбыз сөйләвенчә, бу тыюны җиренә җиткермәсәң, малларың таралырга, көтүдән туры йортка

кайтмаска мөмкин. Әлеге тыю хәзер дә Апас, Тәтеш, Чүпрәле районннарында яшәүче татарлар тарафыннан бик актив үтәлеп килә.

«Терлекләрне көтүгә озаткач, чыбыкны алып кайтып пайтастына кыстырырга, беренче көннекен. Ул көзгә кадәр, көтү кергәнче тора» (Абдрахманова Х.Т., Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы); «Көтүгә барганда таяк белән барабыз бит инде. Ул таякны бәреп калдырырга ярамый, дия иде кайнам. Ул таякны үгә алып кайтырга, дия иде. Бәреп калдырсаң, терлек кайтмый, тарала, диләр иде. Бер таяк белән куабыз, алып кайтып ишек төбенә куябыз, икенче көнне шул ук таяк белән куабыз» (Алимова А.А., Чүпрәле районы, Мунчали авылы); «Көтү куа торган таягы бар иде безнең әнинең. Аны беркая да илтми иде. Көтүне куып чыгара. Ул таякны кайтарып мөешкә (почмакка) куя иде. Ул таяк сакланырга тиеш. Таякны югалтсаң, терлек кайтмый үгә. Көтү буенча сакланырга тиеш иде. Каты агачтан була иде таяк. Таягы күп еллар саклана. Шомарып бетә иде әнинең» (Туктарова Ә.К., Чүпрәле районы, Түбән Каракитә авылы); «Беренце көтү куган чыбыкны, арканны, җепне кешегә бирергә ярамый. Катярып абзарга югары куярга кирәк. Сыер көтүдән турук үгә кайтсын эцен» (Алиева Ф.Р., Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы); «Көтү куган таякны ыргытып калдырырга ярамый, кайткач сөяп куярга тиеш, орынмаска кушалар иде. Таякны калдырсаң, көтү тарала дип әйтәләр» (Насыйров Г.Н., Апас районы, Кече Күккүз авылы).

Көтү озатып кайтуга бәйле ышануларга нигезләнгән тагын бер тыю – кайту юлында туктап сөйләшеп торырга, кешегә керергә, артка борылып карарга ярамый. Әгәр дә туктыйсың икән, терлегең шулай ук йортка туры кайтмый дип ышаналар.

«Беренче көтү куып кайтканда, кешегә керергә ярамый. Туры кайтмасаң, хайваннар өйгә туры кайтмый диләр» (Хәсәнҗанова К.В., Әлки районы, Каргалы авылы); «Беренце тапкыр сыерны көтүгә кугац, сүләшеп тә, артка карап та кайтырга ярамый, сыер кацып катяцак» (Алиева Ф.Р., Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы); «Көтү куып кайтканда кешегә кергәнебез җук инде. Олылар әйтәләр иде шул» (Шәһиева Р.Р., Апас районы, Үтәмеш авылы); «Беренче көтү куган көнне көтү куып кайтканда кеше белән сөйләшмәскә. Көтүне куасың да, туры өеңә кайтасың, бик сайрарга ярамый» (Хуҗина Сания, Әлки районы, Түбән Әлки авылы).

Безнең тарафтан теркәлгән тагын бер йола гадәте – беренче кат көтү куган көнне «көтү сәдакасы» бирү. Хуҗабикәләр, «хайваннар исән-сау йөрсеннәр, үзебезгә насыйп маллар булсыннар» дип, йә догалар укый торган карт-карчыкка, йә мәчеткә сәдака илтәләр. Бу гадәт без билгели алган үзенчәлекле ритуаллар чылбырын йомгаклый. Сәдака итеп акча яисә ризык бирәләр. Әлеге гадәт Әлки, Апас, Тәтеш һәм Чүпрәле районының барлык авылларында да башкарылып килә.

«Хайваннарны көтүгә чыгардием дип сәдака бирү бар» (Насыйров Г.Н., Апас районы, Кече Күккүз авылы); «Көтүгә куганда көтү сәдакасы бирәбез, исән-сау йөрсеннәр диеп» (Мөбәрәкшина Ф.Б., Апас районы, Олы Күккүз авылы); «Беренче тапкыр көтү кугач, хайваннар исәнлеге өчен дип, мәчеткә сәдака кертәм» (Шәһиева Р.Р., Апас районы, Үтәмеш авылы); «Көтү чыккан көнне, укый торган әбигә, маллар исән-сау йөрсеннәр дип, сәдака бирәләр» (Шиһапов С.Н., Әлки районы, Чиялебаш авылы); «Көтүгә куганда, Аллага тапшырдык, дип әйтәбез. Көтүгә чыккан көнне сәдака бирәбез» (Миңгәрәева Г.С., Апас районы, Үтәмеш авылы); «Көтү сәдакасы бирәбез, йә көтү чыгар алдыннан, йә көтү йөри башлагач бирелә, терлекләр исән-имин йөрсеннәр дип» (Идиятова В.В., Апас районы, Түбән Барыш авылы); «Көтү сәдакасы бирәбез. Акча да бирәбез, икмәк тә бирәбез, исән-сау җөрсеннәр дип, үзебезнең кулга керсеннәр дип» (Мөбәрәкшина Ф.Б., Апас районы, Олы Күккүз авылы).

Беренче кат көтү куу көненә кагылышлы ышануларның соңгысы терлекләрне каршылауга бәйле. Әлки районы татар авылларында түбәндәге тыюны теркәдек: «Беренче көтү куган көнне малларны эзләмәскә кушалар ие, гел эзлисе була дип» (Хуҗина С.С., Әлки районы, Түбән Әлки авылы).

Экспедиция барышында терки алган кызыклы гына күзәтүләребезгә анализ ясап, без түбәндәге фикерләргә килә алабыз. Татарларның беренче көтү куу көненә бәйле йолалары төрле ышанулардан, тыюлардан, аларга нигезләнеп башкарыла торган ритуаллардан торучы күпкырлы, берничә яссылыклы мәдәни күренеш. Әлеге йола ритуалларының барысының да вазифалары – терлекнең көтүдә көзгә кадәр исән-имин йөреп, гаиләнең үзенә насыйп мал буларак саклануын тәэмин итү. Йолаларның терлек хуҗалары, көтүчеләр, дини карчыклар катнашында башкарылуы йола комплексының мәҗүсилек чорлары ышанулары, тыюлары белән беррәттән ислам дине мәдәнияте күренешләренең дә үрелгән булуын күрсәтә.

Мәхбүбҗәмал АКЧУРИНА

Кыз егълату

(18нче гасырның ахырында булган вакыйга)

«Түгәрәк уен» журналына татар халкының атаклы сәүдәгәрләре – Акчуриннар нәселеннән булган язучы, мөгаллимә Мәхбүбҗәмал Акчуринаның «Кыз егълату» дигән язмасын әзерләгәндә, әлеге язмадан соң «Шура» журналы редакциясенә килгән кайтавазга да тап булдым. Аны фольклорчы галим Гали Рәхим язып җибәргән. Укучылар игътибарына, бик сөенеп, кайтавазны һәм авторның аңа биргән җавабын да тәкъдим итәм.

Рәйсә Шәрәфиева,
Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге
фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге баш библиографы.

«Килен, балакай! Иртәгә иртәрәк торып тарыны төярсең, Солыткайның тиңдәшләре җыелыр, боткага кирәк булыр», – дип, Зөләйха әби килененә әйтеп куйды да, үзе ястү намазына кереште.

Зөләйха әби 65 яшьләренә килгән картчык улып, ире Сәфәргали агай бер ярты ел гына борын дөньядан китеп, тол калган иде. 30 яшьләрендә бер угылы илә 25 яшендә Солтанбикә исемле кызыннан башка балалары кечкенә вакытларында дөньядан китмеш иделәр.

Сәфәргали агай тере вакытында Солтанбикәне икенче авылга Бикмәмәт исемле кешенең угылына вәгъдәләшкән булсалар да, Сәфәргали агайның үлеме илә туй тиз заман була алмады. Хәзер инде, туйга берничә көн калдыгында, кызлар җыелып «Кыз егълату» көне булачак иде.

Зөләйха әби намазын тәмам итеп, догаларын укып, йокларга ятса да, кызының килачәк көне тугрысында уйлар берсе артыннан икенчесе килеп йокысын качырды. Ире исенә төшеп, егълап та алды. «Аһ Алла! Синең тәкъдиреңә чара юк, атасы тере булса, кызымның күңеле моңаймас, туе да күрекле булыр иде», – диде. Үзенең зур каениш арасына төшеп, таңнан элек торып, кыш көне әвендә киптергән арыш сугулары, 25 кешелек гаиләгә кул тегермәнендә ярма ярып, иртәнге ашка ботка пешерүләре; берәр һәфтәләп [атналап] аягындагы чабатасын чишәргә вакыт тапмыйча шул көе йоклаулары; аз гына гаеп өчен каенанасыннан табагач, уклау ашаттыклары; биш-алты ел ата-анасына бара алмыйча зар булганнары исенә килеп, кызының да башына шундый хәлләр килүеннән куркып калтырап китте.

Таң беленә башлагач киленне уятты. Үзе каеништән күп җәфа күргәнгәме, яки йөрәге йомшак идеме, Зөләйха әби килене илә яхшы мөгамәлә кылып [аралашып], эш кушканда кычкырмый, бакырмый иде.

Урыныннан торып тәһарәт алгач, кызын уятмакчы булды. Кызы кулларын башы астына куеп рәхәтләнеп йоклаганга, уятырга аяды. «Йокла, кызым! Йокла, Солыткаем! Тыныч йокыларыңның ахыр көннәре инде», – дип, уятмый китте.

Көн яктырды, кызлар берәм-берәм җыелдылар. Килен барып «Кыз егълату»га оста Хаслия тутайны да чакырып китерде. Хаслия тутай өйгә керү илә, өйгә әллә нинди моңлы төс керде. Зөләйха әби илә Солтанбикәнең

күзләре бер-берсенә тугры килеп, аерылачак көннәрен сизгән төсле, исәнләшкән карау илә караштылар. Солтанбикә пич алдындагы ашханә урынына торган кечкенә бүлмәгә[1] керде.

Хаслия тутай, дога кылып саулык сорашкач, үзенең хезмәтенә кереште. Зөләйха әбине түр урындыкка[2] , агасын тар урындыкка[3] , тиңдәш кызларны эскәмияләргә утыртты. Хәзерләп куйган ак чаршауны Солтанбикәнең башына ябып, бүлмәдән алып чыкты. Идән уртасына туктап, моңлы тавыш илә җырлый башлады:

Әгузе белән башладым, укып ташладым,
Кече яшьтән җыйган яшемне әле генә
түгә башладым.

Аннан анасы каршына туктап:

Әгузе белән бисмилла – ул иманнарның
башы икән;
Карадым анакай йөзенә – ике күзе
тулы яшь икән.
Аткынаем борган китәргә, килдем
күңелеңне бәхил итәргә!
Синнән айрылуга вакыт җитте,
инде миңа ни хәл итәргә?

Зөләйха әбинең җыерчыкланган бите буенча яшьләре ага, агасы да еглый, кызларның да күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр коела. Чаршау илә каплаганга Солтанбикәнең йөзе күренмәсә дә, иңбашлары калтыраганга, чиксез еглавы сизелә.

Хаслия тутай эшендә кимчелек кылмый җырлый:

Мин анакайга барырмын ап-ак кына
чатыр ябынып,
Әле дә анай кәбәмне[4] күрдең?
Баксаң елар идең сагынып.
Китәм, анай кәбәм, күреп кал!
Тагы да килә алмам – юлым тар!
Чыбылдык кынам чуп-чубар, чебеннәр үк
кунса – кем куар?
Туган илем сагынып елаганда, еламачы,
диеп кем тыяр?
Тар урдыкларның буена
куш чыбылдыклар корылган;
Минем буенгынам[5] борылган
анакай кәбәмнең югыннан.
Китәм, анай кәбәм, күреп кал!
Тагы да килә алмам – юлым тар!

Зөләйха әби тартышып-тартышып еглый. Солтанбикәнең бөтен тәне калтырап ычкынган тавышы ишетелә.

Хаслия тутай Солтанбикәне агасы тарафына борып:

Борылыш кына, борылыш юл килсә,
борылмамусән, агакай?
Кереп халемне белүгә хурланмамусән,
агакай?

– Юк, сеңлем, юк! Алла сакласын, синең хәлеңне сорау буенымa фарыз булсын! — дип, агасы җавап кайтара.

Аннан кызлар тарафына борылып:

Күнчегемдә[6] минем күк нагыш[7],
Күчерәлмәм, дустлар, мин яңгыз[8]!
Эчкенем үк тулган кайгы-сагыш,
Таркайталмам[9], дустлар, мин яңгыз!

Бик каты еглалыктан Солтанбикә аяк өстендә көчкә тордыкыны Хаслия тутай сизеп: «Тотыңыз!» – дип кызларга ишарә кылды. Ике кыз Солтанбикәне тотып урындыкка илттеләр. Башыннан чаршауны ачып карасалар, йөзе ап-ак булып, һушы китәрлек дәрәҗәгә килмеш! Баш астына ястык куеп, йөзенә салкын су сиптеләр. Тиңдәш кызларның һәммәсенең еглаудан йөзләре, күзләре шешенеп беткән иде.

«Кыз еглату»дан өч-дүрт көн соң никах мәҗлесе булды. Каенасыннан Солтанбикәгә тастар[10] , сылавыч[11] , ике данә башлы инә (булавка) килде. Киленне алып китәр көн янә ыруг-кардәш җыелып, Солтанбикәнең башына тастар сарып, алача[12] чаршау илә өртелмеш дәдекле[13] арбага утыртып озатып җибәрделәр.

(Шура. — 1911. - № 20. — Б. 637-639).

Идарәгә мәктүпләр:

Түбәндәге сөальләремә «Шура»ның киләчәк номерының сәхифәләрендә җавап бирмәкеңезне рәҗа идәм. 20нче гадәд[14] «Шура»да хөрмәтле Мәхбүбҗәмал ханым Акчуринаның «Кыз егълату» нам[15] бер хикәяте дикъкатемне җәлеп итте. Бу хикәяттә тасвир кылынган вакыйга халык арасында була торган милли бер йола (гадәт) микән? Бу гадәт вакытында җырлана торган җырлар чын-чын халык җырлары микән? Бу гадәт кай тирәдә вә кемнәр арасында таралган гадәт икән? Халык әдәбиятын тәдкыйк[16] илә мәшгуль булганлыгымнан, бунларны белү миңа аеруча матлубдыр[17]. Әгәр дә «Шура» идарәсе бу сөальләремә җавап бирә алмаса, бу җавапларны бирүне, «Шура» аркылы, Мәхбүбҗәмал ханым Акчурина җәнапләреннән түбәнчелек илә үтенәмен.

Мөхәммәтгали Габдерәхимов
(*Гали Рәхим – ред.*).
(Шура. — 1911. — № 22. — 4 тышлык бите.)

Мөхәммәтгали Габдерәхимов җәнапләренең сөальләренә җавабым:

«Кыз егълату» хикәясендә күрсәтелгән вакыйга, буннан йөз еллар – ике йөз ел элек шундаен көчле милли гадәт булган ки, хәтта ваҗиб[18] мәнзилендә[19] йөретелгән дисәм мөбаләгә[20] улмас. Саратов губернасының Кузнецкий һәм Петровский өязләрендә, гавам[21] халкы арасында, егълатмыйча һичбер кыз кияүгә озатылмаган. Җырларны да җырлаучы ирләр түгел, хатыннар үз моң-зарларын нечкә калебләрендә сыйдыра алмагач җырлап, егълап бушатканнар.

Ул заманда мишәрләр арасында хатыннарның, хосусан бичара киленнәрнең тормышы кол вә кәнизәкләрдән[22] артык булмаганга, кызларны 25 яшьтән ким кияүгә бирмәгәннәр, кызларын тереләй тәмугъка салуга аяган аналар 30-35 кадәр тотканнар.

Туйдан элек «Кыз егълату» гадәте: гүя бу бичараның азатлыктан коллыкка төшүенә, көченнән тыш булган хезмәтләрне җиренә китерә алмагач, сугу, кыен күрүләренә, зинданга төшеп дөнья яктысы күрүләре тәмам булуына матәм тотудыр.[23]

1830 нчы елларда бу гадәт кими башлап, 40-50 елларда бөтенләй сирәкләнеп, ахырында тәмам беткән.

Сабый вакытымда, бер фәкыйрә кызга туй көтүгә җыелган хатын-кызлар арасына чакырылган идем. Фәкыйрь кешеләрнең туендә аш-су мул булмаган кеби, эш тә күп булмый. Утырып торган хатыннардан берәве: «Туй килүгә байтак вакыт бар әле, тик торганчы кайсыңыз булса кыз егълатыр идеңез!» – дигәч, «Мин белмим», «Мин дә белмим», – дигән тавышлар ишетелде. Арада бер Эшләки тутай дигән карчык бар иде. «Инде ни, борынгыча чаршау яптырып булмаса да, бераз егълатыйм», – дип, тамагын кырды. Кияүгә бара торган кыз бер читтәрәк утырган иде. «Юк, Эшләки тутай, азапланып җырлама! Барыбер егъламыйм, минем көнем моннан да яман булмас инде», – диде. Карчык аңа карамыйча җырларга кереште. Кияүгә китә торган кыздан башлап, кечкенә кызчыкларга кадәр егъламаган кеше калмады.

Мин шуннан кайткач ук «Кыз егълату» тугрысында анамнан сораша башладым. Анам да үзенең сабый вакытында Петровский өязендә, ак чаршау ябындырып «Кыз егълату» булган җирдә хәлдән киткәнче егъладыгыны сөйләп, миңа байтак мәгълүмат бирде. Бу җырлар минем хикәячегемдә язылган кадәр генә булмыйча, бик озын булган. Битләре бөрешкән, күзләре эчкә баткан карчыклардан сорашып, хәтеремдә калганнарын гына яздым. Шундый милли гадәт, җыр, табышмак, әкиятләрне сорашуга һәвәсле булсам да, ул вакытта яза бармаганыма хәзер һәрвакыт үкенәмен.

Мәхбүбҗәмал Акчурина.
(Шура. – 1911. – № 24. – 2-3 тышлык бите.)

---

[1] мишәрләрдә «чолан» дип йөртелә (-М.А.)
[2] сәке төсле киң урындык (-М.А.)
[3] дивар буенда бер такталы урындык (-М.А.)
[4] кәгъбәм (-М.А.)
[5] буен — муен (-М.А.)
[6] күлмәкнең изүе (-М.А.)
[7] нәкыш (-М.А.)
[8] ялгыз (-М.А.)
[9] тарата алмам (-М.А.)
[10] читләре ефәк ука илә уртасы назик ак мамык яки җептән тукылмыш. Тастар сүзе дәстәрдән алынмыш булса кирәк (-М.А.)
[11] ука илә нәкышлагән, тастар астында башка киелә. Русларның «чепчик»ләренә охшаулы (- М.А.)
[12] күк илә ак яки күк илә кызыл җептән шакмак-шакмак итеп тукылмыш (- М.А.)
[13] көймәле (- М.А.)
[14] гадәд — сан
[15] нам — исемле
[16] тәдкыйк — җентекләп тикшерү
[17] матлуб — теләнгән, эзләнгән
[18] ваҗиб — тиешле, үтә кирәкле
[19] мәнзиләндә — дәрәҗәсендә
[20] мөбаләгә — арттыру, күпертү
[21] гавам — гади, надан
[22] кәнизәк — кол хатын, җария
[23] матәм — кайгы тоту

Кыңгыраулы атлар көтеп тора...

Урал татарларында Кыз елату (сеңнәү, чеңнәү) йоласы

«Сеңнәү, чеңнәү – кызны җырлап елату, кыз елату җырларын җырлау.

Корткалар чеңни аны кыз киткәндә. Шундый бер сабак була, шундый матур тавыш чыга анда. Анда кешеләр елый, шундый моңлы ул. Без бетеки булып, без елап тораек. Кызны шул алып китәр чакта чеңниләр.

Чеңнәүнең көе бар, бик матур, моңлы. Безнең истә түгел инде хәзер. Без аны ирмәк итеп караганбыздыр бала чакта. Мөнәҗәт кебек матурые ул».

«Кыз чеңнәү дип әйткәлиләр, ике хатынкай утырган да менә шулай чеңнәгәннәр. Мин анысын оныткканмын кый әле. Еламаган бер кеше дә калмый. Чеңләүчеләр авылда берике кеше генә булган. Кыз елаган. Туган йортыңнан аерылу җиңел түгелдер инде.

Кыз уртада утыра, чаршау тотып торганнар, өй тулук кеше булган, бер тавыш та чыкмаган. Шундый матур итеп чеңнәгәннәр.

Безнең Тутыяны кияүгә биргәндә чеңнәделәр. Башларына чаршау яптылар. Дүрт кешене дүрт мөгешеннән тоталар. Ябу астында утырды. Кызны елаталар.

Инәкәем, ашың пешәр булса,
Балаларың җыелыр.
Алар булып, мин булмасам,
Күзеңнән яшь коелыр.

Капкаларны чыккан чакта
Пар атлары дулый башлады.
«Сау бул, инәкәем!» дигәндә
Барысы да елый башлады.

Тактадай такта балавыз,
Такта өсләренә ябабыз.
Фатыйхадан ташламагыз,
Кулыгызда үскән балагыз.

Ишек алдында ак каен,
Караштырып торыгыз.
Узганда барган кешеләрдән
Сораштырып торыгыз.

«Кыз башына чаршау бөркәделәр дә чеңнәделәр.

Ай ак көчек, ак көчек,
Азбар аста ят, көчек,
Монда килгән кодаларның
Ыштан бавын тарт, көчек.

Күп була ул чеңнәү. Кыз елый.

Алырга килгәндә чеңниләр аны. Кызның туганнары, нәселләре чеңни. Күп ул чеңнәү җырлары.

Кызны алып китәргә атларны җигәләр, кыңгыраулы атлар, көймәле атлар көтеп тора. Кияү яклары килә ат белән. Ә монда кызны чеңниләр, атны әзерләгәнче кызны елаталар. Хәзер инде көймә белән китмиләр, кызны чеңнәмиләр.

Кыз шунда була кый чеңнәгәндә, китәсе килми, елый. Кайсы берсе бигрәк еракка китә кый».

(Чыганак: Ф.С.Баязитова, Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары, Казан, «Фикер» нәшрияты, 2002, 76-77 битләр).

* * *

Атакаем, атың күпме ийе,
Серге баукайлары сукмы ийе.
Атакаем, мине яшьтән бирдең,
Асрар хәлкәйләрең юкмы ийе.
Уй...

Атакаем өендә
Утыра идем тәрәз төбендә.
Ят кешеләрнең өендә
Утырамын ишек төбендә.
Уй...

Ишектән чыктым – аерылдым,
Капкадан чыктым – кайрылдым.
Атай, инәй, сау булыгыз,
Инде мин сездән аерылдым.
Уй...

(Чыганак: Ф.Ю. Юсупов, Сафакул татарлары: тарих, тел, халык иҗаты, Казан, «Татполиграф» ААЖ, 2006, 370-371 битләр).

Хатын-кызның күрке – яулык

Беренче карашка гади баш киеме кебек кенә тоелса да, безнең тормышыбызда яулыкның үзгә бер урыны бар. Әдәби әсәрләрдә яулык хәтта символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Моның мисалы итеп Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасын искә төшерү генә дә җитә, бу әсәрне белмәгән татар кешесе юктыр мөгаен.

Авылыбыз китапханәсендә «Хатын-кызның күрке – яулык» дип аталган очрашу-кичә узу да очраклы хәл түгел. Шул яулык аша без никадәр вакыйгаларны, күпме кешеләрнең язмышларын искә төшердек.

Зал күзнең явын алырдай аллы-гөлле бизәкле яулык, шәлъяулык, шәлләр белән бизәлгән иде. Авылдашлар 50-60 ел сандык төпләрендә изге бер истәлек итеп саклаган яулыкларын алып килгәннәр. Кичәне китапханә мөдире Тәнзилә Шәйхнурова яулык тарихы белән таныштырудан башлады:

– Яулык кына дисәк тә, аларда тарихыбыз ярылып ята: төсе, бизәкләре, тукыманың сыйфаты – һәрберсе үз чорының үзенчәлеге турында сөйли; халык сәнгатенең дәрәҗәсен күрсәтә. Элегрәк әби-әниләребез башларына өрпәк (өчпочмаклы яулык) белән тастар (ак киндердән киселгән озынча яулык) бәйләп йөргәннәр. Торабара фабрикада эшләнә торган дүртпочмаклы яулыклар барлыкка килгән. Татар хатын-кызлары аны үзебезнең милли гореф-гадәтләргә туры китереп бөркәнгәннәр: ике янәшә почмагын ияк астына бәйләп, яулыкны таратып аркага төшергәннәр. Яулык иңбашларын каплап торсын өчен шулай эшләнгән бу. Кызлар исә, хатыннардан үзгә итеп, яулыкның ике очын колак артыннан уздырып, артка чөеп бәйли, бит, муен, иңбашларын капламыйлар.

Ефәк җепләр белән чигелгән ак яулык хатын-кызның сафлык билгесе саналган; башыннан яулыгын мәҗбүри тартып алу кыз бала өчен оят гамәл булган.

Заманында яулык бик зур бүләк исәпләнгән. Шәһәрдән килгән кунак та, базарга барган крестьян да, ерак якларда хезмәтен тутырып кайткан ир-егетләр дә бүләк итеп яулык алып кайта торган булганнар; егетләр яраткан кызларына да яулык бүләк иткән.

Кичәгә дистәләп яулык алып килгән Тәгъзимә Гыйззәтуллинаның ядкәрләре арасында үзенә гашыйк булып йөргән классташының армия хезмәтеннән, Германиядән бүләк итеп алып кайткан яулыгы да бар иде. Рәсимә Хәсәнова гаиләләрендә 50-60 ел сакланган яулыкларының һәрберсенең тарихын сөйләде. Бүләк иясе – туган-тумачалар, әнкәйләр, дуслар үзләре юк инде, ә менә яулыклар, буыннар чылбырын бәйләүче истәлек булып, һаман да саклана.

Нәсимә Биктимерова үзе белән алып килгән һәр яулыкның «биография»сен искә төшерде:

– Менә бу яулыкны 1974 елда кайнанам Хәернурга бүләк итеп биргән идем, – диде ул, япон яулыгын күрсәтеп. – Ә менә бу тула шәлне 1950 елда торфчылар алып кайтканнар. Кышкы салкыннарда юлга чыксалар, бишмәт өстеннән менә шундый тула шәл ябынганнар элек...

Тәнзилә Шәйхнурова җитмешенче елларда беренче хезмәт хакына әнисенә бүләк иткән яулыкны алып килгән иде. Яулык гомере буе колхозда эшләгән, алты бала үстергән әнкәсе Миннегаян турында хатирәләрне дә уятты.

Тәнзилә Шәйхнурова сүзне 79 яшьлек Хәнифә әби Вәҗиевага бирде.

– Бу яулыкка бер гасыр, ягъни 100 ел инде. Авылыбызда иң борынгы яулыктыр ул. Аны бабам Талип беренче герман сугышыннан (1918), исән калу сөенеченнән, әбием Бибисарага бүләк итеп алып кайткан. Каян алгандыр, анысы билгесез. Ул заманда авылда мондый шәлъяулык булмаган. Гасыр кичкән яулык, тишекләре – бәйләгән җепләре өзелгән

җирләре булса да, әлегә кадәр матурлыгын җуймаган. Ялтырабрак торган чуклы-ефәк зур шәлъяулык, җилкәгә салсаң, шуып төшәргә генә тора. Билгеле, әби аны бик яратып бәйләгән, мәҗлесләрдә җилкәсенә салган. Талип бабай да, аның улы – минем әти Вәгыйз дә Бөек Ватан сугышында башларын салганнар, ә яулык күңелләрне җылытып, истәлек булып һаман яши әле. Сугыш чорында ничек кенә авыр булмасын, ачка тилмермәсен, яулыкны ризыкка, икмәккә алыштыру мөмкинлеге булып та, Бибисара әби аны чит-ят кулларга бирмәгән. Күңелендә, бәлки, бабай кайтыр да шушы яулыкны ябып аны каршы алырмын, дигән өмет уты янгандыр, гомере буе ирен дә, улын да көтеп яшәде ул...

Яулык әбидән әнием Бәгъдәнурга калган. Ул да бу яулыкны бәйләп бик күп ашларда булды, яңадан-яңа яулыклары була башлагач кына, башыннан алып, сандыкка салып куйды. Мин дә еш кына сандыкны ачып, андагы истәлекле әйберләрне барлыйм, хәзер инде бу яулык тарихын оныкларыма сөйлим. Ефәк нык бит ул, гасырлык ядкәр булып әле тагын яшәрлеге бар.

Гыйззәтуллина Тәгъзимә сөйли:

– Мин күп балалы гаиләдә төпчек кыз булгач, игътибар зур булган, әткәй-әнкәйнең дә, әби-бабайның да яраткан кызы идем. Ерак әби Шәмсенур, бабай Шәйхеләгзәм авылда хәлле гаилә булган. Бабай 3 аты белән алмашлап аръякка товарга йөргән: авылдан ризык төяп алып китеп, Әгерҗе-Ижау якларында саткан яки товарга алмашкан. Шәһәр байларыннан, фабрикалардан авыл халкына кирәкле көндәлек товар: төрле тукыма, шәлъяулык, ефәк, чәй, буяулар алып кайткан. Ә әби тәмле ашарга, матур киенергә яратты. Мин әбинең яраткан оныгы, эшләренә булышып гел аларда кунып кала идем. Әле дә күз алдымда: аларның яшел чирәмле иркен ишегалды уртасыннан су ага. Әби, чираттагы матур яулыгын ябып, күршеләренә яки, аркасына кечкенә ак чүпрәк капчыгын асып, озын таягына таянып, магазинга китәр иде. Тимер мич өстендә боламык пешерү, күмер самовары кайнату кебек эшләр аркасында, күлмәк итәге бик үк чиста булмаса да, яулыгы һәрвакыт күз явын алырлык булды. Көнгә ничә тапкыр урамга чыга, чыккан саен яулыгын алыштыра. Аның өчен яулык хатын-кыз күрке иде. Бабай алып кайткан товар арасындагы иң матур яулык – аныкы гына, андый яулыкны авылда бүтән хатын-кыз бәйләргә тиеш түгел... Инде әби якты дөньядан киткәнгә ярты гасыр, әни үлгәнгә дә 15 ел булды. Сандыкны ачкан саен әбием-әнием бәйләгән яулыкларны кулга алып сыйпыйм, исним – үзәк өзелеп бала чаклар искә төшә. Җитәр-җитмәс тормышта яшәсәк тә рәхәт иде. Табигать чиста, булган ризык тәмле, кешеләр ихтирамлы, чиста күңелле булган. Ләкин барысы да еракта калган, кичә укылган әкият кебек.

Хафизова Зәрия сөйли:

– Әтием Хафизов Акмалны, сугышта яраланып, 4-5 ай госпитальдә ятып, сугышка керерлеге булмагач, 1945 елны авылга кайтарып җибәргәннәр. Яралы солдатның биштәрендә олы шакмак шикәр, консервылар булган. Шул вакыт, бер баласын күтәреп, икенчесен җитәкләп, поездга чегән хатыны керә дә хәер сораша башлый. Биштәрнең зурлыгын чамалаган хатын аз гына йөри дә әйләнеп әти янына килә икән; шулай берничә тапкыр кабатланган. Әтинең дә кайтасы җире ерак, авылда да ач балалары көтә, биштәрен бушатасы килми. Шулай да түзми бер шакмак шикәрен алып бирә. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң... Чегән хатыны әтигә күрәзәлек итә башлаган һәм, җитмәсә, җилкәсендәге кара җирлеккә зур кызыл чәчәкләр төшкән яулыгын да салып биргән. Шуннан соң инде ярты биштәр дә бушап калган...

Әтинең исән кайтуына бер сөенсә, матур яулыкка икеләтә сөенә әнием Кәнҗелбанат. Бик яратып, кунакка барганда гына кадерләп бәйләде аны әни. Әти дә исе китеп кабат-кабат чегән хатынын искә төшерә иде: «Барлык юраулары да төп-төгәл юш килде бит, балалар санын да, эшне дә, тормышны да ничек шулай төгәл әйтергә була?!» – дип еш кабатлый иде.

Әти дә, әни дә мәрхүмнәр инде. Ә яулык исән, кадерле истәлек булып гаиләдә саклана. Чегән хатыны да ризалык белән биргәндер яулыгын, бәлки шушы яулык аның балаларын да үлемнән саклап калгандыр. Чөнки без бик бәхетле гаиләдә үстек, хәзер дә булганына шөкер итеп оныклар тәрбиялибез. Яулык тарихын барлык балалар да, оныклар да белә.

...Истәлекләр, истәлекләр... Яулыклар аша чорлар белән чорларны бәйләдек, узганнарга кайтып килдек. Хак әйтәләр, хәтер исән булганда, йолалар саклаганда, милләт яши. Баянчыбыз Марсель Биктимеровка ияреп, «яулык» сүзе кергән күпме җырыбызны искә төшердек. Гөлсинә Зыятдинова белән Тәнзилә Гарафетдинова төрле рәвештә яулык бәйләү ысулларын да күрсәттеләр. Истәлекләр, яулыклар тарихы әле чәй өстәле янында да бик озак дәвам итте.

Заһидә НӘБИУЛЛИНА,
Тукай районы, Күзкәй авылы.

«Һәрвакыт алга барырга тырыш!»

Кайчандыр әти миңа, лаеклы ялга чыккач, үзеңә дә, җәмгыятькә дә кызыклы һәм файдалы булырдай шөгыль тап, дип киңәш биргән иде. Башта, кызым киңәше белән, оныкларым өчен нәни-нәни әкиятләр язарга керештем. Тик күңелгә барыбер нидер җитми иде. Ә менә узган ел гаиләбез белән бөтен республиканы шаулаткан «Төп йорт» гаилә ансамбльләре иҗат фестиваль-бәйгесендә катнашу, алай гына да түгел, фестивальнең декоратив-гамәли сәнгать номинациясендә 1 дәрәҗәдәге диплом яулау минем күңел офыкларымны киңәйтеп, тормышыма өр-яңа мәгънә өстәп җибәрде. «Аллага шөкер, гаиләбезнең мактанырлык уңышлары да, сәхнәдән сөйләрлек матур тарихы да бар! Шулай ук буыннан-буынга күчкән гаилә йолаларыбыз, күркәм һөнәрләребез дә бар безнең!» – дип сөенеп кайттым мин Питрәчтә узган Йомгаклау турыннан. Һәм күңелемнән миңа олы тормыш мәктәбе биреп калдырган әти-әниемә рәхмәтләр укыдым.

Безнең әтиебез хәрби кеше иде, шунлыктан гаиләбезгә төрле урыннарда яшәргә туры килде. Әтием мине язмышның каршылыкларын, авырлыкларын сынмыйча-сыгылмыйча уздырып җибәрергә өйрәтте. Ул миңа еш кына: «Тормыш тигез генә бара торган урам түгел, анда чокыры да, баткаклыгы да, сикәлтәсе дә була, ә кайвакыт, гомумән, тар сукмактан гына да барырга туры килә. Каршыңа нинди генә җилләр иссә дә, юлыңа нинди генә авырлыклар очраса да, ирләрчә уздыр, кыйналса да егылмаган боксчы кебек, аягыңда басып кала бел. Һәрвакыт алга барырга тырыш!» – дия торган иде.

Минем балачагым Калининград шәһәрендә узды. Без кайчандыр немецлар яшәгән иске генә өйдә тордык. Өйне мич ягып җылыттык. Әти, энекәш һәм мин бергәләп утын әзерли идек. Утын монда ел әйләнәсе кирәк! Олы ирләр эшли торган эшләрне әти энекәш белән икебезгә бүлеп бирә иде. Әти безне агач эшенә дә өйрәтергә тырышты: лобзик белән агач тартмачыклар, киштәләр эшләүләребез истә калган.

Әниемне мин һәрвакыт эш арасында итеп күз алдыма китерәм. Ризыкларны бик тәмле итеп пешерүе өстенә, өй эшләрен дә пөхтәләп, яратып башкара иде ул. Өстәвенә, бик оста тегүче иде әни! Ательеда эшләгәндә мода дөньясындагы һәр яңалыкны белеп торды. Кайбер заказларны өйгә алып кайтып та эшли иде. Бу аңа безнең өс-башны кайгыртып торырга да ярдәм иткәндер. Горурланып әйтә алам, без һәрвакыт мода буенча киендек.

Әнинең ялы да «үзенчәлекле» булды: бушаган арада, кулына энә-җеп алып, йә тегәргә, яки киерге тотып чигәргә керешә, аның кул эшләре дә бик матур, зәвекълы килеп чыга иде. Әти аларны аерым бер горурлык белән кыса эченә урнаштырып, фатирыбызның диварына элә иде. Әни кайбер эшләрен башкаларга да бүләк итте. Әни чигешләре арасында иң кадерлесе дә, матуры да «Тавис кош» картинасы булды. Кайда гына яшәсәк тә, без ул картинаны өйнең иң түренә элеп куя идек. («Тавис кош» картинасы 2006 елда Санкт-Петербург шәһәрендә узган Федераль Сабантуйда театральләштерелгән татар шәһәрчеген бизәүдә дә кулланылган иде.)

Кызганыч, күченүләрнең берсендә әлегә картина югалды... Әниемнең «Көймәдәге кыз» һәм «Яр буе» чигеш-картиналары чын сәнгать әсәрләре булып күз алдымда тора. Безнең өчен иң кадерлесе – һәр чигүдә әниемнең йомшак табигате, искиткеч бай эчке дөньясы чагыла иде.

Эше күп булуына карамастан, әниебез тегү һәм чигү серләрен танышларыбызга, күршеләргә дә өйрәтергә өлгерә иде. Хәтта мине дә кул эшләренә өйрәтте ул! Мәктәптә укыганда мин чиккән «Тюльпан» картинасы мәктәптән районга, аннан шәһәркүләм кул эшләре күргәзмәсенә дә китте.

Әниебез үзенең һөнәрләрен минем хатыныма һәм кызларыма да өйрәтеп калдырды. Кызларым, Нурлатка каникулларга кайткан вакытларында, дәү әниләреннән бик күп тор-

мыш дәресләре алып китәләр иде. Хатыным тегү машинасында бик оста тегәргә өйрәнде, ыргак белән чигәргә яратты. Аның куллары белән эшләнгән идән паласларына гомер буе кинәнеп яшәдек.

Әнә шулай итеп, тормыш күнекмәләре, кул эшләре серләре өлкән буыннан яшьләргә күчә барды. Шөкер, кияүләрем дә уңганбулган кешеләр булып чыкты. Икесе дә кечкенәдән хезмәт тәмен аңлап яшәгән гаиләләрдә үскәннәр. Ир кеше белергә тиешле һәр хезмәт таныш аларга: агач эшен дә, тимер эшен дә яхшы беләләр.

«Төп йорт»та катнашыр өчен иң зәвекълы, сыйфатлы кул эшләребезне барладык. Иң беренче чиратта, әнием истәлеге булган «Көймәдәге кыз» һәм «Яр буе» картиналарын сайлап алдык.

Гаиләбезнең кул эшләре күргәзмәсендә мулине, сәйлән кулланып чигелгән, элеккедән сакланып калган чигешләр дә, яңалары да күп иде. Хатыным чиккән сөлге белән күлмәк тә күргәзмәбезне бизәп торды.

Кызым Гүзәл фестивальгә балаларны да бик нык әзерләгән иде, оныкларыбыз Самира белән Роберт фестивальдә безне урап алган халыкка җептән талисман-курчак үрү дәресе бирде. Ә без – җиде яшьлек оныгым Роберт, киявебез һәм мин лобзик белән агач эшләнмәләр ясау серләрен аңлаттык.

Әлеге фестиваль безгә иҗади яктан дөрес юнәлештә баруыбызны дәлилләп күрсәтте. Кайткач, кызым Гүзәл тәкъдиме белән, әниебезгә хөрмәт йөзеннән, аның кулы белән болгар җөе стилендә чигеп ясалган, югалган «Тавис кош» картинасына тиңдәш зур күләмле чигү эше башкарырга тиешбез, дигән карарга килдек. Әмма кибетләрдә тавис кош рәсеме төшкән чигү үрнәкләре юк булып чыкты. Шуңа да карамастан, безнең омтылыш һәм тәвәккәллекне күреп, бер кибеттә тавис кош сурәтле чигү үрнәге ясарга заказ алып калдылар.

Ул арада оныкларым китапханәдән кул эшләренә өйрәтүче китаплар алып кайтканнар.

Шулай итеп, «Төп йорт» фестивалендә катнашып, мин үземнең күңелемә чын-чынлап хуш килерлек шөгыль таптым: декоратив-гамәли сәнгать белән шөгыльләнә башладым.

Минем һәм кызларым, кияүләрем, оныкларым бергәләп ирешкән һәр уңыш – эти-әниләребездән килгән төпле тәрбия нәтиҗәсе ул. Әтиемнең «Һәрвакыт алга барырга тырыш!» дигән сүзләре яшәвемнең төп кагыйдәсенә әйләнде. Мин аны балаларыма, оныкларыма да кабатлыйм.

Рәфикъ ХӘСӘНШИН,
Нурлат.

Гали РӘХИМ



Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты



Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге «Фәнни фикер истәлекләре» сериясенең чираттагы басмасын дөньяга чыгарды. Бу басмада күренекле галим, язучы, тәнкыйтьче Гали Рәхимнең (Габдерәхимов Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улының) (1892–1943) татар фольклорына, әдәбиятына һәм төбәкне өйрәнүгә кагылышлы хезмәтләре урын алды.

Җыентыкны төзүчеләр – филология фәннәре кандидаты М.И. Ибраһимов, филология фәннәре кандидаты А.М. Гайнетдинов; фәнни мөхәррир – филология фәннәре кандидаты, доцент Ф.Х.Җәүһәрева; рецензентлар – филология фәннәре докторы, ТР ФА мөхбир-әгъзасы Т.Н. Галиуллин, сәнгать белемнәре кандидаты Э.Р. Каюмова.

Әлеге җыентыктан басмабыз өчен сайлап алынган хезмәт укучыларыбыз өчен кызыклы һәм файдалы булыр дигән өметтә калабыз.

Бертөрле дә күршеләрнең тәэсиренә бирелмәгән, бары үз тормышы эченә генә батып утырган борынгы төрек халыкларын тарихи бер хакыйкать итеп тасвир итәргә мөмкин булса да, ул эш тарих гыйлеме күз карашыннан дөрес булачак түгелдер; чөнки моның өчен шундый бер караңгы, борынгы заманга чумарга кирәк булыр иде ки, ул заманнан тарихи дәвергә кадәр ни бер мәнбәгъ (*чыганак*), ни дә бер мәгълүмат сакланып калмаган. Дөрес, әсәре гатика (*борынгы*) фәне актарып чыгарган каберләрдән, курганнардан табылган беркадәр нәрсәләр бар; ләкин ул курганнарның, бер яктан, төрекләрнеке икәне тәмам исбат кылынып җитмәгән, икенче яктан, ул курганнар, каберләрнең һәм аларда табыла торган нәрсәләрнең тарихы (хронологиясе) тәмам тәгаен кылынып та бетмәгән әле; шуның өчен болардан алынган мәгълүмат белән төрекләрнең иң борынгы замандагы тормышларын мөҗәррәд (*гади*) иттереп тасвир итү гыйльми яктан хата булачак.

Европа голәмәсенең күбесе шикелле Европа археологиясене истинадан (*аерып алганнан*) һәм хәзерге вәхшиләрне тикшергән соңында, борынгы төрекләр һәм аларның кардәшләре монголларның тарихи дәверләрендәге «искелек калдыклары» буенча борынгы төрекләрнең тормышын тасвир кылуда шактый хата булырга мөмкин. Бу ысул белән барганда бераз хакыйкатькә якын килеп булса да, аның биргән бөтен нәтиҗәләрен катгый хакыйкатькә хисаплау да зур ялгышлык булуы һаман да истисна ителми (*чыгарма булмый*). Ләкин бу мәсьәләне тикшерү өчен мөаррихнең (*тарихчының*) кулында бер газамәтле (*олы*) корал бар ки, ул да булса тел фәнедер. Бу юл белән барып, хәзерге төрекләрнең төрле кавемнәрендә булган уртак сүзләрне җыеп, шул сүзләргә истина-

дан борынгы төрекләрнең тормышын тасвир итәләр. Бу корал белән ар җенесенә мәнсуб булган (*билгеләнгән*) халыкларның тормышына даир (*караган*) күп нәрсәләр кәшеф кылынып (*ачылып*), кайсысы тәмам хакыйкать дәрәҗәсенә килгән инде; ләкин хәзергә кадәрле төрекләрнең телләрен тикшерү мәсьәләсе әле ибтидаи (*башлангыч*) дәрәҗәдә тора; аны тикшерүдән соң тормыш тасвирларын бирү хакында моңарчыга кадәр бары Вамбери[1] тарафыннан гына бер тәҗрибә ясалган.* Әгәр инде бик борынгы төрекләрнең тормышын, гомумән, тасвир кылуда шактый уңайсыз булса, шул ук төрекләрнең фикри хәятләрен, аларның ышануларын тасвир итү тагы да читенрәк бер эштер.

Төрек халкының тарихка мәгълүм булган борынгы заманы патриархат тормышыдыр. Дөрес, ул патриархат тормышында хатыннарны хөрмәт олы хатын һәм аналарның гаиләдә зур рольләре шикелле фактларда матриархат тормышының калдыклары күренсә дә, тарих төрекләрнең чын-чын матриархат тормышы белән торган чакларын белми. Шулай итеп борынгы төрекләр өчен патриархат һәм күчмәле тормыш бер тип булган иҗтимагый һәм икътисади хәяттер (*тормыштыр*). Шул икътисади һәм ул китереп чыгарган иҗтимагый халәтнең таләп кылуы буенча аларда шушы тормышка мөнасиб (*яраклы*) рухи һәм фикри бер хәят тә хөкем сөрде.

Борынгы төрекләрдә әле тарихи дәвердә дә хөкүмәт төзелеше бер катгыять (*катгыйлык*) алып китмәде. Күчмәле тормыш таләп кылуы аркасында чыккан көтү җирләрен (*утлавыкларны*) ыруглар арасында тигез һәм бер мәгълүм микъдарда бүлү, ачлыктан гаҗиз булгач, сахраларны ташлап мөнбит (*уңдырышлы*) җирләргә күчү аркасында туган яисә Кытай, Иран монархияләренең аларны икътисади эксплуатация өчен тәҗавезләре (*басып керүләре*) аркасында чыккан сугышлар төрекләргә бик борынгы заманнарда ук дәүләтләр ясарга ярдәм итте. Ләкин бу сахра империяләре һаман, икътисад таләп кылган сәбәпләр беткәч тә, кире сүтелеп, тәхлил кылынып (*бозылып*), төрекләр кире ыруг һәм кабиләләргә бүленеп тордылар**. Димәк, борынгы төрекләр 18 нче гасыр башкортлары һәм хәзерге кыргызлар күк ыруг тормышы белән тордылар: боларда хакимият тә шулай ук ыруг башлыклары кулында булды.

Мәгълүм ки, адәмнәр мәгъбүдләрне (*гыйбадәт кылынган затларны*) үзләренә охшатып ясыйлар; шуның өчен без борынгы төрекләрнең диннәренең әсасләрендә пантеизм ягъни бөтен табигатьне җанландырып табыну һәм сансыз күп мәгъбүдләргә яисә тәңреләргә ышануны күрәбез. Тәңреләргә ышану исә җир һәм күкнең бөтен көчен мәгъбүд ясаудан гыйбарәттер. Затән (*үзе*) «тәңре» дигән сүз, Вамберинең фикеренчә, «таң» (*яктылык*) дигән тамырдан алынган***. Ләкин борынгы төрек пантеизмын сөйләгән чакта, аларның бу тәңреләргә ничек итеп ышанулары хакында катгый бер сүз әйтүе уңайсыз. Мәгълүм ки, мәдәниятнең түбән дәрәҗәсендә торган халыкларның мантыйкы һәм аларның тойгылары безнеке төсле үк булмый. Шуның өчен безнең алардагы игътикад (*ышану*) һәм фикерләр хакында сөйләгән һәр сүзебез тәхмини (*якынча*) генә булып, мәдәни кешенең акылыннан кайнап чыккан бер хыял гына булачактыр. Шулай да төрекләр тәңреләрне, һәрбер аерым вакыйгада иштирак (*уртак*) булулары сыйфаты белән, аерым мәгъбүдләр итеп танысалар, икенче яктан, тәңреләр бөтен галәмгә, комга сеңгән су шикелле, сеңеп киткәнлекләреннән, табигатьне бер мөҗәррәд (абстрактный) мәфһүм (*аңланган нәрсә*) рәвешендә тәңре санап яисә бөтен тәңре белән тулган галәмне мәгъбүдләр рәвешендә берләштереп аңлап, «тәңре» яисә «җир-су» дип тә аташтыргалаганнар.

Гомумән, борынгы вәхшиерәк халыкларның диннәрендә бер система эзләү – хата бер эштер. Алардагы дини тойгы акылларның бергә кушылып хәрәкәт итүеннән гыйбарәт була. Шуның белән бергә, бер үк кавемнең төрле кабиләсе һәм ыруглары төрле икътисади халәттә торып, дини тойгылары да шул мөнәсәбәттә төрле-төрле булырга мөмкин. Шуның өчен төрле икътисади халәттә торган күчмә һәм ярым утрак төрекләрнең диннәрен гомумиләштереп, бер системага салырга азаплану – фәнни яктан ялгыш бер эштер. Бит борынгы юнаннар Татарстанның бер кантоны кадәрле кечкенә генә җирдә һәммәсе тәхминән (*якынча*) бер төсле тормыш белән торсалар да, аларның диннәрен дә бер системага салу шактый читен бер эш булды. Шуның өчен без төрекләрдә бөек дәүләтләр ясалу дәверләрендә, бәгъзы вакытта аларның хыялларында үзләренең сәяси тормышларына кыясән**** (*чагыштырып*) ясалган мөселман Алласы сымак, «хан тәңре»не дә очратабыз. Мәсәлән, мәдәниятнең түбән дәрәҗәсендә торган 19 нчы гасырның мәҗүс чувашларында «зивади тора»*****, ягъни бөек тәңре, орхон төрекләрендә «ил бирүче тәңре» бар иде[2].

Борынгы төрекләрнең мифологияләрендә дә, нәкъ борынгы бабиллылардагы күк, югарыдагы күк белән түбәндәге җир кушылганнар да, шулардан кешеләр яратылганнар[3].

Тәңре, Җир-судан башка борынгы төрекләрдә без башка мәгъбүдләрне дә очратабыз. Болар шул тәңреләрнең «сыйфатлары» гынамы, әллә аерым мәгъбүдләрме, билгеле, аны хәл итү, югарыда сөйләнгән сәбәпләргә бинаән (*таянып*), читен. Мәсәлән, Алла мәгънәсендә уйгырчада «укан», чыгытайчада «уган» сүзе бар. Әгәр бу мәгъбүдләр баш тәңренең бер сыйфаты шикелле генә булсалар, бу сүзләр «укмак» масдарыннан (*тамырыннан*) алынганга күрә, «бөтен нәрсәне белүче, аңлаучы» мәгънәсендә булалар. Шулай ук уйгур телендә «баят» яисә «бият» дигән Алла исеме бар. «Бай, би» «югары» мәгънәсендә булганга моны «бөтен нәрсәдән югары» (Всевышний) дип тәрҗемә кылырга кирәк була. Уйгур һәм алтай төрекләрендә «мәнге, мәнкү» дигән исем дә очрый. Бу сүз күп вакытта «тәңре» сүзенә кушылып монголларда «манчу тәңре» рәвешендә йөртелә. Гомумән, академик Бартольдның фикеренчә, «тәңре» мәфһүме астында төрекләр матди күкне ирад иткәннәре (*күздә тотканнары*) төсле, мәгънәви күк, ягъни мәгъбүдне дә аңлыйлар иде. Хәтта төрекләр 11 һәм 12 нче гасырларда да күкне мәгъбүдләштереп ышаналар; шул сәбәпле, мөселман Иран мөәррихләре төрекләрнең «күк-тәңре» дип ике бер үк мәфһүмне кушып әйтә торган сүзләрен «күк тәңресе» дип аңлап, төрекләр күкнең аерым бер алласы бар дип ышаналар, дип йөриләр иде. Орхон язулары дәверендә[4], инде төрекләрнең сәяси бер дәүләт ясаган заманнарында, «төрек тәңресе»[5] дигән мәфһүм дә хөкем сөрәдер иде******.

Бу вакыйга бәни Исраилнең «Исраил – Яһва халкы, Яһва – Исраил алласы» дигән игътикадына бик охшый. Менә шуның өчен дә 18 нче гасырда төрек-монголларга сәяхәт кылучы Рубрук[6] һәм Планукарпини[7] мәсьәләне католик акылына салып үлчәп, «алар бер аллага ышаналар», дип ышанып кайттылар. Госманлыларда «чалаб» дигән тагы бер мәгъбүд исеме очрый. Әгәр бу сүз, Вамбери әйткәнчә, «чал» һәм «аба» (ата) дигән сүзләрдән мөрәккәб (*кушылган*) булса, ул чакта бу мәгъбүднең башта бабайлар рухын мәгъбүд итеп танудан гыйбарәт булганын күрәчәкбез.

Шулай ук борынгы төрек әдәбиятында тагын бер төрле мәгъбүд исемнәре бар; алар исә хәзер дә безнең татарларда да очрый торган «ия»ләр[8]. Бу уйгурларда «ите, иде», чыгтайчада инде «иде, әгә, игә» формасында истигъмаль ителә (*кулланыла*). Алтай татарлары, әле дә безнең Идел буе татарлары шикелле, «ту әясе» (тау иясе), «иш әясе» (урман иясе), «су әясе» бар, диләр. Шулар белән бергә борынгы төрекләрдә «умай» исемле йорт мәгъбүде дә бар[9].

Моңарчы сөйләнгән мәгъбүдләр – һәммәсе дә яхшылык китерә торган «хәер» мәгъбүдләре. Ләкин төрекләрнең мәгъбүд галәме хәерлеләр белән генә бетми. Башка пантеистлардагы шикелле, аларда начарлык, явызлык (шәрр) мәгъбүдләре дә бар. Мәсәлән, шулардан берсе, «әрлик» яисә «әрник» дип аталган җир асты мәгъбүде, бездәге «өрәк» белән бер булган[10]. Алтайлыларда «өрәкән», чыгтайда «ирәк», маҗарларда «өрәк» исемле яман мәгъбүдләр очрый. Болардан котылу өчен корбан яисә сәдака бирергә кирәк*******; аларны ничек булса да үзеңә якынайтырга, зарарсызландырырга кирәк. Ләкин алар белән дуслашырга һәм мөнәсәбәткә керергә һәркем дә булдыра алмый. Аларны «баглар» яисә «бәйләр» өчен аерым догалар яисә «арбаглар» (ар – көч, баг – бау) кирәк. Бу эшләрне «кам» яки «кам хатын»нар яисә «баксы»[11], «багучы» һәм «күрәзәләр» генә эшли алалар. Болар гына «багны чишә» алалар, болар гына, һәр нәрсәне алдан «багып-күреп», мәгъбүдләрнең зарарларыннан халыкны һәм кешене котылдыра алалар; болар гына кешенең «котын» (җанын) яман көчләрнең шәрреннән «коткара» һәм «котыру»дан саклап кала яисә шуннан сәламәтләндерә һәм кешене «котлуг» (бәхетле) итә алалар[12].

Димәк, борынгы төрекнең идеологиясе, аның фикри хәяте бик садә: бөтен табигать – Алла. Ул «Җир-су» (галәм) кешеләрне яраткан. Ләкин шул «котлы» (җанлы) галәм эчендә яман һәм яхшы көчләр бар. Менә шулар адәмнәр өчен бер-берсе белән мөттасил (*туктаусыз*) көрәшәләр. Адәм бөтен гомерен начар көчләр белән көрәштә үткәрә. Ләкин яхшы көчләр аңа ярдәм итәләр. Шуның аркасында бөтен галәмдә туктаусыз низаглар бара, тартыш хөкем сөрә.

(Җәяләр эчендәге аңлатмалар Айдар Гайнетдиновныкы)

* Vambery. Die primitive Kultur der Turko-Tatarichen Volkes. – 1879.
**Моның бик матур мисалларын Радлов «Кудатку белек»кә (*«Кутадгу билик»кә – А.Г.*) язган мөкаддимәсендә китерде. Das Kиdatku Bilik (Einleitung) и «К вопросу об уйгурах».
*** Vambery. Die primitive Kultur der Turko-Tatarichen. Volkes. – 1879. G. 240.
**** Соңгы елларда Ашмарин кайбер борынгы мәҗүс чуваш мәгъбүдләренең исемнәре Алтын Урда чиновникларының исемнәре белән бер икәнен исбат итте.
***** Тәңре (тәре)дән мөнхәрәф (алынган – А.Г.) булса кирәк. Вамбери, 241 сәхифә.
******Bartold, Die Historische Bedeutung der Altturkischen Jnschriften.
*******Vambery. Die primitive Kultur der Turko-Tatarichen Volkes. – 1879. – s. 246

[1] Арминий Вамбери (1832-1913) – көнчыгышны өйрәнүче Венгрия галиме, «Урта Азия буенча сәяхәт» дип аталган популяр китап авторы. Русиядә яшәгән мөселманнар мәдәнияте белән кызыксынган. (...)
[2] Г. Рәхимнең Казан татарлары фольклоры хакындагы лекцияләрендә моның турында түбәндәгечә язылган: «Орхон язмаларында, күк йөзе – хакимият бирүче, дип әйтелгән. Кешеләрнең һәм илнең язмышы, хәтта ханнар язмышы «төрек тәңресе» кулында» (Мирасханә: ф.18, тасвир. 1, сакл. берәм. 32. – Б. 52).
[3] Казан татарлары фольклоры хакындагы лекцияләр стенограммасында моның турында түбәндәгечә язылган: «Борынгы төркиләрнең космогония фәне буенча, иң беренче булып күк йөзе барлыкка килә. Күкнең ничек, кем тарафыннан ясалганы билгесез.
Аннан соң җир ясала. Алар арасында кешеләр барлыкка килә. Гадәттә, борынгы төркиләр күк йөзен ир-ат җенесендә булган алла итеп, ә җирне хатын-кыз җенесендә итеп күзаллыйлар. Бәлки, әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсә күк йөзе һәм җирнең җенси мөнәсәбәте
аркасында барлыкка килгәндер дә, шул исәптән кешеләр дә. Шулай итеп, төрекләрнең галәмнең барлыкка килүгә карашлары бүтән борынгы халыкларныкы белән (мәсәлән, ассиро-вавилоннар) тиңдәш дияргә мөмкин». (Мирасханә: ф. 18, тасвир. 1, сакл. берәм. 32. – Б.501арты.)
[4] Галимнәр тарафыннан Орхон үзәнлегендә табылган эпиграфик истәлекләр чоры күздә тотыла (б.э.к. VIII гасыр, Икенче төрек каганаты).
[5] Казан татарлары фольклоры турындагы лекцияләр стенограммасында моның турында түбәндәгечә язылган: «Шул ук язмалардан (орхонныкылардан – М.И.) күренә: төркиләр үз аллаларын, хәттә иң югары «тәңре»не, бары тик үз халыкларына гына хас, дип уйлаганнар. «Тәңре»не «төрек тәңре», ягьни «төрек күк йөзе» дип атаганнар...». (Мирасханә: ф. 18, тасвир. 1, сакл. берәм. 32. – Б. 55 арты).
[6] Гильом де Рубрук (якынча 1220-1293) – фламанд францискан монахы, француз короле Людовик IX кушуы буенча, 1253-1255 елларда монголлар янына сәяхәт кыла, «Көнчыгыш илләренә сәяхәт» китабы авторы.
[7] Джованни Плано Карпини (якынча 1182-1252) – Италия францисканы, европалылардан иң беренчеләрдән булып Монгол империясенә килеп, үзенең сәяхәтен «Татарлар дип аталган Монголлар тарихы», «Татарлар турында китап» (лат. «LiberTartarorum» кульязмаларында тасвирлаган).
[8] Ия (хуҗа) – төрки телле халыклар мифологиясендә билгеле бер урынга бәйләнгән рухлар атамасы. Татар мифологиясендә «ия» – табигать, торак урыны белән бәйле булган аерым категорияле рухлар: су иясе, өй иясе, шахта иясе һ.б.
[9] Умай – борынгы төрки халыклары мифологиясендә хатын-кыз, уңдырышлылык башлангычын гәүдәләндерүче алиһә. Умайга ышану калдыклары кайбер төрки халыкларда сакланган. Мәсәлән, кыргызлар, Умай мул уңыш һәм мал-туарның артуын китерә, гаилә учагын, балаларны саклый, дип ышанганнар.
[10] Өрәк – татар мифологиясендә үлгән кешенең рухы. Ышануларга караганда, кешеләр үлгән, кан агызылган җирдә яки күмү урыннарында яши. Кеше сурәтенә яисә болыт, ут өермәсе кыяфәтенә керергә мөмкин. Казан татарлары фольклоры турындагы лекцияләр стенограммасында бу хакта түбәндәгечә язылган: «Хәзер бүтән рухка, шулай ук кешеләр белән тыгыз элемтәдә торган рухка күчик. «Өрәк» элекке вакытлардагы төрек телендә, бәлки, җан мәгънәсендә булгандыр. Шуңа күрә, һәрбер кешенең «өрәге» булырга мөмкин, ләкин хәзерге вакытта татарларда җан «өрәк сүзе белән аталмый. Мөгаен, «җан» сүзе телгә кергәнче, «өрмәк» (өрү) тамырыннан килеп чыккан «өрәк» сүзе кулланылгандыр. Хәзерге татарлар мифологиясенә караганда, «өрәкләр» тәүбәгә килмәгән кеше җаннары буларак күзаллана, ягьни, хуҗа үлгәннән соң, алар җир буйлап сыеныр урын һәм тынычлык таба алмыйча йөриләр. Гадәттә, болар – үз үлемнәре белән үлмәгән кеше җаннары.(...) (Мирасханә: ф.18, тасвир. 1, сакл. берәм. 32. – Б. 108-109 арты).
[11] «Кам» һәм «баксы» – алтай төркиләренең һәм кыргызларның шаманнары исемнәре.
[12] «Кот» сүзе татар телендә мифологик күзаллауларга тоташа, алар нигезендә, кешенең җаны гәүдәдән кош кебек китә, дип санала. Бу күзаллаулар бер рәт идиоматик гыйбарәләрдә сакланган, мәсәлән, котым очты, котым ботыма төште – болар иң соңгы дәрәҗәдәге курку хисен белдерәләр. «Коткару», «котыру», «котлы» кебек хәзерге татар теле сүзләренең «эчке формасын» автор бирелгән фрагментта «кот» сүзе белән бәйли. Казан татарлары фольклоры турындагы лекцияләрендә Г. Рәхим болай ди: «Күп төрки телләрдә «кот» «бәхет» мәгънәсендә кулланыла. Татарларда да шулай. Мәсәлән, котлаганда татар кешесе «котлы булсын», ди. «Котыру» сүзе «шашыну», «җенләнү»не аңлата, котырынган кешенең эченә «кот» кергән кебек була. Төркиләрдә шул ук тамырдан «коткару» сүзе ясалган». (Мирасханә: ф. 18,тасвир. 1, сакл. берәм. 32. – Б. 62 арты).

(Дәвамы бар)

Чыганак: Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр. – Казан: «Ихлас» нәшрияты, 2018, 170-180 битләр.

Илсөяр ИКСАНОВА

Шигъри җанлы абыстай

«Халык зур ул, көчле ул, шагыйрь ул, әдип ул!» Шөкер, Тукаебызның әлеге шигырь юлларын безгә бик еш кабатларга туры килә. Милләттәшләребез яшәгән кайсы якка гына барып чыксак та, халкыбызның күңел байлыгына, тел җорлыгына, рух чисталыгына сокланып кайтабыз. Мари иленең башкаласы Йошкар-Ола шәһәрендә гомер итүче Самавия апа Сафиуллина белән танышкач та күңелне соклану хисләре биләп алды. Иң сокландыргнаы – аның һәр вакыйганы йөрәгеннән үткәреп, үзенчә бәялэп, фикерләрен шигъри юлларга салып баруы. Бу шигырьләрне чорыбызның елъязмасы дисәң дә була. 1929 елда туган Самавия апа илебездә барган бик күп вакыйгаларны үзе күргән, үзе кичергән: ачлыгын да, репрессия елларын да, сугыш чорларын да. Сугыштан соң илне күтәрү, себер шахталары, илдәге бетмәс-төкәнмәс үзгәрешләр һәм шул үзгәрешләр эчендә гади татар кешесенең кичергәннәре һәм кичерешләре... барысы да чагыла аның шигырьләрендә.

– Нәрсә күрәм, шуны язам инде, – ди ул үзе көлеп. – Тормышыбызда, җәмгыятьтә нинди кимчелек бар, барысына үз фикеремне белдерәм. Ул әхлаксызлык, кеше кадере бетү, табигатькә вәхшиләрчә караш! Бөтен җирне чүп басты – кая карама пластмасса, урман бетә, кырлар чәчелми – басуда хәзер җиләк кенә түгел, гөмбә җыялар. Йөрәгемне әрнетә шулар.

Яшьтән үк каләм кыштырдатсам да, язудан бик озак аерылып тордым мин. Апам Дания укытучы иде, аңа план тутырырга калын дәфтәр биргәннәр. Бәрәңге педучилищесында укыганда шул дәфтәргә бик күп шигырьләр яздым. Күбесе патриотик шигырьләр инде: Чапаев, Зоя Космодемьянская, Калинин, совет власте турында... Ул дәфтәрнең тышына Пушкин портреты төшерелгән иде. Шунда Пушкинның бәдрәсенә «Долой СССР!» дип язылган булган икән. Дәфтәрне «изәт иттеләр». (Безнең авылда Изәт дигән кеше бар иде, шуңа «изъять» дигәнне «изәт» дип йөрдек.) Бик куркыныч чаклар иде бит, апам да курыккандыр инде, дәфтәрне кире кайтару артыннан йөрмәгән. (Берәр җирдә истәлеккә калды микән ул дәфтәр?) Шуннан соң беттем мин, нигә кирәк инде миңа, дип башка язмадым.

Озак еллар үтте, мин инде Кузбасста тора идем, әни үлгәннән соң апам әйтә: «Әйдә, син дә әни турында шигырь яз, мин дә язам», – ди. Ул да шигырьләр яза иде. Икебез дә яздык, бер-беребезгә хат белән җибәрдек.

Әниебез Гөлбикә кырыс холыклы иде, мәрхүм. Хәзер генә аңлыйм, әти тәрбиясендә генә үскәнгә шундый булган инде ул. Әнинең әнисе җиденче баласын тапканда үлгән. Бабам җиде бала белән тол калган.

20 яше тулгач, бабай әнине кияүгә бирәм дигән. «Әтигә каршы бер сүз әйтә алмыйбыз инде, – ди әни. – Мәйлең, дидем». Әнинең

1950нче ел.

Сахрага чыккач.

үзенчә яратып йөргән Хафиз атлы егете дә булган инде бу вакытта. Яратышу шул инде, чишмәдән судан менгәндә, егет кызга хат тапшырган, аннан кыз сыер саварга чыккач, абзар тәрәзәсеннән кулын сузып, кулларын тотышып торганнар.

«Кияү килә, кияү килә!» дигән тавышка, әни тәрәзәдән караса, тарантас башында бер егет утыра, тарантаста бер кеше җәелеп утыра, ди. Әни тарантас тоткан егетне уйлап, Аллага шөкер, әтием егет кешегә бирә икән, дип сөенгән. Күрештереп тормаганнар бит элек, кәләш бер якта, кияү икенче бүлмәдә. «Риза булып бардыңмы?» дип кенә сораганнар да, никах укыганнар.

Кемгә барганын әни кияү өенә кайткач кына аңлаган. Егетләр өйдән чыгып киткәннәр, 44 яшьлек ир уртасы гына калган. Тарантас тоткан егет әтиебез Сибагатулланың әни белән яшьтәш улы булган икән. Хатыны үлеп, өч малай белән тол калган сәүдәгәр булган әти. Аулакта калгач, кәләштән чәй куюын сораган. Әнинең самавырга үрелүе булган, кияү дигәнең артыннан кочып та алган... Әни 15 чакрым араны яланаяк чабып туган йортына кайткан. «Чәч толымыңнан атка бәйләрмен дә, бер атка, бер сиңа сугармын, кайтып кит тизрәк ирең янына! Туйганчы ипи ашадың мени!?» – дип куып җибәргән бабай.

Инде матур гына яшәп киткәч... революция. Әти бик озак колхозга кермәгән. Малларын алып бетергәннәр. Соңгы абзарны сүтеп алырга килгәч, әни түзмәгән, балта тотып чыккан...

Колхоз эше барыбызга да җитте инде. Әле хәтерлим, өйдә мич чыгарабыз. Әни эштә, мин кирпеч биреп торам. Мин кечкенә инде, мич өелеп менгәч, минем буем җитми башлады. Икенче көнне, яңа мичтә табикмәк тә пешерәсе булыр, дип, әни калды кирпеч биреп торырга. Мин әни урынына уракка киттем. Уракның да рәтен белмим бит инде, дәртләнеп ура гына башлаган идем, бармакны кистем дә өздем...

Әни турында язганда шуларның бөтенесен исемә төшердем.

– Ә Кузбасска ничек барып эләктегез?

– Язмыш. Үзем Бәрәңге районында кечкенә генә Пүчинкә авылында туып-үстем мин. Куянавыл мәктәбендә укыдым. Бәрәңге педучилищесын тәмамлагач, Хлебниково районы (Хәзер Мари-Төрәк) Түнтәр авылына укытучы итеп җибәрделәр. Йөргән егетем үзебезнең якта калды. Аның икенче кыз белән чуалганын сиздем дә: «Миңа башка хат язма, кияүгә китәм», – дип хат салдым. Язуын яздым да... кемгә китәргә? Шул чакта авылга Гатиятулла атлы егет кайтты. Аның турында мактап сөйләгәннәрен ишеткәнем бар иде инде. Армиядән соң Кузбасска, ФЗУда укыган энесе янына барып эшләргә ниятләгән. Авылга бер кайтса, чыгып китә алмый, колхозда бушка эшләтәләр ул чакта. Егеткә өйләнеп китәргә кирәк. Вакыт бик аз. Беренче кат күрештек моның белән. Кичтән сөйләштек, иртән авыл Советында язылышырга кирәк. Миңа 22 яшь бу вакытта. Шулай, егетемә ачу итеп, кулымнан да тотып карамаган кеше белән язылыштым да куйдым. РОНО мөдире: «Кыш уртасында балаларыңны кемгә калдырасың?!» – дип, бик ачуланды, шулай да гаиләле кешене җибәрми кала алмадылар инде. 45 ел бик бәхетле гомер иттек ирем белән. Кулыннан килмәгән эше юк иде аның. Ике бала үстердек. Икебез дә сәяхәт итәргә ярата идек. Урманнарда йөрү, сахраларга чыгудан да ямь таптык. Тормышны яратып яшәдек. Шахтада эшләгән кеше гомернең кадерен белә инде; бик күп кеше үлде шахтада. Картым, эшкә җыенганда көн дә бәхилләшеп: «Алай-болай булсам, авылга күмәрсең», – дип китә иде. «Минем өчен сугыш шахтага киткәч башланды», – дия идем үзем уенын-чынын бергә кушып. Картым эштә 15 минутка тоткарланса, тәрәзәдән-тәрәзәгә йөреп, авыруга сабышам...

1952 елда киткән идек, 1986 да кайттык Кузбасстан. 34 ел күмер суладык – һава кап-кара иде анда. Картым монда кайткач, 1995 елда вафат булды. 53 яшендә улыбыз да дөнья куйды. Кызыбызны Новосибирскида институтта укыганда практикага шул яктагы бер районга җибәргәннәр иде, шунда урыс

Туган якка сабантуйга кайткач.
Уңнан икенче – Самавия апа.

кешесенә кияүгә чыгып калды. Шунысы бик кыен.

– Сезнең турыда, Корбан бәйрәмендә һәр елны 70-80 кеше җыеп кафеда Коръән ашы үткәрә, дигәннәр иде. Моның бер-бер сәбәбе бармы?

– 2011 елда әниемнең вафатына 30 ел булды. Шуңа 30 кеше чакырып Коръән укытасым килгән иде, өйгә ул кадәр кеше сыймый, 15 кенә кеше чакыра алдым. Үпкәләп калучылар да күп булды. Шуннан үзебезнең Татар үзәгенә шылтыраттым. Рәхмәт яусын, урынын таптылар. Ел да зурлап Коръән мәҗлесе үткәрә башладым. Кызым да ел саен Корбан бәйрәменә кайта. Анда урыс арасында уразасын да тота алмый бит инде ул, аның өчен мәчеттә авыз ачтырам.

– Дин юлына ничек кереп киттегез? Сез бит атеизм чорында яшәгән буын...

– Әти-әнием намазлы иде минем. Әтием Коръән дә чыга, мәетләрне дә озата иде, гел укыды. Әнием ятим үскән, уку эләкмәгән инде аңа, Мәңгәр дигән авылда мулла баласын караган. «Абыстай кызларны укыткан бүлмәгә, бер генә хәреф булса да өйрәнер идем, дип бала белән кереп баса идем. Юк, куып чыгара бит...», – дип әрнеп сөйли иде әнием.

Балачакта азан ишеткән кешеләр бит әле без. Аннан, Түнтәрдә укыткан чакта фатир хуҗам намаз иясе иде, ул да догалар өйрәтте. Кузбасста яшәгәндә дә үзем белгәннәрне укый идем. Инде 90нчы елларда дөньялар үзгәргәч, газета-журналларда гарәп хәрефләре чыга башлады. Мин үзлегемнән өйрәнергә тотындым. Бервакыт шәһәребездә татар концерты булды, концерттан соң Әлфия абыстай – безнең беренче абыстаебыз – «Кем намаз укырга тели, керегез бу бүлмәгә», – диде. Шунда кереп намаз укыдык. «Сентябрь аенда укырга килегез», – диде абыстай. Март ае иде бу. Бер өйрәнә башлагач, кая сентябрьне көтеп торам инде мин! Бардым абыстай янына. Берике ай уку белән, мине укытырга да куйды ул. Шулай кереп киттем. Хәзер Коръән дә чыгам, ашларда вәгазьләр дә сөйлим, намаз уку мәсьәләләрен дә аңлатам. Аллага шөкер, берничә кешене намазга бастыра алдым.

– Педагоглык сәләте инде бу...

– Укытучы булып озак эшли алмадым шул. Укытасым килә. Менә хәзер дә, туган телне укыту тирәсендә барган ыгы-зыгыны күзәтеп: «Их, 8 елга гына яшьрәк булсам, 80 дә генә булсам да, татар телен укытыр идем әле», – дип утырам. Ике сәгать дәрестә грамматика өйрәнеп булмый инде. Нинди методика белән укытырга, ничегрәк итеп сөйләм телен өйрәтергә, дип уйланып, планнар корып карыйм. Уен формасында, кызыклы итеп укытыр идем дип уйлыйм.

– Сездә педучилищеда укыган чордан сакланган кызлар дәфтәре дә бар дип ишеткән идек.

– Минем белән бергә укыган Майбәдәр исемле кызның дәфтәре ул. Портянур авылында яшәгән Майбәдәр шул дәфтәрне гомере буена саклаган бит. Ул дәфтәрне кулыма алгач, еладым. Яшьлек дәфтәрен укыгандагы уйларымны, хис-кичерешләремне «Яшел дәфтәр серләре» дигән истәлек язмама теркәп куйдым. Дәфтәр хәзер Фирзиядә саклана.

Самавия апа безне бирегә алып килгән Фирзия ханым Сабирҗановага ымлады. Мари Эл республикасында татар иҗтимагый тормышында кайнап, халкыбызның мәдәниятен саклау, үстерү өчен җан атып йөрүче Фирзия ханымга без бик рәхмәтле. Истәлекле дәфтәрне ул безгә биреп үк җибәрде.

Без исә Самавия апаның кичерешләрен укучыларыбызга да җиткерергә булдык.

Самавия САФИУЛЛИНА

Яшел дәфтәр серләре

ОНЫТМАМ
Яшел болыннардан, күл буеннан
Мин чәчәкләр җыйдым бер көнне.
Чәчәкләрем шиңде, исе бетте,
Күз алдымда калды төркеме.

Аерылырбыз, дустым, озакламый,
Алар бездән ерак йөрмәсләр.
Аерылгач та, җан биргәнгә кадәр
Онытылмыйлар якын сердәшләр.

Күз алдымда тотам алсу йөзең,
Балкып торган зәңгәр күзеңне.
Аерылгач та, авыр тормышта да
Онытмаска бирәм сүземне.

Шулай, дустым, безнең тормышның да
Онытылыр кайбер яклары.
Ә истәлек, син утка якмасаң,
Бәлки, гомереңә сакланыр.

Бу кыска шигырьләрне дустым Майбәдәрнең яшел тышлы дәфтәренә язганыма 70 елга якын вакыт узып та киткән. Алар, 1945-1947 нче елларда туган рифмалы юллар, үзе бер тарих битенә әйләнеп өлгергән.

Үсмер чакта булдырылган иҗади язмалар яңадан кулыңа килеп керсә, бик дулкынландыра икән ул. Ике-өч ел элек мин дә шундый кичерешләрне башымнан уздырдым. Яшьлеге читтә узган кеше аңлый, олыгайган саен, узганнарны кайтарып алып булмаса да, туган якка, яшьтәшләргә, хезмәттәшләргә карата булган хисләр нечкәргәннән-нечкәрә бара. Аларны туганнарга булган тойгыга тиңләрлек. Үземнең дә, югарыда искә алган юлларны укып, бер яктан гаҗәпләнсәм, икенчедән, күзләремә яшь тыгылды.

Бәрәңге педучилищесында Майбәдәр Хәлирахманова (Шәрәфиева) белән, Куян ягыннан йөреп, без бер елларда укыдык. Ул чакта бар нәрсәне дә кулдан язып бардык. Техника заманы түгел, һәр нәрсә бик гади итеп язылды. Рәсемнәрне дә карандашлар белән генә буяп куябыз, ачыграк булсын өчен, карандашларыбызны төкереклә тә җибәрәбез. Шулай итеп истәлек дәфтәрләре тутырабыз. Безнең белән күрше район һәм Татарстаннан килгән кызлар да укыды. Тулай торакта сагындыра инде ул, әти-әни дә, башка туганнар да. Уку елларыбыз сугыш вакытына туры килгәч, һәрьяклап тыйнак булырга туры килде. Ачлык галәмәтен, авырлыкны үзебезчә күңел ачып, шигырьләр, истәлекләр уйлап чыгарып, читкәрәк этәргән кебек була идек. Барыбер ул еллар – безнең яшьлек хатирәләре.

Әле дә Майбәдәр белән искә алып утырдык. Япь-яшь килеш башка авылларда тулы хокуклы укытучы булып эшләдек. Без бик бәхетле булганбыз. Чөнки ул вакытта укытучы авылда төп фигура иде. Балаларның әти-әнисенә – өлкәнөлкән абый-апаларга – киңәшләр бирәбез. Класстан тыш эшнең дә торышын үзгәртәсе, укучыларга белемне дә тырышып бирәсе килә. Сәхнәдә дә без, колхозчылар белән дә булабыз. Яшьлек бит, гашыйк та булдык, шәхси тормышыбызны оештырырга да вакыт таба идек. Күбебез гомерлек язмышын эшләгән авылларында тапты. Ә Майбәдәрне олы мәхәббәте – хезмәттәше – мәктәбендә үк тапкан. Мөхәрләм белән тату яшәп, берсеннән-берсе матур җиде бала үстерделәр алар.

Шушы яшел тышлы дәфтәрне, яшьтәшем Майбәдәр кулыма тоттыргач, читкә үк китеп утырып, елый-елый укыдым. Булачак укытучы беренче биткә үк бик җыйнак итеп:

«Сез китәрсез, югалырсыз,
Монда исемегез калыр,
Монда язган кульязмагыз
Миндә мәңге сакланыр», – дип язып куйган.

Майбәдәр, шаярып кына тутырган дәфтәребезне әлегә хәтле саклый алгансың бит. Сүзеңдә торгансың, сокланырга гына кала синең җитди карашың белән.

Һәркайсыбызда диярлек мондый кулдан язылган истәлекләр җыентыгы бар иде. Тик үзебезнең җитешеп бетмәгән якларыбызны дөнья

мәшәкате белән каплыйбыз да куябыз. Шул рәвешле, саклапырга тиеш ядкарьләр юкка чыга.

Битләре тетелеп бетәргә өлгергән дәфтәрне, саклык белән генә тотып, һәр язмасын бик җентекләп укып, дусларымны искә төшердем. I класста укыганда язылган дүрт юллы җырларыбыз, шигырьләребез (ул чакта урта һөнәри белем бирү йортларында «студент», «курс» сүзләре кулланылмады) исемә төште: иптәшләремнең күбесе миннән шигырь язып бирүемне сорый иде, шактыена булышканым да булды.

Безнең буын һаман да эшләрен бик уйлап, килеп чыкмаса, читенсенеп, гафу итүне үтенеп, кеше нәрсә әйтер, дигән сыман башкара иде. Бу безнең яшәү принцибына әйләнде. Иптәшләребезнең күңелен төшерергә куркып яшәдек. Гафу итүне үтенү беренче кагыйдә иде. Хөсетләнү, көнләшү турында сүз булырга да мөмкин түгел иде. Дәфтәрдә дә кичерүне үтенгән очраклар бик күп. Кемдер камилләшеп бетмәгән шигыре өчен, кемдер язуының бик пөхтә булмавы өчен, ә кемдер, өч ел эчендә бергә уку дәверендә төрле чаклар булгандыр дип, истәлек хуҗасыннан гафу итүен сорый. Бу – хәзерге заман яшьләренә дә, очраган киеренкелекне йомшарту өчен, бик кирәкле, мөһим сыйфат.

Сизмәстән елмаеп куйдым. Дәфтәрне актара торгач, үзем турында кемнеңдер эзеннән йөрүче кебек итеп уйладым бит әле. Әллә иптәшләремнең язуларын чагыштырып, ниндидер бер кагыйдәгә туры китереп тиңләштерәсем килә инде. Барысы да, балалар тырышкандай, пөхтә итеп эшләгәннәр бит. Юк, «Кайсыбызниләргә иреште икән дөнья йортында?» – дигән якка юнәлде уйларым.

Монысын кем язды икән? Мөхәммәтова Рәбига дигән. Ул шундый җитди карашлы, бик дөрес итеп фикер йөрткән кыз иде. «Дустым Майбәдәр! Бүгенге көннәрдә без Бәрәңге училищесында бергә уйнап-көлеп, концертлар куеп, күңелле генә итеп гомернең (тәүлекнең) өчтән берен уздырабыз. Ләкин тормышның ачы дулкыннары безне төрле якларга аерачак. Бу вакыйга безнең барыбызга да ачыктан-ачык билгеле.

Менә шул вакытта, иптәшләреңнең кульязмасын караганда, мине дә искә алырсың: озын буйлы, сипкелле битле, кырысрак кына бер кыз иде ул, дип уйларсың».

Рәбига үзенә, әлбәттә, бик юмарт итеп тәнкыйть күзлегеннән караган. Бәлки нәкъ шул җитдилеге һәм бик йомшак, назлы тавышы белән дә Шамиленең күңеленә керә алгандыр.

Рәбига укытучы, ана гына түгел, гомере буе җитәкче хатыны булып яшәде. Ә җитәкче хатыны була белү – читтән караган күзгә генә рәхәт һәм җиңелләрдән. Рәбига үзе дә Яңавыл мәктәбендә директор вазифасын үтәде.

Кадыйрова Раушания вафат инде. Аның 1947 нче елның 6 нчы июнендә язган истәлеге: «Майбәдәр! Безнең тиздән, яки 16 нчы июньдә, сынаулар башлана. Беренче рус теле язмадан бирәбез. Безнең шул вакытта «судьба решается». Белмим, яза алырбызмы, юкмы? Яза алсак, башкаларын биреп чыга алыр идек әле. Биреп чыксак, бер-беребездән аерылырбыз инде. Мин – Косолапово районы Хәсән пүчинкәсе, син Төрәк районы, Шункиргә китәрсең (бу уй гына). Ә инде атна арасында кайтып йөрербез. Бер-беребезне сагынышып кайтырбыз. Их! Бирә генә алсак инде имтиханны! Китсәк китәр идек шунда.

Майбәдәр! Без синең белән туганнан бирле бергә уйнадык, көлдек. Кайбер чагында курчак уйнаганда сугышулар, су коенгандагы вакыйгалар, синең мине кыйнап менеп китүләрең, Кадыйр... Хәләхмән... дип «талашулар», бердән унга кадәр бергә укыган вакытлар сагынып сөйләргә генә кала...

Минем теләгем: экзаменнарыңны «4»кә, «5»кә биреп, бәхетле тормышка ireш. Кечкенә чагыңдагы дусың Раушания».

Дөрес, имтиханнар барыбызны да бер яктан куркыта, ә икенчедән, һәрьяклап бик җыйнак булырга өйрәтә. Андый укытучының балалары да җаваплы булырга омтыла. Шул сыйфатларын күрептер, Раушаниянең дә укучылары белем ягыннан бик көчле булганнар.

Бүгенгәчә Югары Мазарбашында яшәгән Гәүһәрия Йосыпова (Һадиева) белән телефон аша хәл-әхвәлләрне белешеп торабыз.

Гәүһәрия, исеңдәме шул 47нче ел июненең бер җомгасында истәлек язганың? Әйдә, узганнарны барлап алыйк әле: «...Директор бишенче дәрестә безгә үзлекле эш биреп чыкты (Ватан сугышы турында Г. Рәмлә укый). Менә мин, шул укытучы юклыктан файдаланып, сиңа, Майбәдәр, ике-өч кенә җөмләдән торган кульязмамны калдырырга уйладым. Майбәдәр! Без синең белән гел бергә укыдык, бергә укыдык кына түгел, бергә йөрдек тә. Шул узган өч ел эчендәниләр генә кыланмадык без! Көлүләр, уйнаулар, төрле күңеллелекләр һәм күргәнбелгәннәрне сөйләп, юлның озынлыкларын белми дә кала идек. Их! Сагындырыр әле ул көннәр, әгәр тормыш дулкыннары төрлебезне төрле якларга аерса. Ләкин, Майбәдәр, безне бер районга билгеләделәр. Киләчәктә зачетларыбызны уңышлы биреп, авырлыкларны җиңеп, кичеп чыксак иде, бер авылда булып, укыган чактан да күңеллерәк итеп йөрсәк иде. Өч ел эчендә төрле вакытлар булгандыр. Гафу ит. Экзаменнарыңны уңышлы бир...» – дип яза Мазарбашы кызы Гәүһәрия.



Гәүһәрия дә башкарган эшенә бик җаваплы итеп караучылардан иде. Куян урта мәктәбе укучыларының кайсысы белән сөйләшсәң дә: «Укытып карады ул Гәүһәрия апа математиканы!» – дип сокланалар.

Бар яктан да көчле идең син, Гәүһәрия. Тормышыңда Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынауны үтәдең – ятим балаларның мактаулы анасы була алдың. Аларга әтиләре Рафаэль белән бергә ата-ана назы да бирә алдыгыз, тормышка кирәкле сыйфатлар да тәрбияләдегез.

Шәйхиева Мостафизәнең, Габдуллина Даниянең язмаларына күз салдым. Дуслыкның кадерен белү турында язганнар. Язмыш турындагы юллары бар.

Күзләр җитеп, салкын җилләр искәч,
Алсу чәчәкләр дә суалар.
Кайбер күзләр авыр язмыш белән –
Кешеләр дә шулай булалар.

Даниянең бу сүзләре нинди тирән мәгънәле. Ә Нигъмәтҗанова Хәдичә:

«Синең белән дус булуым
Кайгыларымны минем тарата», – дигән.

Гарипова Наиләнең дә, Нигъмәтуллина Даниянең дә дуслыкка бер төрле назлылык белән каравын аңлап була.

Истәлек язучыларның кыска шигырьләре шул елларныкына охшатып төзелгән. Вакыт узу белән, һәрбер саргайган кәгазь бите, үзенең эчтәлегенә карап, әһәмияткә ия була. Чордаш классташларымның тойгыларын, берничә генә юл белән булса да, бүгенге танышларыма җиткерәсем килә.

Берәр нәрсәне очраклы хәл дип санасак та, тик алай булмый ул. Бары да Тәңрем кушуы буенча алдан билгеләнә. Укыган чакта кемнең үзе тутырган саргаеп беткән дәфтәр битен, дистәләрчә еллар узгач, кулына алачагы

уенда булды икән! Бу юлларны уку йөзегездә елмаю тудырса да, ышаныгыз: шушы яшел тышлы дәфтәр – безнең гомеребезнең бер өлеше, алай гына да түгел, әйтеп узганымча, зур тарихның кечкенә генә бер сәхифәсе. Ул вакытта андый калын дәфтәрләр дә юк иде әле. Җаен тапкан бит дустым: бар дәфтәрне бергә туплап, заманчарак «күлмәк» киерткән. Минем кулыма Майбәдәрдән килеп кергән икән, димәк, мин аны кемгәдер җиткерергә тиеш булганмын. Менә үзегез тыңлап карагыз. Безнең яшьлектә мәктәпләр ир-ат укытучылар эшләү белән көчле иде. Безнең белән дә Энгель Шәйхиев, Урушан Фәйзрахманов, Равил Сафин укыды. Өчесенең дә истәлеккә калдырырлык сүзләре булган. Егетләрнең беренчесе:

«Бу истәлекне алып укыганда,
Бик күп еллар үткән булырлар.
Шул вакытта иптәшләрең булса,
Әллә кая киткән булырлар», – дигән.

Әллә кая киткән булырлар, дигәндәй, Энгельнең гаиләсе бик озак Владивостокта яшәде. Аннан соң, өч балалары булгач, алар Казанга кайтып урнаштылар. Фатирга кереп тора башлаганнарын ул елларның чишелеп бетә алмаган мәсьәләсе итеп, ничектер бер очрашуда Дания исенә төшерде: «Иң алдан бер балабызны гына күрсәттек хуҗага, торырга рөхсәт итүеннән куркып. Хуҗа күргән икән безнең килгәнне. Ярар инде, теге балаларыгызны да алып керегез, дип елмайды».

Урушан да әйтәсе килгәнен үзенчә аңлаткан:
«Синең белән бергә укыган чаклар
Минем истән чыкмас тиз генә,
Аерылгач, мине уйларсың микән?
Әмма мин онытмам һич кенә.»

Арабыздан Равил Сафин кебек якты шәхесләр чыгуы белән без дә горурлана идек. Ул:
«Бәрәңгенең мәктәбендә
Укып узды яшьлек гомерләр.
Бергә укыган чаклар искә төшкәч,
Өзелеп сагынып, уйланыр күңелләр...
Ярый, дускай, гаеп итмә,
Әйбәт итеп язып булмады.
Дәфтәремне пычраткан, дип
Ачулана күрмә син тагы», – дигән шигъри юлларын нурын сипкән йолдызчык белән бизәгән. Равилнең шул вакытта ук алдагы тормышын яктырткан язмыш йолдызы булмадымы икән ул?

Минем яшьлегем Себер ягында узды. Туган якларга ялга кайтуны зарыгып көтеп ала идек. Бергә укыган кызлар, егетләр бик киң күңелле булган икән. Күрешкәч тә, кызыклы очракларны искә алу башлана иде. Элек проблема булып күренгән вакыйгалар соңгарак көлеп сөйләрлек кенә булып кала. Бервакыт Энгель үзләренең ничек итеп укырга кереп йөргәннәрен сөйләде. Аның дусты Энгель укыганда әнисенең апасында фатирда торды. Алар Равил белән һаман бергә булдылар. Шушы ике дус хәрби училищега укырга керергә максат куйганнар. Ни сәбәпледер, егетләрнең берсен укырга алмыйлар. Энгельнең (ул минем абыемның кызының ире) шул чактагы «йөрәк ачысы»н искә алып: «Мин, Равил кайтып китә, дип, ә Равил, Энгель кала, дип, бик озак кочаклашып еладык», – дип сөйләгәне булды. Әйе, дуслар ул чагында кайгының нинди булганын аңларлык яшьтә түгел иде. Туган якта эчәсе сулары Равилне нинди үрләргә күтәрде! Димәк, тәкъдире буенча ул шушы җирдә күбрәк файда китерергә тиеш булган. Хәер, ул шулай килеп чыкты да: чордашым Равил үзен бик күпләргә үрнәк булырлык җитәкче итеп таныта алды.

Ә Энгель Казанда иң зур заводларның берсен җитәкләде. Лаеклы ялга киткәнче, шул оешманың, хәрбиләрчә атлагандай, ышанычлы һәм оста директоры булды. Аның яшьлек хисләре дә сокланырлык иде. Укыган елларда кабынып киткән мәхәббәте Дания Габдуллина белән 60 елга якын бик матур яшәделәр. Дөресрәге, бер ай гына тулмады алты дистәгә. Гаилә корууларының олы юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнеп йөргәндә, Дания кинәт кенә гүр иясе булып куйды. Бу матур пар берсен-берсе бик ихтирам итеп яшәде. Дания, чыннан да, күп кенә офицер хатыннары кебек, ире тапканны гына файдаланып ятучы түгел иде. Пөхтә, бик тырыш, сөеп һәм сөелеп яшәде ул. Дания югары белемле, үзен укучыларына нык яраттыра алган укытучылардан саналды. Гомеренең соңгы елына хәтле диярлек өйдә укытыла торган балаларга белем бирде. Андый укучылар белән эшләүнең серләрен тирәнтен аңлагач кына алар янына барып була. Мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ата-аналарыннан рәхмәт сүзләре ишетү, ел саен үзен эшкә бик теләп чакырып алулары Данияне канатландыра иде.

Егетләрнең өченчесе – Урушан Фәйзрахманов – апасы Халидә киңәше белән һөнәр алырга Бәрәңге училищесын сайлаган иде. Ул, укуын тәмамлагач та, Ерак Көнчыгышка китеп барды. Өр-яңа тармакта һөнәр сайлап булса кирәк, Урушанның урманчылыкта эшләгәнен иптәшләребездән белдем.

Арабызда Гәрәева Сания бик чибәр, үзен артистларча тоткан укучы иде. Аның әйтергә теләгән сүзләре түбәндә:

«Их, дускаем, алгы көннәреңдә
Алырсыңмы мине исеңә?
Мин бит сине онытмаска диеп,
Юллар сызам альбом битеңә.
Яшьлегемнең матур вакытларын
Шушы язуымнан карарсың.
Бергә булган иптәшләреңнең
Берсе итеп мине санарсың».

Сания татар һәм рус әдәбиятын һәм телләрен яхшы белгән укучылардан иде. Алар, укучылары искә алганча, Фәүзелнәҗәт Әхтәм кызы белән Татар Кетнәсе мәктәбендә көчле тел белгечләреннән саналганнар.

Дәфтәрдә чәчмә әсәр формасында язылган көндәлекләр бигрәк тә дулкынландыргыч. Габдуллина Даниянең, Кадыйрова Раушаниянең, Габдрахманова Рәмләнең, Йосыпова Гәүһәриянең, Рәхимова Мәсхүдәнең, Шәйхиева Мостафизәнең, Нигъмәтуллина Даниянең, Рәхимова Миннурның, Хәлирахманова Майбәдәрнең үзенең һәм башка бик күпләрнең язмалары укучыны педагогия училищесы тормышына алып кайта. Анда көз көне солы суккан, салам өйгән, ашлык сукканда машина әйләндергән, колхозда бәрәңге чыгарган вакытлар, кыш көне урман чистартып, агач яндырган чаклар һәм ял сәгатьләре тасвирланган. Педучилище өчен һәр укучыга җәй көне алты кубометр, кыш көне дә шуның хәтле үк утын кисәргә йөкләмә бирелә иде.

Хәдичә Нигъмәтҗанова язган биттә гомеребез буена күз алдыннан китмәслек, коточкыч очрак турында сөйләнә. Безнең укулар октябрьдә генә башлана иде. Ел саен педучилищеда белем алучыларны инде кар белән капланып өлгергән басуга бәрәңге алырга җибәрәләр. Ат кәзне ерып китә. Без шуннан яланкул уңыш җыябыз. Бервакыт әйбәт кенә урыс гаиләсенә фатирга керттеләр. Хуҗалар, безнең тышкы кыяфәтебезне күреп, бик кызгандылар. Мария апа тәмләп коймак пешереп сыйлады. Юеш чабаталарыбызны, сыгып алырлык аяк чолгауларын мич өстенә кибәргә куйдык, һәм тез башына хәтле чыланган аякларыбызны сөртеп, сүндәрәгә (сәндерә) менеп яттык. Арабыздан Фатыйма Рәхимова: «Боларның тәресен борып куйсак, тагын да яхшырак сыйлыйлар икән», – дип шаяртырга уйлаган һәм иконаны почмакка каратып әйләндереп куйган.

Хуҗалар, бик нык ачуланып, ничә кыз бар, барыбызны да урамга куып чыгардылар. Күршедәге мари өендә түрдә «г» хәрефе формасында куелган эскәмиядә юеш киемнәребезне киеп, бер-беребезгә сыенышып утырган килеш шушы төнне таң аттырдык. Яшьлек җүләрлегебез аркасында тамырлары белән дингә табынучыларның хәтерен калдырдык, ышанычларын аклый алмадык.

Безнең белән башка милләт кызлары да укыды. Алар бездән татарча, без алардан урыс һәм мари телен өйрәнә идек. Елеево авыл Советына кергән «Пеледыш» колхозыннан Павлова Александра «Сулима» җырын истәлеккә калдырган. Бик яратып җырлый идек ул җырны. Авылдашлар булса кирәк, шушы ук колхоздан Завойских Лидиянең сүзләре бик матур: «Как яблоко ты зреешь наливное», – дигән. Майбәдәр чибәр иде шул. Бәрәңге районыннан Ильпанур кызы Ямбатрева Салика: «Майби, бүген 1947нче елның 6нчы июне, иртәгә укуның соңгы көне, – дигән. – Хушлашу турында марича бер куплет язам. Аны синең белән концертта җырлаган идек». Салика шундый иде ул – сюрпризлар ясарга ярата. Дөп-дөрес итеп татарча теләкләр язып калдырган. Өлкәнрәк яшьтәге, III класста укыган Арсаева Евдокия мәхәббәт турында язган. Чыннан да бик хак сүзләр: сөюебезне яшерә белә идек, кычкырып йөрүләр булмады. Тик бу бик көчле, саф хисләр була торган иде.

Сөйләп бетерә алмаслык чор булса да, барыбер үзебезне бәхетле итеп тоеп гомер кичердек. Гомер бик тиз узды, бигрәк тә аның көзе килеп җиткәнен бөтенләй сизмәдек.

Бу укытучылардан бик санаулы кешеләр генә исән бүген. Инде аларны белүчеләр дә азаеп бара. Кылган догаларыбыз мәрхүм укытучылар рухына барып ирешсен. Өлкән буын вәкилләренә, бәлки, бу хатирәләр өлешчә кызыклы булыр. Әмма бит бүгенге яшьләр дә картаячак. Әйтүе кыен, тик бер утыз-кырык елдан алар ук: «Безнең узган буыннар нинди җырлар көйләп йөрделәр икән, кыска шигырьләрне ничегрәк итеп төзеделәр икән?» – дип сорап куймаслармы? Чөнки, вакыты җиткәч, нәрсәгәдер өстенлек бирү ничек тә безнекенә охшап калыр. Шул вакытта аларга бу истәлекләр бик урынлы һәм вакытлы булыр.

Аңлаганыгызча, сүзем XX гасырда Мари ягындагы татар мәктәпләрен тулысынча укытучылар белән тәэмин иткән уку йорты турында иде.

Кадерле ядкарьләр

Бу хатны язуга журналыгызның 2015 елның икенче санындагы Габдулла Тукайга багышланган сәхифә («Тукай сөйгән Зәйтүнә...») этәргеч булды. Свердловск өлкәсенең Түбән Серги районы Аракай авылында яшәүче Миңсылу Байгужинаның бу язмасында сүз безнең Иж-Бубый кызы Һаҗәр Әхмәтлатыйф кызы Гыйззәтуллина (1895 – 1885) хакында бара. Язмага нисбәтле рәвештә, фото да урнаштырылган, һәм бу фотоның бүгенге көндә Аракай авылында, Һаҗәр Гыйззәтуллинаның кызы Роза ханымда саклануы хакында әйтелгән.

Безнең музеебызда да бу фотоның күчермәсе бар. Аны безгә Зәйтүнә Мәүлүдованың килене Зәкия Рәсүлева җибәргән була. Ә Рәсүлевләргә бу кадерле ядкарь 1980 елда Һаҗәр Гыйззәтуллинаның кызы Флера Ибраһимовадан килеп керә.

Әлеге тарихи ядкарьгә карата үзебездәге мәгълүматны бирүне кирәк табабыз.

Фотода без Мөхлисә Бубый җитәкләгән Троицк хатын-кызлар мәктәбенең бер төркем мөгаллимәләрен күрәбез.

1911 елда Иж-Бубый ир-балалар мәдрәсәсе таркатылып, Мөхлисә Бубыйның абыйсы Гобәйдулла һәм энесе Габдулла кулга алынганнан соң, 1912 елда хатын-кызлар мәдрәсәсе дә ябыла. Мөхлисә Бубый, кызы Мөнҗия һәм энесе Габдулланың кызы Галияне алып, Троицк шәһәренә күчеп китә һәм анда 1910 елда ачылган хатын-кызлар мәктәбен җитәкли башлый.

Иж-Бубыйда хатын-кызлар мәдрәсәсен тәмамлаган Һаҗәр Гыйззәтуллина (икенче рәттә сулдан икенче), шулай ук Тукайның сөйгәне буларак тарихка кереп калган Зәйтүнә Мәүлүдова да (артта сулдан беренче) Троицкидагы хатын-кызлар мәктәбенә укытырга киләләр. Беренче рәттә уртада – Габдулла Бубыйның кызы Галия Бубый (Бобинская).

Музеебызда Һаҗәр Гыйззәтуллинаның Троицкидагы хатын-кызлар мәктәбендә укучылар белән төшкән тагын бер фотосының күчермәсе саклана. Фотода Һаҗәр Гыйззәтуллина – арткы рәттә сулдан өченче.

Икенче рәттә сулдан дүртенче – Габдулла Бубыйның кызы Галия Бубый. Бу фото 1914 елда төшерелгән.

«Түгәрәк уен»да чыккан язмага кадәр, сеңелесе Сәкинә 1990 елда музейга юллаган хатлар буенча, Һаҗәр Гыйззәтуллина турында безгә түбәндәге мәгълүматлар билгеле иде.

Аларның әти-әниләре Иж-Бубыйда туа. Әтиләре Әхмәтлатыйфны (1870 елда туган), сәүдә эшен өйрәнергә дип, 16 яшендә Пермь якларына җибәрәләр. Ул 19 яшендә өйләнә һәм Пермь шәһәрендә төпләнеп кала. Кызларын – Гайшә һәм Һаҗәрне – һәр елны данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Һаҗәр, мәдрәсәне тәмамлап, мөгаллимәлек таныклыгы ала. Троицкида, Тобольскида укыта. Ә менә алга таба Урта Уралда төпләнеп, гаиләсе белән авыр тормыш сынаулар узуы һәм Аракай авылында гүр иясе булуы хакында без белми идек. Якташыбыз турындагы кадерле мәгълүматларны безгә китереп җиткергән журналга без бик рәхмәтлебез.

Музеебызда Зәйтүнә Мәүлүдова белән бәйле истәлек-ядкарьләр дә бар. Шуларның берсе – Зәйтүнәнең Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсен тәмамлаганлыгы турындагы шәһадәтнамәнең фотокүчермәсе. Ул Мөхлисә Бубыйның кызы Мөнҗия белән бик дустанә мөнәсәбәттә була. Моның бер дәлиле – Мөнҗиянең музеебызга Зәкия Рәсүлева аша килеп кергән фотосурәте. Аның артына «Бик сөюдикем Зәйтүнә! Җәнабегезгә гомерлек ядкарь итеп ошбу карточкамны тәкъдим итәмен. Мөнҗия Бубинская. 1914 ел, 21 апрель. Троицк», – дип язылган.

Нурия Раиф кызы МӘННАПОВА,
Әгерҗе муниципаль районының тарихы һәм мәдәни мирасы музееның филиалы – Иж-Бубый авылы тарихы музее методисты

Мөнҗия Бубый.

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Предъявительница сего Казанской губ. гор. Чистополь Зайтуна Гайдаровна Мавлюдова на основанiи постановленiя Сарапульскаго училищнаго совѣта отъ 27-го марта и 5-го iюня 1907 года о спецiальныхъ испытанiяхъ, подвергнись полному испытанiю при Иж-Бобьинскомъ „медресе" и выдержавъ оное удовлетворительно, удостоена званiя учительницы – мугаллимы татарскаго начальнаго училища.

Въ удостовѣренiе чего дано ей это свидѣтельство за надлежащимъ подписомъ и съ приложенiемъ печати Ижбобьинскаго „медресе".

Деревня Ижъ-Бобья августа 23 дня 1910 г.

Завѣдывающiй муллы и мударрисъ А. Бобинскiй

Свидетельство
Выдано Иж-Бобьинским медресе Зайтуне Мавлюдовой в том, что она удостоена звания учительницы- мугаллимы татарского начального училища
23 августа 1910
Д. Иж-Бобья

Һаҗәр Гыйззәтуллина арткы рәттә сулдан өченче.

Сәйфи КУДАШ

КАЗАКЪ ДАЛАСЫНДА

(Очерктан өзекләр)

Сарсымбай тыштагы эш-көшләрен бетереп кергәч, без теге, түр башында утырган кеше белән дә таныштык. Бу кеше, авылдан авылга гизеп, думбра уйнап, үләң әйтеп-жырлап йөрүче бер акын булып чыкты. Сөйләшергә бик ярата торган бу акынның сүзләренә караганда, ул һәр елның җәендә Троицкига барып, ул чакта граммофон пластинкаларындагы җырлары белән билгеле булган җырчы Мирфайза Бабаҗановның кымызханәсендә бераз үләң әйтеп кайта икән.

Ул чактагы күпчелек казакъ акыннары кебек үк, бу акын да укый һәм яза белми иде. Ләкин, шулай булуга карамастан, ул аңсыз һәм артта калган бер кеше түгел. Ул бик күп белә һәм бик күп нәрсәне хәтерендә саклый торган кеше булып чыкты. Шуның аркасында аның сүзләре җырлар, мәкальләр һәм хикмәтле әйтемнәр белән бергә үрелеп бара. Аның телендә Абай һәм Акмулла акыннарның исемнәре һәм сүзләре бик еш кабатланып тора. Ул шагыйрь Акмулланы мактап хәтергә алды. Аның Троицк төрмәсендә утырган чакта, казакъ бае һәм түрәсе Исәнгилдене әрләп язган шигырьләренең бер бүлеген сүз арасына кыстырып җибәрде.

Шуның өстенә бу акын, ниндидер бер татар укытучысының ярдәме белән, Тукайның кайбер шигырьләрен дә ятлап алган. Ул гына да түгел, акын Тукайның «Күңел» дигән билгеле шигырен «Тәфтиләү» көенә җырлап та күрсәтте. Акынның әйтүенә караганда, ул 1912 елның җәендә Тукайның Троицк шәһәренә килүен дә ишеткән...

Шагыйрь белән танышып һәм, шигырь әйтешеп, ярышып карар өчен, эзләп, Габдрахман мулла Рахманкуловның өенә дә барган булган. Ләкин ул, кызганычка каршы, үзе әйтмешли, нугайның өлкән акынын күрә алмаган. Чөнки ул эзләп барган чагында инде Тукай Казанга кайтып киткән булган икән. Ул Тукайны, казакъ җәйләүләрендә йөртеп, кунак итәргә бик теләгән, ләкин барып чыкмаган. Акын моның өчен әле булса үкенеп бетә алмый. Әгәр дә Тукай тагын бу якка килеп чыга торган булса, ул аны, мотлак, барып күрәчәк...

Без дә тик ятмыйбыз, һәр көн иртүк торабыз да эш эзләп чыгып китәбез. Шәһәрдәге барлык постоялый дворларны, мосафирханәләрне һәм юлчылар төшерә торган махсус өйләрне йөреп чыгабыз. Бер мәчет ишек төбенә барып, Гатаулла мулланың, икенчесенә барып, Сәгыйга мулланың чыкканын көтеп торабыз. Алардан укытучылыкка урын сорашабыз. Шуннан соң, я бер байның тире складында яки тегермәнендә эшләп, кан таратып кайтабыз. Үзенә күрә икмәклек акча да табылып тора. Ә ару-талу үзенә күрә генә түгел. Үлгән кебек йокларлык булып кайтабыз.

Беркөнне шулай, көндәге сәяхәттән кайтып кергән җиребезгә, безне әлегә кадәр булмаган бер күренеш һәм яңа бер мосафир каршы алды. Җиткән һәм тузган кара чәчле утыз яшьләрдәге бер кеше елый-елый гармун уйнап утыра иде. Без килеп кергәч тә, ул күтәрелеп карамады. Бәлки, һичбер нәрсәгә игътибар итмәстән, тирән бер кичереш белән онытылып, һаман да уйнавында дәвам итте.

Гаффан Сафаров әле гармунчыга, әле постоялый двор хуҗасына карап торды да: «Әллә бераз төшереп алганмы?» – дип тамагына чиртеп күрсәтте. Моңа каршы постоялый двор хуҗасы, юк, алай сөйләшергә ярамый, дигән кебек итеп, башын чайкап һәм кулын селтәп куйды. Ләкин хуҗаның бу бер нәрсә дә аңлатмый торган җавабы Гаффанны канәгатьләндермәде булырга кирәк. Ул хуҗага якынрак барды да:

– Нәрсә, моны сөйгән кызы алдаганмы әллә? – дип сорады.

– Юк, белмим, – диде хуҗа.

– Алай булгач, ата-анасы берьюлы үлгәнме әллә? – дигәч, хуҗа:

– Соңыннан сөйләрмен, – диде дә Гаффанның яныннан ук китте.

Гармунчы бу сүзләрне ишетмәде дә, Гаффанны күрмәде дә кебек. Уйнавында дәвам итте. Тирән итеп бер көрсенеп алды да, тынак кына моңлы тавыш белән, гармунга кушылып җырлап та җибәрде. Шул вакыт гармун тавышының моңы белән тынлыкка талган өйдә Тукайның:

Яшь вакытта яшьнәдем,
көчле вакытта күкрәдем,
Яшьнәмим дә, күкрәмим дә,
утсыз инде күкрәгем!
Килде тоткынлык,
түбәнләнде уемның куллары,
Хөр заман ак кул белән
күкләрдә йолдыз чүплә дем.
Ак күгәрченне кулымнан алдылар,
козгын биреп;
Ак кирәк дип, пакь кирәк дип,
күпме күз яшь түкмәдем!..
Ул түгел күңлем эшеннән,
тик ялан кулның эше,
Кызмагыз бик,
*чыкса мәйданга басылган чүпләрем,** –
дигән юллары яңгырадылар.

Гармун чыңлаудан туктады. Моңлы җыр тавышы тынды. Өйдәге тынлык тагын да куера төште. Өйдәгеләр, кай җиреннән тотып сүз башларга белмәгән кешеләр сыман, гармунчыга текәлгән хәлдә, сүзсез тордылар. Ләкин бу хәл озакка бармады. Аны башлап гармунчы үзе бозды:

– Нигә гаҗәпләнәсең, әллә дөньяга бүген генә тудыңмы? – диде ул Гаффанга. Кешегә туры карап сөйләшергә ярата торган кыю Гаффан кинәт бирелгән бу сораулардан бөтенләй аптырап калды һәм:

– Юк, бернәрсәгә дә гаҗәпләнмим, – диде, ничек җавап бирергә дә кыймыйча.

– Белмәсәң бел, туганкай, мин бүген аракы эчеп исермәдем. Сөйгәнем дә алдаганы юк. Әтием белән әнием дә тереләр. Бүген мин бөтенләй башка кайгыдан исердем. Бу кайгыдан кайгырмаган татар, ике акыллы булса да, кеше түгел ул.

Үз кайгысы – кайгы түгел кешенең,
Үз хәсрәтем өчен түкмим яшемне.
Мең кат янып, бүген мең кат өшедем,
Халкым кайгысы идерде башымны...
дип, мосафир үзенең сүзләрен дәвам итте:

– Халкыбызның шатлыгы да, кайгысы да аның йөрәге аркылы үтеп, җырга һәм шигырьгә әйләнә иде. Хәзер инде менә шушы шигырь тәсбиxенең бисмилласы өзелде – бөек шагыйрь Габдулла Тукай юк! Рәхимсез үлем аны безнең арабыздан тартып алды... Ләкин аны безнең йөрәкләребездән тартып алырга бернинди көчнең дә кулыннан килмәячәк!.. – диде һәм гагын да гармунын уйный башлады.

Без, бу көтелмәгән хәбәрдән аптырашып, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, берберебезгә карашып, хәрәкәтсез һәм телсез калдык. Гармунчы бераз тынычлана төште. Аннан тагын да безгә күтәрелеп карады һәм әле беребезгә, әле икенчебезгә төбәлеп:

– Ышанмыйсызмы? Ышанмагыз! Чөнки бу – кеше ышанырга яраклы хәбәр түгел. Мондый хәбәрләр һәрвакытта да дөрес булмый калсыннар иде! Ләкин алар дөрескә чыгалар икән шул. Ышанмасагыз, әнә Габдрахман Мостафинның китап магазинына барыгыз. Анда әллә ничә төрле газет килгән. Ләкин барчасы да шул бер шомлы хәбәрне раслап сөйлиләр, – диде һәм эчәргә салкын су сорап алды.

Әлегә чаклы бернәрсә дә аңламыйча гаҗәпләнеп, бер як читтә басып торган украинец, Гаффан янына килде дә, яшерен бернәрсә турында сораган кебек итеп, әкрен генә тавыш белән:

– Нәрсә булган? Бу кеше нинди бәхетсезлеккә очраган?– дип сорады.

– Татар халык шагыйре Габдулла Тукай үлгән, – диде Гаффан, авыр көрсенеп.

– Нигә, бик зур шагыйрь идемени? – дип сорады украинец, кайгының шул чаклы зур булуына ышанасы килмәгән бер кыяфәттә.

– Татарның Пушкины һәм Тарас Шевченкосы иде, – диде Гаффан, үзенең горурлыгын яшерә алмыйча.

Бу сүзләрне әйткәч, Гаффан минем алдымда кинәт үсеп киткән төсле булып күренде. Димәк, ул, ничек кенә булмасын, бөек Пушкин һәм Тарас Шевченконы да белә торган бер егет!

Без теге гармунчы мосафир әйткән Габдрахман Мостафинның «Тәрәкъкый» исемле китап магазинына, ягъни Кустанай шәһәренең бердәнбер культура учагына юнәлдек.

Без, магазинга барып җиткәнче, гармунчы сөйләгән хәбәрнең ялганга чыгуына исәп тоткан идек. Ләкин, анда баргач, теләсәк тә, теләмәсәк тә, ул хәбәрнең чын икәнлегенә ышанып кайтырга мәҗбүр булдык. Шул көннең истәлеге итеп, без кесәдәге барлык байлыгыбыз булган 17 тиен акчаның 12 тиененә Тукайның үзе тере чакта чыккан һәм иң соңгы җыентыгы булган «Җан азыклары» китабын алып кайттык. Без постоялый дворга кайтып кергән чагында теге гармунчы да, Полтава губернасыннан күчеп килә торган украинецлар да юк иделәр инде. Шул сәбәпле бу хәбәргә ышанганнан соңгы кичерешләребезне бер кеше белән дә уртаклаша алмадык...

* Тукайның «Үтенеч» шигыре.

ТУКАЕВ ҮЛҮ МӨНӘСӘБӘТИЛӘ

Безнең авылга мөхтәрәм шагыйребез Габдулла әфәнде Тукаев җәнапларының вафат хәбәре шимбә көн сәгать унда килеп җитте. Килү берлә хәбәр бөтен авылга таралып та өлгергән. Шул көн килгән ике нөсхә «Кояш», өч нөсхә «Йолдыз» йорттан йортка йөртелеп укылган. Яшьләр, картлар, кызлар, карчыклар аны кайгыртканнар, аның рәхәт рухы өчен дога да кылганнар,

Габдулла әфәнде берлә күптән таныш мәктәп балалары да үзләренең остазларын кайгыртып, аның мәҗмугаларын алыр өчен кулларына кергән акчаларын туздырмаска сүз беркетеп куйганнар. Өйләдән чыгышлый мәчет картлары: «Ул кем, ул нинди кеше, дин исламга нинди хезмәт итте?» – диеп, миннән сораша, эзәрлекли, җентекли башладылар. Мин дә үзем белгән кадәр аны халыкка аңлатырга тырыштым. Кич ясигъдан соң күл буена төшеп утырдым. Миннән ерак та түгел бер мунча янында авыл яшьләре җыелып, моң гына, зәгыйфь кенә чыгарылган гармун тавышына бер-икесе авылда гына була торган саф тавыш берлә җырлыйлар, башкалары тыңлыйлар иде.

Җырлары ачык ишетелмәсә дә, арада «шагыйрь Тукай» дигән сүзләр ишетелә иде. Мин: «Бу ни, болар ни җырлыйлар икән?» – дип, чынлап тыңлап карасам, үзләренең шагыйрьләре хакында бер «Илаһи бәет» тәртип кылып, шуны көйләп утырганлыкларын сиздем.

Безнең тарафта авыл яшьләре бер-бер фаҗига булса, шул хакта гавам әдәбияты тарзында бер касыйдә тәртип итеп, исеменә «илаһи бәет» диләр. Шулай итеп, авыл җирендә «Суга баткан кыз», «Картада оттырылган кыз», «Ябышып чыккан кыз», «Үтерелгән мулла» вә башка исәпсез-сансыз «илаһи бәетләр» хасил булган.

Менә алар бүген ярты көн эчендә кадерле шагыйребезне үзләре белгәнчә, фикерләре җиткәнчә кадерләп, бер «илаһи бәет» тәртип кылганнар да шуны җырлыйлар вә ихлас берлә тыңлыйлар икән. Иртәгесен «илаһи бәет»ләрен эзләп табып алдым. Авыл яшьләренең үзләренең кадерле шагыйрьләренең вафатына ачынып әйткән бер «илаһи бәет»ләренә милли җәридәләр бер урын бирерләр өмите берлә «Кояш» идарәсенә җибәрәмен.

ИЛАҺИ БӘЕТ

Бисмиллаһи вә биллаһи,
укыдык корбан гаетен;
Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Тукай шагыйрь бәетен.

Тукыз йөздә унөч елда апрель икесендә
Тукай мескен вафат булган
Клячкин больнисында.

Ак келәтнең келәсен элә белми эләсең;
«Әҗәл» агай, син нишлисең,
килә белми киләсең.

Ак келәтнең алдында калды бәнем җиләнем;
Егерме алтыда үлеп китте
Тукай шагыйрь сөйгәнем.

Тавык йөри кырлашып,
кызлар йөри җырлашып;
Безнең өчен җыр язды
тырышып та тырмашып.

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз, боты озынга күрә;
Без Тукайны сөябез җыры матурга күрә.

Йөгереп кердем келәткә,
кулым тиде беләккә;
Җылы аштай җырлары чат ятадыр йөрәккә.

Ызба артында алмагач,
кисеп җиргә салмагач;
Җырла, моңай, саргай, ул,
матур Тукай калмагач.

Мәсҗет башы манир-манир,
манир саен бер талир;
Безне ятим калдырып,
китте безнең шәп шагыйрь.

Тукай абзый, яшь чагыңнан
белә идек без сине;
Онытыр диеп уйлама, онытмабыз без сине.

Алма бирдем – алмадың,
тәңкә бирдем – сайладың;

Безнең матур дөньябызда
ник ике-өч ел калмадың?

Тауга менсәм – тау биек,
түбән төшсәм – тамырлык;
Тукаен җуйган яшьләргә
ходай бирсен сабырлык.

Актыр җиләнем минем,
күктер җиләнем минем;
Кабереңдә шат йокла,
җаным, шагыйрем минем.
1913

Г. Тукайны соңгы юлга озату. Казан. 1913 ел.

ТУКАЙ БӘЕТЕ

Бисмиллаhи вә биллаhи,
Җитте корбан гаете;
Без әйтәек, сез тыңлагыз
Мәрхүм Тукай бәетен.

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Унөч елы бу вакыт;
Унбишенче апрелендә
Җырчыбыз Тукай вафат.

Булды мәрхүм шагыйрь Тукай,
Чәчә-чәчә нурларын;
Китте Тукай бу дөньядан,
Безгә биреп җырларын.

Яшьли китте шагыйрь Тукай
Тәкъдиренең әмеренә;
Аллы-гөлле күп чәчәкләр
Куйды халык каберенә.

Мең-мең халык җеназа укып,
Куйдылар зурлап күмеп;
Чит калалардан килделәр,
Тукайны якын күреп.

Кичте дөньяны бичара
Моңланып та сызланып;
Ничә мең кеше күзеннән
Яшен түкте, кызганып.

Бик аз вакыт эчендә дә
Нык танытты ул үзен;
Белделәр барча галәмнәр
Тукайның әйткән сүзен.

Шагыйрьләргә шагыйрь иде
Ул Тукай заманында;
Куркып тормый әйтер иде
Яхшысын, яманын да.

Бик күп шигырь чыгарды ул
Халкы өчен сызланып;
Халкым артка калмасын дип,
Яратып һәм кызганып.

Мохтаҗлыкта яшәде ул,
Байга бурычка батып;
Сәүдәгәрләр баедылар
Аның китабын сатып.

Хезмәт итте ул халыкка
Авыру көе, тырышып;
Гаделлекне язды мактап,
Яманлыкны – орышып.

«Җырлый-җырлый үләрмен мин, –
Диде Тукай, – үлгәндә дә...»
Тере калды җыры белән,
Җисемен җиргә күмгәндә дә.
1913

Ясигъдан – кичке намаздан
Гавам әдәбияты тарзында бер касыйдә – халык әдәбияты рәвешендә бер бәет
Хасил булган – барлыкка килгән
Җәридәләр – газет, журналлар

Чыганак: Тукай турында замандашлары. Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960, 210-217 битләр.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

ТӘРӘЗӘЛӘР

хикәя



Без урамнан икәү үтеп барабыз. Мин аның шәенә генә барырга тырышып акрынрак атлыйм. Гаҗәп, ул да як-ягына каранып, һаман адымнарын акрынайта. Нидер әйтергә теләгәндәй, проспектның аргы башына йотылып карый. Аннары бөтенләй туктый да, нигәдер оялып кына:

– Кара әле, ничаклы тәрәзәләр! – ди ул.

Мин күтәрелеп карыйм да, бая өзелгән сүзне ялгап, аңа сорау бирәм:

– Ничек соң, Фәхриев абый, пенсиядә бик күңелсез түгелме?

Ул һаман үзенекен сөйли:

– Тәрәзәләрне көндез түгел, төнлә, караңгыда карарга кирәк. Кичләрен алар үзләре нур сибәләр! Тәрәзәдә ут бар икән, димәк, анда тормыш, тереклек бар!.. Мин кичләтеп кенә шушы проспекттан бер урап кайтырга яратам.

Без бара-бара әлеге исемсез мәйданга барып җитәбез. Каяндыр сулдан, әле салынып та бетмәгән йортлар арасыннан, шау-гөр сөйләшеп, бер төркем кешеләр килеп чыга. Ул, кемнедер эзләгән сыман, төркемне көтеп туктап кала. Чыннан да, кешеләр безнең турыга килеп җитүгә, арадан бер егет аерылып чыгып кычкырып җибәрә:

– Фәхриев абый!

– Исәнме, Һади, – ди ул, тыныч кына.

– Алтынчы йортны тапшырдык. Бүген күченеп килә дә башладылар. Безне өй туена чакырдылар... Кызык!

Алар тагын бер-ике сүз алыштылар, тик сүзсез торган чакларында ныграк аңлаштылар бугай, туктаусыз елмайдылар.

Егет Фәхриев абыйсы янына керергә вәгъдә бирде дә иптәшләре артыннан йөгерде.

Егет киткәч, ул миңа таба борылды:

– Пенсиядә күңелсез түгелме, дип сорадыңмы әле бая?

– Әйе.

– Мәгънәле сорау!.. Күңелсезме, юкмы?.. Гомерең ничек узган бит. Эштән туктагач, уйланырга вакыт кала! Гомерең ничек үткән бит, менә нәрсәдә эш... Һади бу. Пыялачы егет! Сөйлимме аның турында?

Без ябалдашлары чак кына гөҗләшкән яшь агачлар астына кереп утырдык. Шунда ул, проспекттагы тәрәзәләргә карый-карый, Һади турында сөйләде. Бу хикәяне шуннан алып яздым.

1

Өстәлгә ике тәлинкә, юка гына итеп туралган ипи телемнәре һәм ике кашык куелган. Берсе зуррак, икенчесе кечкенә – сабы бөгелеп, кыегаеп беткән алюмин кашык. Тәлинкәләрнең берсе буш, икенчесеңдәге сөтле өйрә суынып, өстенә пәрәвез юкалыгы гына җыерчыклы элпә сарылган.

Бүлмәдә тып-тын.

«Челтер-р!» иттереп тәрәзә пыяласы коелган тавышка Маһирәнең йөрәге «жу» итеп китте. Авызына капкан икмәгеп дә йотып бетермичә, ул, абына-сөртенә, ишеккә атылды.

Урындык авып калды, аның тез өстендә ясмык кадәр генә кан күренде. Ул кулларын җилпеп егылудан чак котылды һәм коридорга чыкты...

Маһирә, ярым караңгы коридордан якты көнгә чыккач, беравык берни дә аермый торды. Күзе, иялләшә төшкәч, иң элек ямь-яшел мүк үсеп кутырлаган таш стеналар арасында почмакка поскан улы Һадига төште. Адашып калган хәлсез чебине сырып алган дәү каргалар кебек, аны бишалты хатын-кыз урап алган. Каргалар башында дәү козгын – керфексез күзле, юантык гәүдәле, беренче катта яшәүче инженер Сәйфуллин хатыны Өммегөлсем икән. Ул язгы судан калган таш кебек йомры, итләч йодрыкларын йомарлап, киң халат итәкләрен, җиңнәрен җилфердәтеп Һади өстенә очып-очып куна: малай туплы уйнаганда ялгыш аларның тәрәзәләрен ваткан икән.

Усал телле булулары белән тирә-юнь йортларында дан алган хатыннар, кулларына туп кадәр туп дәлил булып кергәч, бөтенләй тугарылганнар. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаепләрне куркудан дер-дер калтырап торган малай өстенә өяләр генә. Әллә кайчангы, кадимдәге хәлләр, югалган кер баулары, онытылып беткән сыңар галошлар, сөткә төшкән тычканнар, ниндидер велосипед тәгәрмәчләре дә телгә алына.

– Башыбызга кара хәсрәт булды инде! – дип, Өммегөлсемнең чәрелдәве аермачык ишетелеп китә.

Һади еламый, ул кечерәйгәннән-кечерәя һәм күгәргән стенага сеңә генә бара. Яңак һәм борын

тирәләрендә төрле түгәрәкләр ясап әйләнгәләгән йодрыклар артыннан күзе дә иярми аның... Кыйнамасыннар гына!.. Кыйный башласалар, берәрсенең корсагына баш белән төртергә дә камалыштан ычкынырга кирәк!..

Шул чагында малай башын күтәреп карый һәм өметсезләнеп нәни йодрыкларын йомарлый: ычкынып кая барырсың? Бөтен тирә-якта уннарча тәрәзәләр ишегалдына караганнар. Ух, бөтенесен ватып-кырып, томалап бетерәсе иде шуларның! Кинәнә-кинәнә, рәхәтләнеп кырыр иде ул аларны! Иркенләп уйнар хәл юк, йә берсеннән, йә икенчесеннән ачулы берәр кеше сузыла да: «Әй, кая чабасыз? Тәрәзә ватарсыз! Керләрне пычратмагыз! Чокырга төшмәгез! Тегеләй итегез! Болай итмәгез!» дип кычкырына башлый.

Һади ул минутларда хатыннарга түгел, тәрәзәләргә ныграк ачулы иде...

Хатыннар кыйнамадылар. Базмадылармы, яхшысынмадылармы, белеп булмый. Арттагы рәтләрдә торучыларның «Ятим бала бит, нинди тәрбия күрә ул!» дигән кызгану катнаш әрнүләре аларны тыйлыктырып тордымы, сукмадылар. Менә алар тез күмәче бәрелүдән бераз аксабрак килүче Маһирәне күреп алдылар. Малай бөкрәеп, кечерәеп бер кырыйда торып калды, каргалар яңа табышка – Маһирәгә ташландылар. Тавыш көчәйде, «П» хәрефе төсле итеп салынган бәләкәй ишегаллы йортның өч ягыннан да уннарча тәрәзәләр ачылды. Тузган чәчләр, чәбәләнгән сакал-мыеклар ишегалдына сузылды:

– Тагын Маһирә малаемы?

Сүз дә юк: ишегалдындагылар барысы да Һадины беләләр иде...

Ярты сәгатьтән Маһирә җилкәсенә зур агач тартма күтәргән берәүне иялтеп кайтып керде. Аңа ватык өлгене күрсәтте дә, беркемгә дә эндәш-мичә, өенә кереп китте.

Пыялачы, тартмасын ишегалды уртасында үскән бердәнбер агач янындагы өстәлдә калдырып, ашыкмыйча гына ватык тәрәзә янына килде. Чалбар кесәсеннән өтерге сыман әйбер чыгарып, рам җегенә кысылышып торган пыяла кисәкләрен кырып төшерде. Ишегалдының төрле почмакларына таралышкан бала-чага, уеннарын бүлеп, аны сырып алды. Баштарак кыяр-кыймас кына каранып торган Һади да тыгыз рәт булып баскан малайлар янына килде. Ул пыялачыга да, аны иярп кайткан әнисенә дә ачулы иде. Томалап, баягы кебек мендәр белән каплап куясы иде ул Сәйфуллиннарның өлгеләрен!

Ватык өлгене үлчәгәч, пыялачы тартмасыннан бер табак пыяла алып өстәлгә куйды. Үлчәде, кесәсеннән шомарып беткән күн савытка салынган бер әйбер тартып чыгаргач, алдарак торган малайлар:

– Алмаз, алмаз! – дип пышылдаштылар.

Пыялачы, малайларга күтәрелеп карап, калын тавыш белән:

– Кайсыгыз ватты? – дип сорады. Берничә малай Һадины алгарак эттеләр:

– Менә, менә ул ватты!

Пыялачы да кыйнарга җыенмый икән. Ул сүзсез генә башын чайкады һәм кисәргә әзерләнде. Шул чагында гына Һади аның сул кулының юклыгын күреп алды. Менә ул кисек беләге белән пыяланы кысты, чак кына янтайды һәм уң кулындагы алмаз белән «чыж-ж» иттереп йөртеп алды. Пыяла керт иттереп киселгәч кенә, Һади җиңел сулады.

Тагын бер эздән керт иттергәч, пыялачы алмазын яшерде һәм Сәйфуллиннар тәрәзәсе янына китте. Малайлар төркем булып аңа иярделәр, Һади да алардан калмады. Башта аның күзе гел пыялачыда булды. Тора-бара ул кинәт Сәйфуллиннарның өй эчен, радиоалгыч янына баскан олы малайларын күрде. Бозыласың, әшәке малайларга иярәсең, дип, әниләре балаларын ишегалдына чыгармый иде. Ул да Һадины күрде, таный икән, телен чыгарып күрсәтте. Теле дәү, Һадиның ямаулы кызыл бияләе хәтле бар икән... Улының кем белән булашуын күргәч, Өммегөлсем зарлана-зарлана пәрдәләрен тартып куйды.

Ул арада ишектән, буш чиләк тотып, Маһирә килеп чыкты. Ул да пыялачы янына килде. Авыр сулап алъяпкыч кесәсеннән унлык акча чыгарды. Пыялачы акчаны алгач, кая куярга аптыраган шикелле, кулында әвәләгән арада, Маһирә ялгыз яшәвен, үзенең кондуктор булып эшләвен, Һадины көндезләрен генә түгел, төннәрен дә ялгыз калдырырга туры килүен, күзәтү җитмәвен сөйләп зарланып алды.

Тормышта бик сирәк зарлана торган әнисенең бөтенләй чит-ят кешегә, җитмәсә, пыялачыга үз нужасын сөйләвен ишетеп үртәлгән Һади бер читкәрәк китте. Әнисенә карамаска тырышты ул. Өй кыегына кунган күгәрченнәргә күз салган булды, дүрткел бәләкәй күк йөзеннән үтеп барган сыек болытларга үрелеп карады.

Ул борылып караганда, пыялачы эшен бетереп, коралларын җыештырып тора, әнисе сыңар чиләк белән бөгелә-сыгыла су күтәреп кереп бара иде. Менә Маһирә бая Һадины кысрыклаган почмакка җитте. Эсседән эреп түбәдән аккан сумалалар чуарлаган шома ташлар арасында зәңгәр сәдәфне күреп алды. Ул чиләген куймыйча гына сәдәфкә үрелде, вакытсызрак өлкәнлек эретелгән йөзенә саран гына кызыллык йөгерде. Тол хатынның күңеле тулды, ул каптыр-кыптыр атлый-атлый тар ишеккә кереп югалды...

Бу бәләкәй сәдәфнең Маһирә өчен зур тарихы бар. Өйләнешкән елны ук ире Әхтәри, сигезенче

мартка дип, Мәһирәгә зәңгәр күлмәк бүләк иткән иде. Шул күлмәкнең җиң очында иде инде ул сәдәф. «Бигрәк яратам, карчык, шушы күлмәгеңне!» дия торган иде Әхтәри. Ләкин аларның бергә яшәү гомерләре аз булды. Әхтәри сугышка китеп барды. Мәһирә сугыш елларында күп кыенлыклар, кысанлыклар кичереп, артык-портык әйберләрен генә түгел, рәешкә асраган кием-салымын базарга илтсә дә, зәңгәр күлмәген бик кадерләп саклады. Ел саен яз да, көз дә җилләтеп алып керде. Әхтәридән дүрт ел эчендә сирәк кенә килеп торган өчпочмаклы кадерле хатлар белән саклады ул аны.

Кырык дүртнең көзендә яраланган Әхтәри, тылдагы госпитальдән фронтка үтеп барышлый, туган шәһәрендә бераз кунак булып чыкты.

Ире кайткан көннәрдә Мәһирә зәңгәр күлмәген киеп җиңeләеп, яшәреп йөрде... Төш кебек кенә булып калган бу кыска очрашуның өн икәнлеген раслап аларның уллары Һади туды. Үзе кебек үк зур күзле, олырак авызлы томрап торган улы дөньяга килгәндә, Әхтәри Берлин янында, бәләкәй генә зиратта, чит илнең салкын туфрагында ята иде инде...

Озак көтте Мәһирә ирен. Зәңгәр күлмәген әллә ничә яз җилләре, көзнең саран кояшлары киптерделәр. Кояш-яңгырдан уңып беткән кырык төенле кер бавында җилләтергә соңгы елларда нибары шул зәңгәр күлмәк кенә калды. Түзмәде Мәһирә, соңгы өметләрен яндырып, ул күлмәген дә кия башлады. «Исән-аман кайтып җитсә, әллә нинди күлмәкләр юнәтә торган ир әле!» — дип юатты ул үзен. Зәңгәр күлмәк тузып, итәкләре, җиңнәре сизри башлагач, Мәһирә аңардан вак-вак капчыклар текте. Әхтәри ранный булып ятмыймы, берәр җирдән хәбәре килмәсме, дип, соңгы акчаларына сатып алып шул капчыкларга кипкән өрекләр, урман чикләвекләре тутырып тотты.

Өрекләр ашалды, чикләвекләрнең истәлеге булып урындык башларында бәләкәй чокырлар калды. Чикләвекләр белән тәгәрәп Мәһирәнең улы үсте. Зәңгәр капчыклар тузып, өстәл сөрткеч тастымалларга әйләнделәр. Тик җиң очындагы сәдәфләрне саклый иде Мәһирә. Улы үсә төшкәч, күз алдында булсын, дип, аның күлмәк изүенә таккан иде ул аларны. Бала ананы аңлыймыни соң ул?! Әнә бит, югарыга караган да каткан... Мәһирәнең улына рәнҗисе бик килде, тик теле әйләнмәде, ул, күлмәк итәкләренә су чайпалта-чайпалта, ачы кәбестә исе аңкыган ярым караңгы коридорлар, кухнялар аша үтеп, бүлмәсенә кереп югалды.

Пыялачы, эшен бетергәч, йөнтәс кашларын күтәреп, малайларга карап торды. Аннары ишегалдына күз салды. Тар иде ишегалды, ә малайлар бик күп, артык күп иде...

Авыр тимер капкалары як-якка кыйшайган таш баганалар янына барып җиткәч, пыялачы тагын артына борылып карады. Башка балалар кайсы кая таралышканнар, нидер кычкырышып уйнап маташалар, борыны купшакланган, дәү күзле, олырак авызлы малай гына, кулын зурларча артка куеп, аңа карап тора иде. Ямаулы күлмәгенең ачык изү-еннән ябык күкрәк сөякләре күренеп тора.

— Әй, малай! Монда кил әле!

Һади, сәерсенеп, як-ягына каранып алды.

— Син инде, син!

Капка янына килгәч, пыялачы күрде: малайның аяклары чебиләп беткән. Пыялачы тын гына аңа карап торды да бая Мәһирәдән алган унлыкны малайга сузды:

— Бар, әниеңә кертеп бир.

— Кирәкми, абый.

— Ал инде, ал!

— Алмыйм. Мин озакламый үзем эшли башлыйм.

Пыялачы көчләп диярлек малайга унлыкны тоттырды һәм кабаланып, урамдагы ыгы-зыгы арасына кереп югалды. Ара-тирә аның киң җилкәсенә менеп кунаклаган дәү тартма гына күренеп китте.

Унлыкны учына йомарлап, малай шактый озак басып торды. Кызган ташлар кайракланган аяк табаннарын рәхәт кенә иркәлиләр иде. Ул Сәйфуллиннар турысына күз салды, тузан кунарга өлгермәгән яңа өлге ялтырап, башкалардан аерылып тора иде.

Ул ишегалдына атлауга, ачык тәрәзәләрдән шөпшә кебек озын бармаклар сузылдылар:

— Әнә сугыш чукмары кайтып бара!

— Әнә тәрәзә ватучы!..

Дәшми-тынмый гына үтеп китәргә уйлаган Һади ике кызны комга төртеп екты, алар акыра башлагач, унлыкны кысып тотып, чатыр-чотыр чабып икенче катка менеп китте.

Бусагада юаш кына басып торган улын Мәһирә кочаклап ук алды. Шелтәләргә теләде, булдыра алмады. Муенына тамган кайнар тамчылардан сискәнеп китте малай.

— Җылама, әни! Моннан болай ватмам шуларның тәрәзәләрен, — диде ул.

— Әй, улым, улым! Бигрәк тар шул уйнар урыннарыгыз... Мәһирәнең күзе улының аягы янында яткан унлыкка төште.

— Бу нәрсә тагын?

— Теге абый бирде.

Таный аны Мәһирә, таный... Шул унлык икән шул... Ананың күңеле тагын да нечкәрә төште, ул Һадины тагын да кысыбрак кочаклады:

— Алай шукланырга ярамый бит, улым... Ярамый. Әтиең дә яратмас!

Кояшның чыгуын да, баюын да ишегалдында бер чагында да күреп булмый. Әмма караңгылык бер ашыкса, бик тиз иңеп, тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп утлар алдыра. Кемнәрдер эштән кайта-лар, кемнәрдер эшкә бара, ишегалдында зурлар хәрәкәте.

Кич җитүгә, Маһирәнең тынычсызлыгы арта төшә: баланың өстеннән бикләп, төнге сменага эшкә барырга кирәк. Ул шыпырт кына аңа ашар-га-эчәргә әзерли, саран гына сүзләр белән аны үгетләргә керешә:

– Ары-бире сугылма, тамагыңа аша да ятып йокла!

Әнисенең аяк тавышлары тынуга, Һади ипи белән сөтне ялт иттерде дә салкын су белән генә чынаяк чокырын юып куйды. Шуның белән эш, ма-выгулар бетеп тә китте. Ул әрле-бирле йөренде, караватастыннан тычкан тәбесе тартып чыгарды, кире куйды һәм урынга менеп ятты.

Кайдадыр еракта зыңгылдап трамвайлар узды. Күкне шаулатып самолет үтте. Әмма ул арыган иде, авызын тәмләп чәпелдәтә-чәпелдәтә җәйрәп, рәхәтләнеп йокыга да китте.

Шәһәр уртасына утырган ишле кешеле бу йортның башка тәрәзәләрендә дә берәм-берәм утлар сүнде. Доминочылар китүгә, ишегалдына парлылар кайтты. Алар караңгырак почмакларга, аулаграк урыннарга басып үбешәләр. Ап-ак пәр-дәләр эленгән тәрәзәләр аларга кул болгый. Бе-леп кенә булмый, хуплыйлармы алар парлыларны, әллә ашыкмаска өндәп кисәтәләрме? Егет кызны ныграк кочаклый һәм тәрәзәләр ишетмәслек итеп кенә:

– Бүлмә тапкач та өйләнешәбез, җаным! – дип пышылдый...

2

Һади кызган май исенә уянып китте. Яп-якты! Әнисе, эштән кайтып, майлы таба тирәсендә бу-лаша. Малай, сикереп торган уңайга бер-ике кой-макны элдерде дә, томырылып, баскычтан төшә башлады. Күрше карчыгы су алып менә икән, җан-фәрманга атылып төшкән Һади бүксәсе белән чиләккә барып та бәрелде. Карчык сукранып тор-мады, ябык йодрыгы белән малайның җилкәсенә генә кундырды. Һади шул шәпкә ишегалдына аты-лып чыкты.

Тик юеш чалбар белән кеше күзенә күренергә ярамый... Ул тиз генә Сәйфуллиннар тәрәзәсен карап килергә һәм өйгә керергә ниятләде. Ише-галды уртасына җитүгә, аның күзе кичтән домино-чылардан калган таякка төште. Юан, шоп-шома, әйбәт таяк... Тукта әле. Бу таяктан уенчык тәрәзә рамы ясап җибәрсәң!.. Пыяла да тапсаң...

Ул як-ягына каранды да, таякны элдереп, һәрвакыт ачык авызлы ишеккә чумды. Коймак ти-рәсендә әвәрә булып йөрүче Маһирә күрми дә калды, малай таякны ялт итеп караватастына шу-дырды. Күрмәве хәерлерәк, йә ачулана башлар... Тәрәзәне Һади әнисе югында ясап куяр... Соңын-нан, әзер булгач кына күрсәтер. Менә мактар ин-де әнисе!

Ашап-эчеп алгач, Маһирә йокларга ятты. Шу-ны гына көтеп торган Һади таякка ябышты, ты-рышып-тырмашып аны дүрткә ярды һәм эшкә ке-реште.

Дөп-дөп йөргән аяк тавышлары Маһирәне тәмле йокысыннан уяттылар. Күзен ачса, бусага янында дүрт-биш кеше басып тора. Идәндә йо-мычкаларга, чыраларга күмелеп, киселгән чәнчә бармагын кысып, улы Һади утыра.

– Менә күр инде!

– Шул малай актыгы алгандыр, дип әйтемме мин сезгә?

– Нәрсә булды тагын? – дип сорады Маһирә, караватбашындагы яулыкка үрелеп.

– Нәрсә булсын! Менә Сәмигулла абзый тая-гын ишегалдында калдырган. Синең малаең шуны урлаган.

Юаш, басынкы Сәмигулла карт бер читтәрәк тора һәм бу шау-шуны кузгатуына үкенгән сыман сакалын тарткалый иде.

– Син, Өммегөлсем килен, алай димә әле... Сабый кызыккандыр да алгандыр, диген.

– Мин тәрәзә ясыйм, – диде малай, зур күз-ләрен мөлдерәтеп. Өммегөлсем дәррәү чәрелдәп кычкырды:

– Ясый, һе, кара әле берәүләрне!

– Син тәрәзәләрне вата гына беләсең!

– Синең ишеләрдән гомергә игелек буласы юк!

Ачык тәрәзә турысына бөтен ишегалды җыел-ды. Сәмигулла акрын гына Маһирәләрдән чыгып китсә дә, ярсыган хатыннар тиз генә тыела алма-дылар. Малай, әнисенең яшь белән чыланган яңакларына карап, калтыравыклы тавыш белән:

– Мин чыннан да тәрәзә ясыйм, әни. Менә рамнары. Менә... – диде. Ниһаять, бүлмә тын ка-ла. Маһирә улының киселгән бармагын ак чүпрәк белән бәйли, аның яшь тулы күзләрен күреп кочаклап үзе дә елап җибәрә:

– Алай ярамый бит инде, улым! Ярамый...

Кич белән Маһирә тагын эшкә китә. Малай аның җыенуын сүзсез генә күзәтеп торды да:

– Әни, бүген ишекне бикләмә инде. Мин ише-галдында аз гына уйныйм да керәм, – диде.

– Ярамый, улым.

Маһирә бер шешә сөт белән бер кисәк ипине сумкасына салды.

– Әни...

– Ярамый, улым...

– Печтик кенә, нәни генә уйныйм.





– Азга гына түз инде. Минә ике көннән көндезге сменага күчәм. Үзеңне Ботан бакчасына алып барырмын. Арысланнар китергәннәр, ди.

– Арысланнар? Әй, читлектә бит алар! – Малай өметсезләнеп ишеккә карый, нәни йодрыкларын йомарлап күз тирәләрен уа. Минә теге якта йозак чылтырый һәм Маһирә апа соңгы кат улына эндәшә:

– Улым, әйбәт кенә бул.

Менә ул почмактагы ярыкка ачкычны яшерә, баскыч араталары ямьсез шыгырдыйлар.

Ишегалдына чыккач, Маһирә тәрәзәгә күтәрелеп карады. Юк, Һади үпкәләгән, күренми...

Күңелсез кич җитә. Һади әйләнә, тулгана, мендәрен изеп бетерә, тик йокы һаман килми. Урамда чыр-чу, чыңгылдап трамвайлар үтеп китә. Менә күрше карчыгы да кереп килә. Малай атылып ишек янына бара.

– Апа-у!

– Нәрсә бар? – дип сорый кырыс тавыш.

– Почмакта, примус астындагы ярыкта ачкыч бар. Ишекне генә ач инде, апа.

– Кая барасың?

– Монда гына, монда гына, апа!

Аяк тавышлары ерагая:

– Өеңдә генә утыр!

Малай, кеше үткәнен көтеп, колагын ишек ярыгына куеп, бик озак бусагада утыра. Тырнаклары белән ишекне тырнап чиртеп карый.

Тәрәзәдән айлы төн бүлмәгә карый. Тамчылы гөлнең хисапсыз күп алкалары көмештән коелгандай ялтырыйлар. Шундый көмеш алкаларың булсын икән дә шуларны әниеңә бүләк итсәң икән!.. Малай бер тамчыны өзеп алып учында уып карый. Аннары гөл чүлмәкләрен бер кырыйга этеп, түше белән тәрәзә төбенә ята.

Тәрәзәләрдә бер-бер артлы утлар сүнәләр. Почмакларда егетләр, кызлар торалар. Малайның дәрте, теләкләре күкрәгенә сыймый, аның бу тәрәзәләр белән чуарланган ишегалдыннан читкә, еракка китәсе, теләгәнчә уйныйсы, чабасы, йөгерәсе килә. Ашыгып ишеккә килә, ябык иңнәре белән этеп карый. Аннары, ачуы кабарып, мич алдыннан ярты кирпеч табып ала, тәрәзә каршысына килә. Каршыдагы сары тәрәзәдә кемнәрнеңдер шәүләләре уйный. Малай тешләрен кыса да бар көченә кирпеч кисәген тәрәзәгә тондыра... Шәүләләр куркышып сикерәләр...

«Челтер-р!» иттереп пыяла коелган тавыш яңгырый. Кемнәрдер тап-топ чаба башлыйлар. Ярты сәгать үтәр-үтмәстән ишегалдында милиция сыбызгысы яңгырый.

Малай карават астында бөгәрләнеп ята. Ишек бикле шул, ача алмыйсыз!.. Ә ачкычның кайда икәнен ул сезгә гомердә дә әйтмәс!..

3

Маһирә икенче көнне улын урамга бөтенләй чыгармады. Ана баласы өчен чын-чынлап куркуга төште. Әллә ишегалдындагыларның сүзе раска чыгамы, хулиган, башкисәр булып үсәме әллә аның улы? Өй эчендә ифрат тыңлаулы, хәленнән килгәнчә әнисенә булышып, ярдәмләшеп йөрүче бала ишегалдына чыккач нигә үзгәрә?..

Балалар бакчасына урнаштыра алмады шул ул аны!

Яңа квартира да кайчан бирерләр әле. Ни дисәң дә, кысан булса да, торыр куышыгыз бар, диләр...

Ә тол калып, мең хәсрәт белән күз текәп үстергән бердәнберең юньсез булып чыкса, нишләрсең? Нинди чараларын күрергә, нишләргә инде ялгыз анага?..

Һади, әнисе алдында гаебен сизенеп, тын гына юнышып утыра. Утыра торгач, аның түземе бетеп китте, малай киерелгәләде, сузылгалады, тәрәзә яныннан әйләнеп килде. Каршыдагы квартирага пыялачының килүен көтә иде ул. Әллә аның оста кулы, әллә аталарча ягымлы карашы малайның йөрәгенә кереп калган иде.

Пыялачы төш вакытында гына килде. Каршы квартирада хәрәкәт башлануыннан сизде моны малай. Әнисе ял итәргә яткан иде. Ул, аңа сиздермәскә тырышып, тәрәзә янына килде һәм пәрдә почмагын ачып күзәтә башлады. Менә тәрәзә ачылды, менә ике кул сузылды. Менә пыялачының башы күренде. Ул түгел лә бу!

Малайга кинәт кенә күңелсез булып китте. Кичәге абый нигә килмәгән инде? Ай-яй оста эшли иде! Монысы аның кебек үк булдыра алмый торгандыр әле, мөгаен. Берәр почмакта ярык калдырыр да китәр әле менә. Монысының да алмазы шулай ялтырый микән? Юк, кичәге абый кебек керт итеп кенә кисеп төшерә алмас бу, тотынуы ук башка бит тегенең. Их, шул абыйга ияреп, йорттан йортка пыяла куеп йөрисе иде!

Үз башына килгән бу дуамал фикердән малай тынычлыгын җуйды. Гөл сабакларын сындыра-сындыра, тәрәзә төбенә үк менеп, пыялачының ялтыр-йолтыр маташканын карап тора башлады. Теге абый ник килмәде, дип кычкырыргамы әллә? Әнисе уяныр инде...

Пыялачы эшен бетереп, тәрәзәне ябып куйды. Һадига кызык та бетте. Ул яңадан чыралары, йомычкалары янына килеп утырды. Аның эче поша, кулы кычыта, аяк табаннары кымырҗып тора иде. Ул нәүмизләнеп ишеккә карап алды. Әнисе иртән: «Ишетсен колагың, бусаганы атлап чыгасы булма!» – дип кисәткән иде.

Ялт итеп кенә чыгып, теге абый турында сорашып керсә? Әнисе сизми дә кала ич!

Һоп лә! Баскыч аралалары шыгырдарга да өлгерми калдылар. Һади, бала-чага өерен ерып, уртагарак чыкты да күрше кызыннан:

– Пыялачы абый сездә чәй эчеп утырамы әллә? – дип сорады.

– Белдең, – диде кыз. – Ул әллә кайчан китте инде.

Малай бер секунд уйланып тормастан капкага йөгерде. Пыялачы урамда да күренмәде. Сорап кала алмавына әрнегән малай кичәге абый киткән якка карап чаба башлады.

Сулуы кабынды, урам ташлары ялан тәпине чагып авырттырдылар. Һади әллә никадәр абыйларны, апаларны куып узды, тик җилкәсенә агач тартма утырткан кеше күренмәде.

Бер бакча янындагы су сатучы янына җиткәч, малай тукталды. Кипшергән иреннәрен ялаштырып карап торды да кеше юграк вакытта су сатучы янына килде.

– Апа, пыялачылар кайда эшли, белмисезме?

– Нинди пыялачылар?

– Тәрәзә пыяласы куючылар.

– Каян белим ди мин? Әнә тегендә йортлар салалар, шунда эшлиләрдер.

Малай, башын иеп, борынын тартты:

– Апа, буямыйча гына бер стакан су эчерт әле.

– Акчаң бармы?

– Юк.

Хатын, сыек кына кызартып, малайга бер стакан су сузды:

– Әтиеңнән алгач, килеп түләрсең.

Малай йотлыгып суны эчеп бетерде:

– Озакламый үзем эшли башлыйм мин!

– Әллә?

– Рәхмәт!

Һади чаба-чаба тукталышка килеп җитте.

Иң кирәгеге – йортлар сала торган җиргә трамвай белән барып булуын ул белеп алган иде инде.

Шактый бардылар. Вагондагы кешеләр әллә ничә кат алышындылар. Ахыргы тукталышта Һади төшеп калды. Зур-зур күтәрү краннарын, дәү-дәү йортларны, әллә нинди машиналарны күргәч, малай авызын ачып катты да калды.

Йортларның инде салынып бетеп килгәннәре дә, ярты юлдагылары да бар иде. Машинага төялгән кызлар Һадига кул болгап кычкырып уздылар. Йортлардагы йөзләрчә тәрәзәләрне күргәч, ул бөтенләй югалып калды. Тәрәзәләрдә кешеләр, өстә кешеләр, аста кешеләр... Исемен дә белмәгән килеш пыялачыны каян эзләп табарсың монда? Былтыр Ботан бакчасында әнисеннән аерылып калып та аһ иткән иде. Халык та күпме генә иде әле анда...

Кая барып керергә белмичә, ул ары-бире сугылды, экскаваторның эшен карап торды. Якында гына үз исемен ишеткәч, малай сискәнеп китте.

– Һади, нишлисен монда?

Караса, Сәйфуллин икән. Малай, шүрләп, артка чигенә башлады.

– Тукта, тукта! Нигә килдең монда?

Һади ычкынып чаба башлады, абынып егылды. Сәйфуллин көлеп җибәрде:

– Кая качасың, җүләр?! Мондарак кил. Ни эзлисең, әйт?

Малай ык-мык итте дә сөйләп бирде. Малайның йомышын белгәч, ишегалдында бик кырыс, куркыныч булып күренгән Сәйфуллин озак кына көлде, аннары аңлатып бирде. Шәһәр уртасында «Ремстройконтора» дигән бер урын бар икән, ватылган өлгеләрне шундагы пыялачылар куя икән. Сәйфуллин төшендереп кенә калмады, малайны үзе белән ияртеп китте, трамвайчыларга дип атап салына торган йортны күрсәтте, соңыннан, үтеп баручы машиналарны туктатып, малайны шуңа утыртып та җибәрде.

Бәхет бер килсә килә бит ул! Һади контора алдына кадәр гөжт иттереп машинада утырып килде. Рәхмәт әйтеп төшеп калды. Кызганыч, малайлар күрмәде! Сөйләсәң, ышанмаслар!.. Ә Сәйфуллин тәрәзә өчен орышмады да, бары:

– Син тәрәзә кырып йөрмә инде алай. Дәү үскәнсең бит, – дип кенә куйды...

Контора ишегеннән керүгә, аны тәбәнәк кенә бер бабай туктатты.

– Әй, әй! Кая барасың, малай?

– Миңа пыялачы абый кирәк иде.

– Ә-ә, тәрәзәгезне кырдыңмы?

– Юк, болай гына.

Карт шунда ук кырысланды:

– Болай гына монда килеп йөрмиләр. Бар, бар! Чык!

Һади киреләнде:

– Чыкмыйм, – диде ул. – Миңа пыялачы абый кирәк.

– Вәт, Ходай кошы! Кайсысы кирәк? Алар монда унлап, йөзләп!

Карт бераз гына арттыра иде. Малай пыялачының кыяфәтен сөйләп биргәч, ул башын чайкады һәм, ачы төтенле челемен суыра-суыра, уңга кереп китте. Бераздан кире чыкты һәм эндәшмичә генә үз урынына – барьер артына кереп утырды. Малай сораулы күзләре белән аңа текәлде.

– Юк ул бүген. Килмәгән. Килми дә. Ишеттеңме? Фәхриев абыең була инде ул.

– Кайда соң ул?

– Больницага кергән.

– Больницага?

– Әйе. Пыяла куярга барган икән дә, синең кебек бер тузга язмаганы ул менгән баскычны аударып җибәргән. Аягын сындырган Фәхриев.

– Бабай, – диде Һади, еламсырап, – кайсы больницада икән?





– Мин каян белим.

– Бабакай...

– Бар, бар, мыек чуалтып йөрмә әле монда.

Карт, ачуланып, аралыгына кереп китте. Аралык артындагы гыжылдавык сәгать дүртне сукты! Сәгать дүрт! Әнисенең эшкә китәр чагы җитә! Һади баскан урынында тыпырчынды.

– Китмәдеңмени әле син?

Малайның яшьле күзләрен күреп, карт, сукрана-сукрана, тагын үңга кереп китте.

– Жиденче больницада. Беләсеңме, теге Чкалов урамында. Очучы Чкаловны беләсеңме?..

Больницада Һадины бөтенләй санга алмадылар. Керту кая ул, якын да җибәрмиләр, усал-усал апалар куып ук чыгардылар. Тагын әйләнеп керде Һади. Апалар бу юлы кумадылар, аның чебиле аякларын бер-берсенә күрсәтә-күрсәтә көлештеләр. Кемең ул Фәхриев, әтиеңме, фәләнфәсмәтән дип сораштылар. Ул арада эчке бүлмәләрнең берсеннән өлкәнрәк хатын чыкты. Аны күргәч, мондагылар авызларын җыйдылар. Шул апа Һадины Фәхриев янына кертергә кушты.

Бүлмәдә иң элек ул зуп-зур тәрәзәләрне күрде. Ай-яй олы! Ишегалды ап-ачык күренеп тора! Ишегалдында агачлар, чәчәк түтәлләре.

Ә менә Фәхриев абый да монда! Ул аркасын мендәргә терәп яткан да елмаеп карап тора. Бер аягын әллә ниләр белән бәйләп, урап бетергәннәр.

– Бер малай, дигәч, кем икән, дип аптыраган идем. Син икәнсең, – диде ул, исе китмичә генә.

Ул кар кебек ак җәймәләр арасыннан кытыршы, дәү кулын чыгарып малайның кояшта уңган житү чәчен сыйпады.

– Килдеңме?

– Килдем.

Малай кат-кат борынын тартып куйды.

– Ни атлы әле син?

– Һади.

Малай пыялачыга туп-туры карады.

– Ә син Фәхриев абый.

Пыялачы тагын көлемсерәде.

– Авыртамы, абый?

– Печтик кенә. Кул ныграк авырткан иде.

– Анысын кайда кистеләр?

– Анысын... Берлин янында.

Малай, Берлин дигәнен ишеткәч, тагын ишегалды якка карады. Анда түтәлләр арасында ак халат кигән хатыннар йөриләр иде. Баягылар түгелме? Күреп Һадины ачуланмасलармы?

– Ай-яй тәрәзәләре зур! – диде малай, шаккатып. – Нигә болай олы иткәннәр инде?

– Зур, – диде пыялачы, малайның башыннан сыйпап. – Сиңа ошамыймы әллә? Яратмыйсыңмы?

Малай яратмавын раслап башын чайкады. Аларның ишегалдында мондый зур тәрәзәләр булса, бөтенләй аптыраш булыр иде. Пыялачы исә үзе янында кечкенә малай утырганын онытып җибәрдеме, әллә уйланып яткан фикерләрен әйтергә җай чыктымы, тәрәзәләргә карап сөйли башлады.

– Әйбәт ул зур тәрәзәләр!.. Бүлмәләр якты була. Аннары тыш та ап-ачык күренеп тора. Тәрәзә каршында бакча да булса, ә, Һади!.. Кешене тышкы дөнья белән бәйли бит ул тәрәзә... Шуның өчен зур булсыннар алар. Тәрәзә алларында бакчалар, гөлләр булсын...

Малай эндәшмәде, ул, мышык-мышык борынын тартып, пыялачыдан күзен алмый иде. Менә пыялачы тумбочка өстеннән бер телем ипи алып аңа тоттырды:

– Аша, ачыккансыңдыр.

Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып:

– Тәмле! – диде.

Икмәк телеме күз ачып йомганчы юкка чыкты. Пыялачы тагын аның башыннан сыйпады.

– Ә хәзер бар, кайт инде. Әниең көтә торгандыр!

– Мин иртәгә тагын килимме? Минем синең белән эшлисем килә, Фәхриев абый...

Пыялачы сүзсез генә башын иде.

Һади, халат итәкләренә уралып, коридорга ташланды. Әнисе югалткандыр инде аны! Фәхриев абыйсы:

– Ишек пыялаларын ватма! – дип кычкырып калды. Малай халык белән кысыла-кысыла вагонга керде. Кондуктор билет алырга кушкач, эре генә:

– Минем әни үзе кондуктор, – дип җибәрде.

Аңа тимәделәр. Менә ул вагон почмагынарак басты да әнисен дә, тизрәк кайтырга кирәклеген дә онытып, ике яклап артта кала торган йортларга карады. Үзе дә сизмәстән йортларның тәрәзәләрен саный башлады ул. Менә бер йорт... Аста сигез тәрәзәсе бар. Монысында унбиш... Тик бик кечкенәләр... Алар бакчага да, шып-шыр ишегалдына да, урамга да карыйлар.

Ә Фәхриев абый, тәрәзәләр бакчага карасыннар, ди... Шул абый кебек булсаң иде ул! Аягын авыртмый дип юри генә әйткәндер әле, мөгаен... Авырта инде анысы! Әле менә Һадиның бармагы гына киселгән иде... Шуның кебек пыяла куеп йөрсәң иде... Бакча ягы тәрәзәләренә...

Трамвай туктаусыз зыңгылдый, селкенә, малай исә ике кулы белән дә чытырдатып ябышкан да үзе янынннан артка чигенүче йортларның тәрәзәләрен саный. Бүген тәрәзәләр аңа ниндидер әкиятләр дөньясын ачучы бәхет капкалары булып тоелалар. Ул йотлыгып, бирелеп карый һәм үз капка төпләрендә моңаеп, аптырап басып торучы әнисен дә күрмичә зыңгылдап үтеп китә...

1960

Фәрит ЮСУПОВ

Ашказар

Урал тауларын кичеп чыгуга, урманлы-далалы туфраклар башланып китә. Аны Урал арты төбәге дип атап йөртү кабул ителгән. Хәзерге көннәрдә бу җирләрдә милләтебезнең бик үзенчәлекле ике төркеме яши: сафакүл һәм әчкен татарлары. Уналтынчы гасырның башына кадәр әлеге җирләр Себер ханлыгына караганнар. Бик борынгы заманнардан бирле алар аша Кытайдан һәм Урта Азия мәмләкәтләреннән Идел Болгарстаны аша Европага зур юл үткән. Шушы юллар буйлап тезелеп утырган татар авыллары юлчыларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнгәннәр. 1580-1581 елларда Себерне яулап алу өчен килгән рус гаскәрләре дә әлеге юлдан килгәннәр. Соңрак бу якларда яшәгән себер татарлары, казан татарлары белән катнашып, бөтенләй башка кавем барлыкка китергәннәр. Ләкин җирле татарларның бик борынгы заманнардан килә торган бай рухи мәдәнияте әле дә булса үзенең яшәвен дәвам итә.

Сафакүл татарлары гомер-гомергә тирә-яктагы төрки халыклар арасында оста җырчылар булулары белән дан тоталар. Алар бүгенге көнгә кадәр ерак ата-бабаларыбыздан килгән җырларны иң кадерле җәүһәрләр итеп саклап киләләр. Шундый җырларның берсе – «Ашказар». Элек бу җыр Курган өлкәсендә яшәүче сафакүл һәм әчкен татарлары арасында озын итеп җырлана торган бик популяр җыр булган. Бер генә мәҗлес тә, бер генә туй да «Ашказар» җырын җырламый таралмаган. Хәтта мәҗлесләрдә бу җырны берничә кеше үзләренә генә хас импровизация белән башкара торган булган. Әле дә татар авылларында бу җырны башкаручыларны сагынып искә алалар. Әйтергә кирәк, әле бүген дә һәр авылда бу җырны һәркемне әсир итәрлек итеп башкара торган өлкән буын вәкилләрен очратырга мөмкин. Җырлаучыны көйнең гүзәллеге генә түгел, бәлки бу җырның тууына сәбәп булган вакыйга-фаҗига тетрәндерә. Җирле халык риваятьләрендә татар халкының күп кенә төбәкләрендә яратып башкарыла торган бу җырдагы вакыйгалар Сакмар елгасы янында булган дип сөйләнсә дә, сафакүл татарлары, чын күңелләреннән, аны үз авылларында булган дип ышанып яшиләр.

...Борын-борын заманда бер бай гына татар кешесе үзенең бердәнбер улын бу авылдан шактый гына еракта булган икенче бер татар авылының иң чибәр һәм иң зирәк кызына өйләндерә. Кәләш тә, кияү дә ике авылның да яраткан яшьләреннән саналган. Туйны ике авыл да бик зурлап, бик күп халыкны чакырып үткәргәннәр. Бу якларга хас булганча, яшь кияү туйдан соң кәләш өендә кияүләргә кала. Кәләшнең атасы да шактый хәлле кеше булганга, ул яшь кияүне барлык йола-гадәтләрне җиренә җиткереп кунак итмичә, яшьләрне кияү ягына кайтарып җибәрергә теләмәгән. Кәләш ягыннан булган барлык туганнарда да кунак булу, көн саен ягылып торган кияү мунчаларына керү, кичләрен авыл яшьләре белән уеннарга чыгу белән өч ай үтеп киткәне сизелми дә кала. Кайната өендә ничек кенә рәхәт булмасын, ниһаять, яшь кәләшне кияү йортына күчерү вакыты килеп җитә. Кышның беренче көннәре. Беренче салкыннар, бөтен якка сафлык бөркеп торган беренче кар, беренче чана юлы... Күл өсләрен көзге кебек ялтырап торган юка боз каплаган...

Киленне озатырга бөтен авыл чыга: бихисап иптәш кызлары, кыз йеңгәләре, кәләш ягыннан булган яшь егетләр, кияү егетләре – нугәрләр. Киленнең бирнәсе белән тум-тулы бизәкле сандыклар, яңа гына телелгән юкә такталардан эшләнгән махсус сандыкта килен бәлешләре, кызның даны һәм шөһрәте турында сөйләячәк кыз кагыты (җир җиләгеннән әзерләнгән как), килен чәк-чәге, кыз төшүгә багышланган килен чәе мәҗлесенә җитәрлек итеп пешерелгән майлы бавырсаклар, дала чиясе катыш-

тырып ясалган чияле майлар, дистәләрчә пешкән дә, пешмәгән дә каз-үрдәк белән шыплап тулган икенче сандык, сандыклар өстенә өелгән затлы урын-җирләргә сабантуй әтәче кебек кукыраеп утырган малайлар төялгән туй чаналары, кыз авылыннан чыгып, кияү авылына юл тота. Юллар авыл араларын бизәп утырган зәңгәр күлләр аша үтә. Талъян моңы, шаян җырлар...

Ул яктагы һәр егетнең, тормыш мизгелләреннән ләззәт таба белгән һәр яшь ирнең канында сунарчылык дәрте ята. Ул бик борынгы бабалардан ук килә торгандыр, мөгаен.

Олы Күлгә җитәм дигәндә генә, көтмәгәндә туй чаналары алдыннан бер төлке йөгереп үтә. Туй көймәләрендәгеләр аның артыннан сызгырып, кычкырып калалар. Төлке, бернәрсәгә дә исе китмәгәндәй, юлны ашыкмый гына кисеп чыга да күл кырыендагы камышлыкка кереп югала. Кияү чанадагы печән астыннан ау мылтыгын алырга өлгерми дә кала. Туй озаткычларыннан берәү уфтанып: «Хәерлегә түгел бу», – дип куя.

Бу яктагы татарлар арасындагы ырым буенча, бара торган юлыңны төлке, куян, йомран кисеп чыгу хәерсезлеккә юрымлана. Бу көтмәгән хәлдән һушына килергә дә өлгермәгән юлчылар алдына каяндыр саескан килеп чыга. Ул да юлдан юырткан чаналар алдыннан җай гына бер кунып, бер очып бара. Бу туйчыларны бөтенләй куркуга сала. Шул вакытта камышлар арасына кереп югалган төлке, кире ат юлына чыга да, юл буйлап чаба башлый. Яшь кияү ау мылтыгын тоткан килеш төлке артыннан йөгерә. Әнә ул, хәлсезләнгән кыяфәттә, яр буендагы боз өстенә кереп ята. Кияү егет кулы белән аның йомшак тиресенә сузыла. Төлке, уянып киткәндәй, тагын да өскәрәк кереп ята. Кияү – аның артыннан. Көзге юка боз яшь кияүнең авырлыгын күтәрә алмыйча ярыла да, кияү егет боз астына китә.

Бу фаҗига әйләнә-тирәдәге бар кешене дә тетрәндерә. Кара кайгы эчендә бер ел узып та китә. Егетнең әтисе улының елына, тирәк-яктагы бөекләрне чакырып, Коръән ашы үткәрә. Коръән укылып, аш мәҗлесе дә тәмам булганнан соң, әтисе улының истәлегенә җыр чыгару өчен бәйге игълан итә. Күп кенә чәчәннәр, бу хәлнең буласын алдан ук белеп, үзләренең җырлары белән килгән булалар. Беренче, икенче, өченче... бишенче җырчы тыңлана. Ата кеше боларның берсен дә күңеленә якын итми. Картның каршына башын зур йон яулык белән каплаган талчыбыктай зифа бер сылу килеп баса. Бу – бер ел элек вафат булган яшь кияүнең кәләше.

– Атайым, – ди ул, карт ишетә алырлык әкрен тавышы белән, – минем дә үземнең җырымны сезгә җырлап күрсәтәсем килә, – дип, тирән сагышлы көен башлап җибәрә. Бөтен халык хәйран кала. Ике яшь йөрәкнең фаҗигасы, тагын бер кабат яңарып, һәркемнең күңелен телгәли башлый. Шуңа күрә дә бу җыр, һәр җырланган саен, үзенең тарафдарларын күбрәк таба бара.

(Риваять, шулай ук җырның тексты һәм көе 2012 елда Фәрит Юсупов тарафыннан Курган өлкәсе, Атҗитәр авылында Ситдыйкова Фәрдәнә Галисолтан кызыннан (1925 елда туган), Ситдиков Фәйзрахман Рамазан улыннан (1925 елда туган) язып алынды.)

Фәрит ЮСУПОВ, профессор,
Халыкара «Тел коруму» (Төркия — Әнкара)
җәмгыятенең мөхбир-әгъзасы

АШҚАЗАР



Җанкай-җанаш китте, ай, сунарга(й),
Ашказаркай буе чәшкегә(й).
Ә-ә-й, Ашказаркай буе чәшкегә(й).
Чәшкеләргә китеп вафат булды,
И-и-и, башкынаем калды яшь кенә(й).

Ишегем алды келилсә лә(й)
(рус. крыльцо – Ф.Ю.),
Җиз самауыр кайнай җил белән,
Ә-ә-й, җиз самауыр кайнай җил белән.
Самауырлар кайнап, чәйләр пешкәч,
Инде эчәем аны ла(й) кем белән,
Ә-ә-й, инде эчәем аны ла(й) кем белән?

Ишеккәйнең алды(й) келәсәләй(й),
Кер(е)сәм генә(й), чыксам да (й) таянам.
Ә-ә-й, кер(е)сәм генә(й), чыксам да(й) таянам.
Төш(е)ләремдә(й) күрсәм дә шатланамын,
Инде үбәем дисәм, уянам,
Ә-й-й-й, инде үбәем дисәм, уянам.

Йәнекәем китте сунарга, көзге чәшкегә,
Күл буйлатып, озын юл белән.
Әҗәлләре җиткән булса,
Җан кер(е)теп булмый кул белән,
Ә-ә-й, җан кер(е)теп булмый кул белән.

(Җырны нотага Дания Арсланова салды).

Затлы нәсел

Авыл өе... Аның һәр почмагыннан, һәр бүрәнә ярыгыннан сер саркып тора сыман. Ә шулай да, иң серле почмак чорма башыдыр, мөгаен. Балачакка кайтып килсәк, без анда киптерергә таратылган алма, алма кагы, чикләвек, дару үләннәрен, какларга эленгән каз түшкәләрен күрербез... Чорма башында, хуш ис аңкытып торган тәмлүшкәләрдән тыш, гаиләнең кадерле истәлек-ядкарьләре дә саклана торган иде. Диннең тыелган чорларында дини китапларны да үзләрендә яшереп саклады чорма башлары.

Мин килен булып төшкән йортның чорма башында да тамбур чигүле яулыкка төйнәп куелган китаплар тора иде. Иске өйне сүткәч, ул төенчек яңа өйнең чорма башына күчте. Анда нинди китаплар төрелгән – озак вакытларга кадәр бу сорау белән әлләни кызыксынучы булмады. Әлеге сорау миндә үзем мәдрәсәгә йөри башлап, гарәп хәрефләрен таный башлагач туды. Яулыкны чишеп карасам, хәйраннар калдым: дини китаплар арасында дәреслекләр дә булган икән бит! Берсе – математика дәреслеге, икенчесе – кульъязма, тагын берсе – 1895 елда ук Санкт-Петербург типографиясендә басылган дәреслек. Кызганычка каршы, хәрәкәсез хәрефләрне тануы минем өчен кыен мәсьәлә булып чыкты. Күңелгә уй керде: безгә каян килеп кергән китаплар соң болар? Кайнатам Равил аларны туган нигезләрендә (Галим бабай нигезе) яңа өй салганда бу нигезгә алып килгәнен әйтте.

Инде китапларның иясен ачыклыйсы калды. Авыл музеенда булган, Равия апа Садертдинова язган китаплардан укып, Мөхәммәтфатих мулла (1880 нче елгы) Борһанетдин улы хәзинәсе булмады микән, дигән фаразга килдем.

Халык арасында «Мөхәммәтфатих мулла Владимир Ильич Ленин укыган чорда Казан университетында укыган, Казан шәһәрендә нindидер түгәрәккә йөргән» дигән сүзләр йөрде. Ул Буа районы Кырлангы авылыннан Зәйнәп исемле кызга өйләнә, 7 балалары туа. Кибет урынында бик шәп йортлары, тополь агачлары белән әйләндереп алынган зур бакчалары була (топольнең берсе әле дә исән). Мулла үзе мәдрәсәдә укыта, ислам нигезләре белән бергә рәттән дөньяви дәресләр дә бирә. Шомлы 30 нчы елларда хәзрәтне алып китәләр һәм юкка чыгаралар. (Хәтер китабында аның турында мәгълүмат табылмады.) Хәләл көч белән салынган йортын Буа районының Шөгәле авылына төяп

Мөхәммәтфатих Муллинның (арткы рәттә уртада) Казанда белем эстәгән чоры. XX гасыр башы.

китәләр. Зәйнәп остабикә өчен авыр көннәр башлана. Күршедә бер көн, икенчесендә 2 көн... Болай яшәп булмаганын аңлаган абыстай бар көчен җыеп кечкенә генә йорт ала. Хәзрәттән калган китапларны остабикә зиратка төшереп күмгән була. 1970-80-елларда, авыл тарихы белән кызыксынучы, ул вакыттагы мәктәп директоры Габдрахманов Рәхим Гарипҗан улы аларны табып, кайсын Габделбарый муллага, кайсын авыл карчыкларына тарата. Минем фаразлавымча, Галим бабай нигезенә бу китаплар шул юл белән эләккән.

Ә Мөхәммәтфатих мулланың нәселенә килгәндә, исән калган улларының берсе – Камиле Бөек Ватан сугышында һәлак була. Җиһандары (ул кайнатам белән укыган, кайнатам аны бик башлы иде дип искә ала) 1954 елда армиядә хезмәт иткәндә үлә. Кызлары Халидә Буага китеп эшкә урнаша, соңрак остабикәне дә үз янына ала, икесе дә күптән вафат. Затлы нәсел җебе менә шулай өзелә.

Китапханә каршында эшләүче музеебызда Мөхәммәтфатих Муллинның китаплары, балаларының фотолары саклана.

Гомумән, бу нәсел кешеләре укымышлылыклары белән аерылып торган. Безгә билгеле булганнарның иң беренчесе Җәләлетдин мулла, ул 1900 нчы елларда имамлык иткән. Сукыр булса да, мәчеткә йөргән. Аның йортыннан мәчеткә таба җеп сузалар, ул шуңа тотынып намаз укырга йөри. Җәләлетдин хәзрәтнең бер улы Борһанетдин бик укымышлы булып, дәвалау-өшкерү ысулларын да белгән, авыл халкына зур хезмәт күрсәткән. Мөхәммәтфатих аның олы улы (1880). Тагын Фәтхелислам (1887), Салихҗан (1895) исемле уллары булуы да билгеле.

1930 нчы елларда ачылган мәктәпнең беренче мөдире Салихҗан Муллин була. Алар Кырлангы кызы Фатыйма (1895) белән өч бала үстерәләр. 1919 нчы елгы уллары Рәхимҗан Бөек Ватан сугышында һәлак була, 1926 нчы елда туган Илһамияләре яшьли вафат була. 1937 нче елгы Роза апа медучилище тәмамлап гомере буе авылда фельдшер булып хезмәт итте. Аның эшен кызы Резедә дәвам итә.

Салихҗан ага да гарәп, фарсы, төрек телләрен белгән. Күрәсең, мулла булырга укып та, дөньялар үзгәреп китү сәбәпле, бу максаты тормышка ашмаган. Кызы Роза апа

Муллин Җиһандар.

Муллин Камил.

истәлекләреннән күренгәнчә, Салихҗан ага үз нәселенең шәҗәрәсен дә төзегән. «Безгә билгеле иң борынгы бабабыз Зәйнелгабидин булган», – дип әйткән ул. Тик еллар тузанында шәҗәрә дә, бик күп истәлекләр дә югалган.

Гомумән, тарихыбызга караган бик күп ядкарьләр юкка чыккан. Шуңа күрә, бүгенге көндә үткәннәрдән килеп ирешкән һәр истәлек, һәр фото, шулай ук һәрбер хәбәр тарихыбызны өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора.

Гөлчәчәк ГАЛИМОВА,
Тәтеш районы Келәш авылы китапханәчесе

Мөхәммәт ГАЛЛӘМ

Тугры юл

Көләч йөз

«Фуссиләт» сүрәсе, 34 нче аять:

«Игелек белән яманлык бер булмас. Син яманлыкны игелегең белән бас (яманлыкка җавап итеп, игелек кыл. Ул таш белән атса, син аш белән ат). Шулай гамәл кылганда, икегезнең арагыздагы дошманлык бетәр, сез дуслашырсыз».

Кадерле мөселманнар!

Кешеләр бер-берләре белән дуслык мөнәсәбәтләрендә һәм үзара аралашканда көләч йөзләләрне эзләрләр. Кешенең елмайган йөзе нәтиҗәдә сөю һәм мәхәббәткә ирештерә, каршысындагы кешенең күңеленә тынычлык һәм самимият җылысын бирә.

Җиһанның җитәкчесе, кешелек дөньясының баш таҗы Пәйгамбәр әфәндебез даими рәвештә көләч йөзле була. Тирә-ягындагыларга һичбер заман караңгы чырай күрсәтми. Шулкадәр ки, турсаеп торганнарның каршысында да елмайган йөзле мөнәсәбәттә була. Аралашкан кешеләренең кяфер яисә монафикъ булганын белүенә карамастан, аларга даһи (өстен) көләч йөзен киметми, пәйгамбәрлек вазыйфасын башкарып, кешелеклелек таләпләрен җиренә җиткереп үти.

Гүзәл һәм көләч йөзле Пәйгамбәребез өммәтенә нәсыйхәтләрендә: «Изгелекне гүзәл йөзлеләр яныннан эзләгез», – дип боерган.

Ислам галимнәребез әйткәнчә: «Яхшылык йөзләре көләч, күңелләре белән елмаеп торган кешеләрнең янындадыр. Чөнки йөзнең чырае эчтәге халәтнең көзгеседер».

Көләч йөзле кешеләр, кешеләрнең хезмәт уңышларын күргәндә, тагы да көләч йөз күрсәтерләр. Инде кешеләрнең теләкләрен үти алмаган вакытта да, янә көләч йөз белән ачыклап әйтеп, кире кагарлар. Димәк, көләч йөзле кешеләр, яхшылык эшләсә дә, эшләмәсә дә каршысындагы кешеләрне канәгать иткән булырлар. Моның өчен Пәйгамбәребез таләпләребезне көләч йөзле кешеләргә ачарга үгет иткән.

Иртән намазга торганда елмайган йөзле булуыбызны әмер иткән. Төшенке чырай белән, күңелсез бер кыяфәт белән Хозуруллаһка юнәлү күркәм түгелдер.

Шул шәкелдә, газиз мөэминнәр, йөзебез даими көләч булсын.

Дин кардәшләребезгә малларыбыз белән, байлыкларыбыз белән ярдәм итү форсаты булмаганда да аларга көләч йөз белән файдалы булыйк. Динебездә көләч йөз үн садака булып кабул ителгәнен һичбер заман хәтеребездән чыгармыйк.

Җыелышларда бездән һәр кеше көләч йөз көтә: балалар – өлкәннәрдән, олылар – кечеләрдән. Һәммәсе көләч йөз күрергә телиләр. Мосафир белән өй хуҗасының йөзендә елмаю күренмәсә, алар шунда ук аерылыр. Көләч йөзләр иң авыр хәлдәге кешеләрне дә куандырыр, сөендерер.

Садака бирүнең иң яхшы һәм иң җиңел юлы булган көләч йөзебезне һичкемнән яшермик, кызганмыйк. Елмайган йөзле Рәсүлебезнең үгет-нәсыйхәтләренә колак салыйк.

Исламда кеше хакы

Кеше – җанлылар дөньясының иң гүзәл һәм иң мөкәммәл үрнәгедер. Андагы үзенчәлекләр һичбер җан иясе белән чагыштырылмаслык кадәр үзгәрүчән, күзләренең нурын алырлык хәлдә балкышлыдыр.

Кеше 900 мең төрле җанлылар эчендә гаҗәеп көнкүреш җайланмаларын эшләүче, галәмнең серләрен өйрәнүче бердәнбер заттыр. Кеше дә, башка җан ияләре кебек, туар, үсәр һәм үләр. Әмма ул туплам-туплам, җәмгыять булып яшәр. Гомер кичергәндә табигать кануннарына, бәхетле булыр өчен – дин һәм җәмгыять кагыйдәләренә буйсыну тәкъдирендә булыр.

Кеше – саны буенча йөз меңнәрчә булган мәхлукларның бер төре түгел. Ул яратылганнарның иң өстене, галәмнең кардәшедер. Әмма ул өстенлеккә лаек булган кадәр, түбәнчелекләргә дә төшәр. Хак Тәгалә, кешене кыяфәтләндергәннән соң, аңа

яхшылыклар һәм начарлыклар кабилиятен дә биргән. «Шәмс» сүрәсенең 7-8 аяте шуны раслый.

Ислам кешегә тугры һәм мәрхәмәтле күз белән карый. Аны, үзенә генә хас җан иясе буларак күрү белән бәрабәр, башка күп төрле сәләтләре булуы сәбәпле, кешегә аерым бер урын һәм кыйммәт биргән. Аның шәрәфле һәм өстен сәләтләре белән бергә зәгыйфьлекләре, кимчелекләре урын алган, һәм боларның бөтенесе дә табигый күренеш дип бәяләнгән.

Инсан никадәр зәгыйфь, никадәр кимчелекле булса булсын – кешелектән чыкмас; никадәр көчле, никадәр мәгърур булса булсын – гомум кешелектән өстен була алмас. Кыскасы, өстенлекләре, кимчелекләре, фазыйләтләре белән кеше – кешедер. Аллаһуның динен безгә китергән бөтен пәйгамбәрләр: «Без дә сезнең кебек бер кешебез», – дигәннәр.

Олуг Пәйгамбәребез хәзрәте Мөхәммәд (с.г.в.) Аллаһуның әмере белән кабат-кабат: «Мин дә сезнең кебек бер кеше», – дип тәкърарлый.

Коръән Кәримнең «Ихлас» сүрәсендә Аллаһуның кеше кыяфәтендә булмаганы кискенлек белән белдерелә, моның кебек ялгыш һәм акылга сыймастай фикер йөртүче кешеләргә каршы көрәш ачыла.

Кеше – шәрәфле бер барлык. Аны башка җанлылардан аерып торган иң мөһим үзенчәлек – акыл һәм мантыйк иясе булуындадыр.

Кеше – хатын-кызмы, ир кешеме, сәламәтме-чирлеме, хәтта мөэминме-кяферме, барыбер – кеше булганы өчен кыйммәтле бер барлыктыр. Шул сәбәптән көнкүрешебездә һәрнәрсә аның ниятенә буйсынган. Кешегә акылын, көчен кулланып, Аллаһуның нигъмәтләреннән файдалану әмер ителгән.

Җәнаби Хак боерды ки:

«Хактыр ки, Без адәм балаларын дан вә шәрәфләргә күмдек. Аларны коры җирдә дә, диңгез-суда да йөрттек. Үзләренә тәмлетатлы ризыклар бирдек. Янә дә аларны яралтканнарыбызның күбесеннән өстен кылдык» («Исра» сүрәсе, 70 нче аять).

Ислам – инсан өчен, кеше бәхете өчен җибәрелгән бер дин. Аның асыл максаты да кеше тормышының шәрәфен саклау һәм кешенең үзенә лаек булган кадер-хөрмәтен белдерүдер.

Белегез ки, кеше гади генә бер барлык түгел. Аллаһ аңа шәрәфне биргән дә олуг әманәтләр яки өстенлеге өчен җаваплылыкны да йөкләгән. Җәнаби Хак Коръән Кәримдә шулай боера: «Күкләргә, Җиргә вә тауларга Без әманәт тәкъдим иттек, ләкин алар (җаваплылыктан куркып) бу йөкне үз өсләренә алмады. Адәм баласы бу әманәтне үз өстенә алды. Чөнки кеше – (табигате белән) залим һәм надандыр» («Әхзаб» сүрәсе, 72 нче аять).

«Кеше үзен һич чикләүләрсез, күзәтүчесез яшәргә хаклы, дип саныймы әллә?» («Кыямәт» сүрәсе, 36 нчы аять).

Бу әманәт – Аллаһуны белү, Аның әмеренә оею, кешеләргә кешечә мөнәсәбәт итүдер. Кеше бу җаваплылыкны төшенеп һәм җиренә җиткереп үтәү аркасында шөһрәт вә шәрәф казаныр.

Уку һәм укытуның да асыл максаты кешенең җаваплылыгын һәм тиешле вазыйфаларын үтәүгә юнәлтелгән. Һәр кеше – яралтучысы булган Аллаһу, үз-үзе, гаиләсе, ватан һәм милләте, бөтен инсаният дөньясы каршында җаваплы һәм бурычлы! Һәр кеше Аллаһу тарафыннан үзенә бер нигъмәт буларак бирелгән тәнен һәм рухын һәртөрле куркынычлардан, җайсызлыклардан сакларга тиеш. Бигрәк тә үзенең пөхтә булуына дикъкать итәргә, сәламәтлеген бозучы нәрсәләрдән ераклашырга бурычлы. Гаиләсенә, балаларына дини вә дөньяви тәрбия күрсәтергә тырышырга, кирәккәндә ватанны сакларга, дәүләте каршында булган җаваплылыкны онытмаска тиеш!

Кешеләрдә бөеклек һәм өстенлек Аллаһ ризалыгы өчен тырышып, башкалар өчен хәерле бер эш башкару аша мөмкиндер. Нинди кавемнән, нәсел-нәсәбтән булуы, тән төсе, бай йә фәкыйрь булуы кешеләргә өстенлек бирми яисә түбәнлек сәбәбен тәшкил итми. Мөкатдәс динебез Ислам гомер кичерешебездә төрле кавемнәр, катламнар һәм төркемнәр булуыбыз нигезендә үзара каршылык күрсәтүне дә кабул итмәгән, хупламаган, һичбер төркемнең башкалардан өстенлеген танымаган.

Чыганак: Мөхәммәт Галләм. Тугры юл: вәгазь-нәсыйхәт вә хөтбәләр. – Уфа: 2010. – 20-21; 74-77 битләр.

«Май уны»

Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре!
Журналыгызда килгән язмаларны игътибар белән укып барам. Мине бигрәк тә башка җирлекләрдәге кардәшләребезнең йолалары, бәйрәмнәре кызыксындыра. Шуларны укыганда «Кара әле, бездә болайрак бит бу», дип, үзебезнең гадәт-йолалар белән чагыштырам. Узган елның дүртенче санында басылган «Борынгылык эзләре җуелмасын» дигән язмада Чүпрәле ягында үтүче «Майның унбише» («Май бәйрәме», «Каталау көне», «Май үләме бәйрәме», «Агач кочакларга бара торган көн» дип тә атыйлар икән) йоласы белән танышкач, «ә нишләп «Майның унбише», бездә бит ул «Май уны», дип гаҗәпләнеп куйдым.
Әйе, бездә, Тәтеш районының Келәш авылында иске стиль белән майның унында май үләннәре җыю гадәте бар. Шул көнне җыйган үләннәрнең шифалы көче бар дип санала. Чыннан да, күкрәк балалары авырып китсә дә, шул үләннәр суында коендырсаң, тизрәк савыга. Мал-туар авырып китсә дә май үләне ярдәм итә. Әлеге йола кайчаннан бирле киләдер, анысы билгесез, тик без белә башлаганнан бирле әнкәйләр ел да май уны үләне җыймыйча калмыйлар иде. Ул гадәтне Мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Хатирә» фольклор төркеме белән бүгенге көннәргә хәтле яшәтеп килдек әле. Элеккеге кебек зурлап булмаса да, төркемебез белән алма бакчасына төшеп, үләннәр җыеп, чирәмдә тәгәрәп, чәйләр эчеп, «Зәлидә» уйнап кайта идек. Гармунчыбыз Галия апа гармунын сыздырып җибәргәч, апалар тыпырдап биеп китәләр, яраткан җырларын сузалар иде (шунысы кызык, бу олы яшьтәге апаларның һәрберсенең үз җыры бар). Кызганыч, 25 ел сәхнә түре тоткан апалар инде олыгайдылар. Күбесе май унында бакчаларыннан карлыган яфраклары гына җыеп керәләр. Киләчәк буынга бу гадәтне өйрәтеп калдыру максатыннан, йоланың сәхнә вариантын әзерләдем, шуны сезгә дә тәкъдим итәсем килә.

Авыл иртәсе. Мал-туар тавышлары, әтәч кычкыруы ишетелә. Алгы планда ике хатын ашыгып көтү куып кайтып килә.

Наилә. Җиләгем, Май унына барасыңмы бүген?

Миләүшә. Ел да барганны, ничек быел гына калыйм ди, җиләгем. Сөтлебикәмне дә шул май үләннәре генә коткарып калды бит. Шилә Зәйнәп аптыйдан үлән сорап җөреп булмас, үзем җыям, Алла бирсә.

Наилә. Мин дә бит кечкенә улым авырганда шуның шифасын таптым. Ярый, ашыга төшик, кош-кортны урнаштырыйк та, кузгалырбыз. (*Китәләр.*)

Сәхнә табигать күренешләре белән бизәлгән, кошлар сайрый. Хатыннар болынга киләләр, араларында әбиләр, балалар да бар.

Әби. Ягез, балалар, әйберләрне урнаштырыйк. Розалия, кызым, син самавырны куеп җибәр, без үләннәр җыйганчы кайный торсын.

Розалия. Була ул, Бибинур аптый. (*Җырлый.*)

Самавырны тиз кайната
Кызыл миләш күмере,
Бибинур аптыебызның
Озын булсын гомере.

Әби. Балалар, әүвәл үләннәр җыеп алыйк, аныңчы самавыр да кайнап чыгар. Алдан ук аңгартып куям: үлән җыйганда сүләшмибез, шуны онытмагыз.

Миләүшә. Сүләшмәгәч тә ни кызыгы бар, мин сүләшмичә түзә алмыймдыр.

Әби. Кызыгы соңынтын булыр, тәртибе шулай. Әгүзе бисмилләне әйтеп, эчтән генә Ал-

лаһы Тәгаләдән саулык сорап җыйганнар элгәреләр. Без дә шулай итәрбез.

Берәү үләнне таптап чабып уза, икенчесе туктата.

Резедә. Тукта инде, Миләүшә, бөтен үләнне таптама.

Дания (*кыек-мыек атлап*).

Кыек-мыек атламыш,
Зачем печән таптамыш,
Келәшеский алам бит,
Җаңагыңа салам бит! (Бергә көлешәләр.)

Әби. Җаңакка салып торыш булмас инде, әмма саграк атласагыз, анысы мишәйт итмәс.

Сүзсез генә җыялар, әкрен генә дога тавышы куярга була.

Илсөяр. Кызлар, булды бу!

Алия. Тукта, аптый дәшми бит әле бер дә, аны узып сүләмә әле син.

Әби. Җитәрлек җыйдыгызмы, кызыкайлар?

Гөлшат. Җитте кебек, Бибинур аптый.

Зифа. Әллә быел үләндә тәгәрәмибезме? Ел буе шуны көттем. Авырый башлаган саен, их, мин әйтәм, җаңгыр җаугач үләндә тәгәрәмәгән идем, башым авырудан чыкканы юк. «Исән булсам, катлый-катлый тәгәрим быел!» дип хыялландым.

Гөлчәчәк. Соң, тот та тәгәрә, кем мишәйтли сиңа?!

Гөлшат. И, сабырсыз инде син, Зифа, аптый әйткәнне дә көтмисең, чаптыртасың гына.

Зифа. Чаптыртмый ни, түземлегем чамалы гына шул.

Әби *(көлә)*. Зифа ул әнкәсе карынында да тугыз ай түзеп тора алмады, җиде айдан туды. Үзем кендек әбисе булдым.

Рузинә. Әле җиде аен ничек түзеп яткан! (*Көләләр.*)

Әби. Әйдә, шул хәтле түземсез булгач, Зифа, син тәгәри башла.

Чирәмдә тәгәрәшләр.
Бисмилләһи рахмәниррахим!
Чирем-чорым коелсын!
Саулык бирсен, байлык бирсен,
Дөньялар тыныч булсын!

Розалия. Кызлар, самавыр кайнады, килегез!

Римма. Чәй дигәндә, безнең аяк идәндә! *(Көләләр.)*

Миләүшә. Идән юк бит әле монда, хәер, чирәм булганда идән ниемә кирәк.

Алия. Бибинур аптый, кил монда, иплерәк урынга утыр.

Утырышалар, чәй ясыйлар.

Рузинә. Печән дигәннән, бер кызык хәл сөйләп алыйм әле сезгә. Элгәре печән, саламга кытлык иде бит. Бригатка эшкә җөрүче хатыннар, бераз булса да файдасы булыр дип, кешекара күрмәгәндә берәр бәйләм күтәреп кайталар иде. Асыл апа да шулай итәргә уйлаган. Элгәре халык простуй булган бит, аны ирләр кызык итәргә уйлый. «Асыл, менә шушы тимерне ирең әллә кайчаннан бирле эзли, килеп чыкты бит шул. Ибраһим абый күрмәгәндә алып кайтып китәсеңме шуны?» – дип, печән арасына җен кебек авыр тимер тыгып җибәрәләр. Авыр булса да түзә апабыз, шту син, ире кайчаннан бирле эзләгән бит. Ахылдап кайтып керә. Ире дә кайткан икән калхуз эшеннән. Чакырып чыгара, ә ул бернигә яраксыз тимер кисәге булып чыга! (*Көлешәләр*).

Әби. Кызлар, үләннәрегезне хәсиятләп киптерегез, кирәге чыгар.

Дания. Кая киптерергә булыр икән соң бу затлы таварны?

Рәсимә. Чормада инде, тагын кая куясың аны.

Гөлшат. Әллә чормаңда урын беткәнме? Җиләктән какларны күп ясадың шул син.

Дания. Ясадым шул, әлхәмдүлилләһи шөкер! Көнгә ике тапкыр да бардым җиләккә. Фәрхе-

зада аптыйны да дәшкән идем, «гады прошла» гына диде. Ул җиләк остасы ие бит элгәре.

Румия. Мин дә бер кызык сөйләп алыйм әле. Әллә иренелгән ул елны, әллә әзрәк җыелган, әллә елак кызымны коендырганда тотып бетерелгән Май уны үләнен. Сыерым авырып китте бит, берни булышмый. Алай да итеп карыйбыз, болай да. Киттем Мәрфуга аптыйга. Мәйтәм шулай, шулай. «Хәзер!» диде дә, шул арада май үләне күтәреп тә керде. «Башка берни бирмә сыерыңа, түлке шуны ашат», – ди. Алланың рәхмәте белән, рәтләнеп китте бит малкай. И, шатланганнарым! Битонга сөт салдым да, киттем Мәрфуга аптыйга. «Нихәл, рәтләндеме?» – ди. «Рәхмәт, аптый, коткардың», – дим. Кетер-кетер көлә. Берничә ел үткәч, Мәрфуга аптый, урыны җәннәттә булсын, серне чиште бит! «Үзем белән алып китә алмыйм, рәнҗемә», – ди. Мин бик аптырап килгәнне күргәч, сушиләсеннән йомшак печән алып кереп биргән икән миңа. *(Көләләр.)* «И, аптый, нинди рәнҗү, сыерымны терелттең бит!» – минәйтәм.

Илсөяр. Аның гомер буе кулы җиңел булды бит.

Гөлчәчәк. Әле дә шундый кешеләребез бар, Аллага шөкер.

Гөлсинур. Җилле кешеләрнең кулы да җиңел була бит ул. Без кечкенә чакта әнкәй җиләккә аңа ияртеп җибәрә иде. Барганда чак өлгерәбез артыннан, кай арада битонын тутыра да, элдертә генә авылга. Иярсәң ияреп кайтасың, калсаң каласың гына урманда. Гөнаһысына кереп булмый: үзе кузгалганда урманны яңгыратып хәбәр бирә иде, «кайтабыз», дип.

Миләүшә. Равия апаның да кулы да, сулышы да шифалы иде бит, сыпырып кына төшерә иде авыруыңны, әле менә шулай итеп таптап та куя иде.

Миләүшә *(сикереп тора).* Әйдә булды, сөйләп тә, ашап та туймассыз сез, шушы матур тугайда бер биеп тә аласы иде.

Әби. Ашка дога кылып алыйк әүвәл. *(Дога кылалар.)*

Илсөяр. Биибез дидең дә, гармунчы булмагач ни тулкы?

Гөлшат. Нишләп булмасын, самавыр торбасы ниемә ул, бер көй дә чыгармагач?

Самавыр торбасында көй чыгарып бииләр.

Бие, бие , бие әле,
Биегәнең юк әле,
Сине матур бии диләр,
Биетеп карыйк әле.
Бие, бие, бие әле,
Биючегә – бер бәрән!
Бии белмәгән кешегә
Чабатасы да әрәм!

Наилә. Кызлар, бер «Зәлидә» дә әйләник инде!

«Зәлидә» әйләнәләр.

Зәлидә яңгырасын,
Нурлы йөзләрең саргайган,
Кем өчен кайгырасың?
Әлләләлем, Зәлидә,
Гөлләләлем, Зәлидә,
Чияле тау итәге,
Чияле тау итәгендә
Бергә булдык бит әле.
Сары матур, сары матур –
Сары матур сайласаң,
Әллә кайлардан танырмын
Кошлар булып сайрасаң.

Алия. Ә хәзер алтылыйбыз!

Өчәр-өчәр булып кара-каршы басалар. Бию көе башлангач, уртадагы кешеләр уртага чыгып «көлтә җыялар», аннан иң кырыйдагы кешеләрне алалар. Аларны әйләндереп, аннары янә үзләре әйләнәләр, аннан башка кырыйдагы кешеләр белән «көлтә җыялар».

Бала арбасы тартып кечкенә бала килә.

Иркә. Әни, әби сине «Дөньясын онытты, өметсез!» диде дә, бәбине сиңа илтергә кушты.

Гөлшат. И, йолдызым, ничек тартып килдең, ардыңмы?

Иркә. Бер дә армадым, бәби дә өйдә җылады-җылады да, кырга чыккач шып туктады.

Әби. Сәхрә килешкән инде аңа, балалар. Барыбызга да сәхрәдә булуның файдасы тисен, җыйган үләннәрнең шифасын табыгыз. Исән-сау булып киләсе җылларда да Май унына чыгарга язсын. Әйдәгез, булмаса, кузгалыйк өйләргә.

Алай да бергә-бергә,
Болай да бергә-бергә,
Безнең болай утырулар
Калсын бөтен гомергә.
Җыен гөлләр арасыннан
Яратам мин кынаны,
Яратмас идем кынаны,
Сезгә охшатам мин аны.

Гөлчәчәк ГАЛИМОВА,
Тәтеш районы Келәш авылы китапханәчесе

Вәли байның аждаһа айгыры

Егерменче гасырның башында була бу хәл. Безнең Яңа Актау (Белогор) авылында бер көн хәбәр тарала: Вәли бай Бозаулык базарыннан бер айгыр алып кайткан ди. Атның буе биек, тиресе, озын ялы да, койрыгы да кап-кара, тик маңгаенда бәләкәй генә йолдыз кебек агы бар ди, атның күзләреннән аждаһаныкы кебек ут чыгып тора ди. Ике кучер егет аны көчкә абзарга керткәннәр, ат аларны шул арада тешләргә дә, тибәргә дә өлгергән, имеш.

Вәли бай затлы чанага җиккән айгырда «вышт» итеп кенә урамнан үтеп барганда, балачага гына түгел, олылары да куркып, йортларына кереп качып, читтән аша гына артыннан карап калалар. Озакламый атка «Аждаһа айгыры» дигән исем дә кушыла.

Бер ун көн үткәч, Вәли бай, кара айгырны җигеп, яшь хатынын утыртып, кучер егет белән Түбән Буйга каенишләренә кунакка китә («Түбән буй» дип бездә Бозаулык елгасы буенда урнашкан мишәр авылларын әйтәләр иде).

Каенише кунакларны каршыларга чыга, тик атка сокланып, апасы белән җизнәсе артыннан өйгә керергә бер дә ашыкмый.

Кучер егет абзардан сыер савып чыгып килгән асрау кызны күреп дөньясын онытып торган чакта, кара айгыр аның кулын тешләп тә ала. Хуҗаның көлеп: «Йә, ат шәпме?» – дип соравына, егет, канлы кулын кысып тотып: «Атмени бу, бу бит – аждаһа!» – дип җавап бирә. Хуҗа аңа текәлеп карап тора да, асрау кызны чакырып, егетнең кулын чүпрәк белән бәйләргә куша. Үзе шул арада егеткә әкрен генә: «Миңа булышсаң, бу кыз синеке була», – дип пышылдый һәм өенә кереп китә.

Өйдә кунакларны яхшы гына сыйлагач, хуҗа Вәли байга эндәшә: «Җизни, сат миңа бу айгырны, икеләтә хакын түлим», – ди. Ләкин, ни хәтле ялынса да, Вәли бай риза булмый. Шуннан хуҗа ачуланып: «Сатмасаң, атыңны урлыйм!» – ди. Вәли бай көлеп: «Ничек урлыйсың? Минем ат абзарына чебен дә очып керә алмый!» – дип җаваплый. Йортындагы зур-зур этләрен дә, мал караучы хезмәтчеләрен дә күздә тотып әйтә, билгеле.

Шуннан каенише аңа: «Әйдә бәхәсләшәбез: ун көн эчендә мин ул атыңны урлый алсам, син миңа берни дә эшләмисең!» – ди. Вәли бай кулын сузып: «Ярый каениш, тик урлый алмасаң, теге кашка бияңне миңа бирәсең», – ди.

Икенче көнне кунактан кайткач, Вәли бай хезмәтчеләренә капкаларны бикле тотарга, төнлә абзарларны карап йөрергә, этләрне бәйдән ычкындырырга куша. Менә өч көн үтә, Вәли байның йортына якын килүче чит кеше күренми. Дүртенче көнне авылга кунакка ике егет килеп төшә. Тик алар кызлар сайларга килгән булып чыга: көндезен тыкрык янында чишмәгә суга барган кызларны күзәтеп торалар, берсе гармунда уйный белгәнгә, кичләрен аулак өйдә авыл яшьләре белән күңел ачалар.

Ә Вәли бай бер атна инде үзе дә йокламый, өйдәгеләрне дә йоклатмый, аждаһа айгырны саклата...

Менә тугызынчы көн дә узып бара, абзарда бикләнеп торган атка якын килүче күренми. Әптән арып талган Вәли бай, кичен йортын әйләнеп керә дә, түшәккә ятып, каты йокыга тала. Аңа карап, өйдәгеләрнең барысы да, шул исәптән, арыган хезмәтчеләр дә йокыга китә. Ул төнне йорттагы усал зур этләр дә бер генә дә өрмиләр. Ә нигә алар өрсен ди? Койма аша аларга шактый гына ит ыргыттылар бит, таңга хәтле ашарга җитәрлек...

Иртән Вәли карт уянып чыкса, мал караучылар да йоклый, тамаклары туйган этләр дә йокы симертә. Йортта бар да тыныч, тик абзарда кара айгыр гына юк...

Караклар капка ачып тормаганнар, абзарның тышкы стенасын сүткәннәр дә, атны алып чыгып киткәннәр. Котырынган карттан йорттан качып өлгерә алмаганнарның барысына да эләгә – кешеләргә дә, этләргә дә...

Ә өйләдән соң, кара айгырны җигеп, авызын ерып, каенише дә килеп төшә. Вәли карт никадәр генә тузынмасын, берни эшли алмый – бәхәс бит!

Авыл халкы сөенепме-сөенә инде – байны кем яратсын...

Ат урлаган ике егет шул бер ай арасында авылның ике кызын Түбән Буйга кияүгә алып китәләр, аларга булышкан кучер егет исә күзе төшкән асрау кызны үзенә алып кайта.

Ә ел ярымнан соң каенише Вәли байга кашка бия белән «аждаһа айгыр»дан туган тайчык китерә. Шуннан инде картның ачуы бетеп тә китә.

Тик Вәли картка ул тайчыкның үскәнен күрергә насыйп булмый: бай кинәт кенә вафат була. Ә тай үсеп җитеп ат булгач, Вәли байның кече улы аңа атланып Беренче бөтендөнья сугышына китә...

Сәгъдия БАТТАЛОВА,
Оренбург өлкәсенең Сорочинск шәһәре

«Ябалак»та кунакта

Ак куян йомшак куян, безгә кунакка килгән
Койрыгы кыска аның, колагы җиргә тигән...

Без кунакка килгәндә Казандагы «Ябалак» татар балалар бакчасына йөрүче малайлар-кызлар шигырь өйрәнү белән мәшгуль иде. Аннан санамышларга күчтеләр:

Баш бармак баш кашый,
Имән бармак имән ташый,
Урта бармак утын яра,
Атсыз бармак ат куа,
Чәнти бармак чәй эчә,
Шуңа үсмәгән дә ул!

* * *

Күпме шатлык, күпме наз,
Борчулар булсын бик аз!
Бик бәхетле гаилә:
әти, әни, бабай,
әби, малай, кыз да бирердә.
Яшик гел бергә-бергә
Булып тату бер гаилә
Кушылыгыз сез дә!

Монда рәхәт, һәркем татарча сөйләшә, татарча аралаша, татарча шуклана.

«Бездә балалар көне буе татар тәрбиячеләре белән аралаша. Бәйрәмнәр, туган көннәр һәм башка күңел ачу чараларын да туган телебездә үткәрәбез. Балалары татарча начар сөйләшкән ата-аналар да безгә мөрәҗәгать итә. Аларда да татар теленә тартылу, балаларын татарчага өйрәтү теләк-максаты бар, – ди әлеге татар балалар үзәген оештыручы Азат һәм Эльза Миргаязовлар. – Йоклаганда тәрбияче апалары балаларга татарча әкиятләр укый, уйнаганда татар әкиятләрендәге геройлар белән таныштыра. Бакчабызда тулысынча милли мохит булдырырга

телибез. Балаларга татарча җырлар, уеннар өйрәтәбез, Сөмбелә, Нәүрүз кебек милли бәйрәмнәр оештырабыз.»

Заманга яраклаштырып ачылган балалар бакчаларында чит телләр өйрәтү дә каралган була. «Ябалак»та да инглиз, алман телләрен өйрәнәләр. Шунысы да кызык, чит телләрне дә апалары балаларга татарча аңлата, чит тел сүзләрен татарчага тәрҗемә итеп өйрәнәләр икән.

Без бу бакча белән танышып йөргән арада балалар инде өстәл тирәли тезелеп утырганнар иде. Апалары нидер аңлата әнә:

– Балалар, безнең калфак, түбәтәй, читек кебек төрле милли киемнәребез бар. Алар барысы да чигеп эшләнгән. Киемнәрдәге һәр бизәк табигатьтән алынган. Күрегез әле, кайсында яфрак, кайсында чәчәк сурәте ясалган...

Кул эшләре дәресе бара икән монда. Бергәләп милли киемнәрне бизәргә өйрәнәләр икән. Балалар каршында – кәгазьдән ябыштырып ясалган түбәтәй формасы, кәгазьдән киселгән читек. Башта бергәләп милли киемнәр белән таныштылар, бизәлешен өйрәнделәр, ә аннары үзләре дә апалары биргән кәгазь читек белән түбәтәйне бизәп карадылар, аларга җилем ярдәмендә төрле бизәкләр ябыштырып мәш килделәр. Кемдер түзми, түбәтәйне киеп тә карый. Күңелле!

«Баланың теле гаиләдә ачыла, әти-әни янында формалаша. Бала үсә, тирәлеге торган саен киңәя бара, – диләр бакчаның хуҗалары. – Туган тел күңелгә сеңеп үссен өчен гаиләдәгеләрнең генә түгел, бала танып белгән яңа дөньяның да шул телдә аралашуы мөһим. Бигрәк тә балалар бакчасында! Үзенең яшьтәшләре, тәрбияче апалары белән көне буе татарча гына аралашкан бала өчен әлбәттә инде туган тел беренчел телгә әйләнә.

Балалар бакчасындагы исемнәрне генә күрегез әле сез: Сөләйман, Тимерхан, Зиннур, Әмирхан, Мәдинә, Зөбәрҗәт, Әминә, Зөбәйдә... Бу асыл исемнәрне әйтергә өйрәнеп кенә дә татар теленә гашыйк булырга мөмкин бит!

Татарча сөйләшү дигәннән, үзләре русча аралашкан әти-әниләр дә, татар теленә өйрәтү максатыннан, балаларын бирегә йөртәләр. Татар телен «Ябалак»та гына өйрәнә башлаган нәниләр белән төрле мәзәк хәлләр дә килеп чыга. Бер малайга ашаганнан соң туган телдә «Рәхмәт, тәмле булды!» дип әйтергә өйрәткәннәр әнә. Ул хәзер, табын яныннан киткәндә дә, уенчык бирсәләр дә «Рәхмәт, тәмле булды!» дип җавап кайтара икән. Шик юк, татар телендә «шытырдатып» сөйләшүче яшьтәшләре даирәсендә кайчан нинди әйтемнәр кулланасын бик тиз өйрәнеп алачак бу бала.

...Казанда чын татар балалар бакчалары күп түгел. Әлегә алар бармак белән генә санарлык. Бу бакчаларда эшләүчеләр бөтен көчләрен сабыйларга туган телнең матурлыгын ачып салырга, аларны милли мохиткә төреп үстерергә тырышалар. Татар теленең киләчәгенә куркыныч янаган, мәктәптә татар теле дәресләре кыскартылган бу чорда әлегедәй бакчалар милләтнең йөзек кашына тиң ләбаса! Артсын иде алар, һәм үзләренә торган саен күбрәк сабыйны тартып китерсен иде!

Зөбәрҗәт.



Бармак санашулар

Бер – бермәк,
Ике – икмәк,
Өч – өчаяк,
Дүрт – дүртмәк,
Биш – бишмәт,
Алты – атмак,
Җиде – җитмәк,
Сигез – сикмәк,
Тугыз – тукмак,
Ун – уймак,
Таба тулы коймак,
Мә, сиңа да бер бармак! (Балага бер
бармак тоттыралар.)

* * *

Берәү – беләү,
Икәү – игәү,
Өч – өчаяк,
Дүрт – дурычмак,
Биш – бишек,
Алты – ашык,
Җиде – җидегән,
Сигез – сикерткә,
Тугыз – тумыртка,
Чыгарганнар йомырка.

Хәрәкәтле уеннар

Бүкәнле

Балалар аллы-артлы парлашып түгәрәкләнеп басалар. Бер парсыз кеше түгәрәкнең тышкы ягында кала. Ул бер парның артта торган кешесенә кагыла һәм алар икесе ике якка түгәрәк буенча йөгереп китәләр. Ә парсыз калганы аларның урынында басып кала. Тегеләрнең кайсы тизрәк түгәрәк буенча әйләнеп чыга, ул әлеге басып калучының алдына басып, парлы була. Соңарганы исә парсыз кала. Ул үз чиратында тагын да берәр парга килеп кагыла һәм уен тагын шулай кабатлана.

Хат ташучы

Уйнаучылар, бер иптәшләрен уртада калдырып, кулга-кул тотынып, бер түгәрәк ясыйлар. Уртада калганы «почта» була. Түгәрәктәгеләрнең һәркайсы үзенә Казан, Уфа, Оренбург, Троицк, Стамбул һ. б. кебек берәр шәһәр исемен атый. Шуннан соң уртада торучы «почта»: «Хат алып барам Уфадан Троицкка!» – дип кычкыра. Исемнәре аталган уенчылар шул арада йөгереп урыннарын алыштыралар. Ә «почта» бу вакытта, форсаттан файдаланып, түгәрәктә урын алып калырга тырыша. Урынсыз калган бала «почта» булып, уен яңадан башлана.

Чыганак: Татар халык уеннары.Төзүчесе Рәшит Ягъфәров. – Казан: «Раннур» нәшр., 2002. – 31, 169, 170 битләр.

Раилә САБИРОВА

Юка

Кайбыч ягына килен булып төшкәч ук аңладым: мин — юкалар башкаласында яшим икән! Монда һәр табын, һәр бәйрәм юка белән уза, һәр аш-су остасының тел йотарлык юка рецепты бар. Алай гынамы соң әле, Кайбыч киленнәре юка пешерә белергә тиеш!

Интернеттан бик тырышып эзләсәгез дә, юканың төгәл рецептын тиз генә таба алмассыз. Юканы – таба үлчәмендәге түгәрәк камыр ашын – Татарстанның Тау ягында пешерәләр.

Менә бүген сезгә дә безнең якта юканы ничек пешерүләре турында сөйлисем килә. Минем алъяпкычлы ярдәмчеләрем – Кайбыч районы Кошман авылының аш-су осталары, бер пешергәндә 130 ар юка (!) пешерү тәҗрибәсе булган Лира апа Шәйхетдинова һәм Флера апа Мотыйгуллина.

Киленнәрнең юка пешерә белүе – безнең якның элек-электән килгән бер матур йоласы ул. Димәк, юка пешкән ис безнең өйдә дә чыгарга тиеш! Барып өйрәнергә дә ерак түгел, камыр осталары күрше Кошман авылында гына яши. Тик менә, юка турында сүз чыккач, өйдә тавышлар икегә бүленде: берәүләргә юканың мичтә, күмер өстендә пешкәне ошый икән, икенчеләре духовкада пешкәне дә ярый, ди. Нишләргә?! Хәер, безнең өйдә мондый сораулар тиз чишелә: икесен дә өйрәнергә! Өебездә духовка да эшли, морҗалы мич тә бар. Димәк, осталарның үзләрен өйгә чакырабыз да юканы бергәләп пешерәбез!

Авылда камыр ашлары әзерләгән Лира апа белән Флера апага күпләр мөрәҗәгать итә, алардан ярдәм сорый. Юка пешерергә өйрәнергә телибез, дигән теләгебезне дә бик рәхәтләнеп кабул итеп, өебезгә алъяпкычлы, ак яулыклы кояш булып килеп керделәр.

– Җиде классны тәмамлагач сыер савучы булып эшләдем. Бик яшьли, 19 яшемдә кияүгә чыктым. Килен булып килгәндә аш-суга бик оста идем, дип әйтә алмыйм. Барысына да кайнанам өйрәтте. Шулай бервакыт, үз әнием безгә кунакка килгәч, кайнанама әйтә куйды: «Кодагый, Лираның кулы әллә ни эш белми, яши-яши өйрәнер инде», – ди. Кайнанам: «Ярар, кодагый, өйрәтергә би-и-ик яратам мин», – дигәч, озак көлешкәннәр иде. Чыннан да шулай булды, кайнанам өйрәтергә, мин өйрәнергә яраттым. Әнкәйне (кайнанамны) дә бик яраттым. Яшь чагында алар берәр кая кунакка китсәләр, тизрәк кайтсыннар иде дип елый идем. Кайнанам 90 яшькә кадәр яшәде, 90 яшенә кадәр мине өйрәтте. Ул дөньядан киткәч, әнкәй өйрәтеп тормагач, бер эшне дә эшли алмам сыман тоелган иде хәтта. Тормышта яңа нәрсәгә өйрәнүдән оялмаска, өйрәтәләр дип кимсенмәскә кирәк, – дип сөйли-сөйли, юка өчен кирәкле әйберләрне барларга кереште Лира апа.

– Он, чүпрә, май кирәк. Камырга йомырканы юып сытмасаң, гөнаһ була, күкәйне юып бирегез. Сөтне җылытыйк, балалар, тик кайнарланып китмәсен. Онны камыр басар алдыннан иләп алсаң, камыр «һавалырак» була, диләр. Барысын бергә куштык, хәзер арка тирләгәнче камыр басабыз. Камырны озаграк баскан саен тәмлерәк була, дия торган иде әнкәй. Аннан камырны җылырак урынга куеп, «күзе ачылганчы» кабартабыз. Духовкада пешерсәк тә, мичтәгесенә дә бер үк камыр ясыйбыз.

Шулай, киңәшләрен бирә-бирә, Флера апа белән Лира апа камырны басып та куйдылар. Хәзер инде, «камыр күзен ачкан» арада, чәй эчеп алырга да була!

Чынаякта бөтнекле чәй, өстәлдә тәм-том. Сүзебез һаман юка тирәсендә бөтерелә.

– Кошманда бөтен кеше дә юка пешерә беләме? – дип сорыйм чәй өстәле артындагы апалардан.

– Кемнең күңелендә бар, шул пешерә, – ди Флера апа. – Юка – туй, кунак мәҗлесләрендә дә, Корьән ашларында да хөрмәтле сый. Аннан башка бернинди аш та узмый. Туй буласы йортка, яшьләрнең тормышлары бәрәкәтле, түгәрәк булсын, сабыйлар ризыктан аерылмасын, әти-әни тигезлегендә үссен, дип, кияү белән кәләш өчен пар юка пешереп баралар. Өйдә дә бик еш пешерәбез. Менә безнең өйдә атнага өч тапкыр юка пешә. Камыр ризыкларын бик яратабыз. Киленем дә бик оста минем.

Кай яктан гына сүз башласак та, кайнана-килен темасына киләбез дә чыгабыз!

– Кайнана белән 12 ел яшәдем, үзем кайнана булып 20 елдан артык торам инде, – дип сүзен дәвам итә Флера апа.

– Кайсы рәхәтрәк соң, килен булумы, әллә кайнанамы?! – дип көлешә өстәл янындагылар.

– Берсен дә кыерсытасы да, кыерсытыласы да килми. Үзеңә карата да, башкаларга карата да гел гадел буласы килә, – ди Флера апа. – Килен булгач, тыныч кына йөрисең инде ул, кушканны эшләп. Кеше кыерсытулардан Аллаһ Үзе сакласын.

Шулай... Менә мин дә йөрим йөгереп, башкалар кушканны эшләп. (Килен булгач, нишлисең?!) Әле чәйләр яңартам, кабарып җитмәгәнме дип камырга күз-колак булам, табаларны барлыйм. Юка пешерергә тотынсаң, сөт, йомырка гына җитми, табагачы, дөгәче дә кирәк бит әле!

Ул арада мич ягып җибәрдек. Юкалы табаны мичкә куйганчы, күмере төшә торсын. Шуны да белеп торырга кирәк — юканы каен утынында пешермиләр. Каен утыны янганда «ата», юка өстенә күмер төшә. Иң әйбәте — юкә утыны, диләр.

Камырга әле тагын бераз кабарып күтәрелергә кирәк. Димәк, икенче чынаяк чәйгә дә вакыт бар дигән сүз. Чәй – чәйгә, сүз яшьлеккә бәйләнә...

Лира апа да, Флера апа да яшьлекләрен, бар көчләрен туган җиргә, колхозга багышлаган ханымнар.

Флера апа яшьлек мәхәббәтен армиядән көтеп ала, аңа кияүгә чыга. Күпмедер вакыт яшәгәч, каты авыру кайнанасын аяктан ега. Ун еллап иренең әнисен тәрбияли ул. Аннан ире дә авырып китә, хаста сеңлесе дә аның кулында... Ул көннәрнең авырлыгын әле бүген дә күз яшьләре аша искә төшерә ул.

Тик бирешергә ярыймы соң!

Вакыт – дәва. Әнә, хәзер ул ике баласына кадерле әни, оныкларына тәмле ашлар пешерүче дәү әни. Алай гына да түгел, картлар йортыннан үз өенә алып кайтып, дистә елдан артык бер ялгыз әбине дә тәрбияли әле ул.

Лира апа бик яшьли зур гаиләгә килен булып төшә. Кайнана белән 30 ел бик рәхәт яшәдем, ди. Унтугыз ел бергә яшәгән ире вафатыннан соң да иң зур таянычы булып кайнанасы кала аның. Өч баланы аякка бастырырга да, башка туганнар белән дус-тату яшәргә дә булыша ул. Тормыш китабының кайсы битендә ни язылганын Күкләр генә белә торгандыр. Кешенең бар бурычы – булганны кабул итеп, шөкер итеп яшәү бит. Лира апа тормышында да шулай – моннан берничә ел элек ул каенсеңлесенең тол калган иренә кияүгә чыга. Ике гаиләне бергә кушкач – алты бала, кияү,

оныклар... «Барыбыз бергә җыелгач, 60 якмыш (безнең якта кыстыбыйны шулай атыйлар – Р. Х.) пешерәм, 4 литр сөттән (1 литр сөттән 13-14 юка чыга – Р. Х.) юка ясыйм», – ди.

Камыр «күзләрен ачкан», өскә кадәр кабарып менгән! Әзер! Эшне башладык.

Алда язып узганча, без юка пешерүнең ике төрле вариантын да сынап карарга булдык. Флера апа юканы духовкада пешерә, Лира апа – мичтә, күмер өстендә. Кайсы тәмлерәк булыр икән?!

Беренче эш итеп камырны бүлеп, кечкенә түгәрәкләр ясап чыгабыз. Аннан түгәрәкләп җәябез. (Юканың үз уклавы да була икән! Аны юкә агачыннан 50 сантиметр озынлыкта ясыйлар, токмач уклавыннан шактый кыскарак ул. Лира апа безгә дә шундый уклау бүләк итте. Ә сез, нинди уклавыгыз бар, шундыйны куллана аласыз.)

Җылытып майланган табага әзер җәймәне салабыз да утка куябыз. Флера апа духовка янында мәш килә. Юка пешерер өчен духовканың өске уты да, аскы уты да янарга тиеш. Өске утны сүрәнрәк тотарга кирәк, артык кызу янса, юканың өсте каралып китәргә мөмкин.

Күмер төште, мич тә әзер.

Лира апа кисәү белән күмерләрне тигезләде дә, беренче юкалы табаны табагач белән ялкынга куйды. Чыжлый! Лира апа әледән-әле табаны әйләндереп тора. 7-8 минуттан юкалар әзер дә булды. Юкаларны зур куна тактасына берәм-берәм тезә барабыз. Аслы-өсле куярга ярамый. Һәр юка аерым-аерым тезелеп ятарга тиеш! Тик беренчеләре түгел! Духовкада пешкәнен дә, мичтән чыккан беренче юканы да, авыз итәбез, дигән булып, «ялт» иттердек! Икесе дә искиткеч тәмле булган!

Юка мәзәге:

Берәү кунакка килгәч, аш белән дә, бәрәңге белән дә юка ашый да, юка ашый икән. Хуҗа хатын, кунакның болай ашавын күзәтеп торган да, башкаларга юка калмас дип борчылып, әйтә куйган: «Габдрахман, син ипи дә капкала инде». Кунак юка ашавын дәвам итеп: «Әй, юканы да ашап бетереп булмый әле монда», – дип җавап биргән, ди.

Лира апа тагын мич каршына басты. Табагач мич белән ике арада йөреп тора, күзне кызыктырып куна тактасына юкалар тезелеп бара. Юка пешерә-пешерә Лира апаның бит алмалары алланып чыкты! Мичнең ялкыны сүрелмәсен дип, берәм-берәм утын атып торабыз. Апалар кулында юка бик тәмле һәм җиңел генә пешә кебек тоелса да, четерекле яклары күп аның. Күмере дә, ялкыны да кирәк, мич тә кызу булсын, юка да янмасын, пешеп тә җитсен. Юканы пешергән саен киже-мамык тастымал белән табаны сөртеп алабыз. Ә менә учак күмере әләккән юкалар – иң тәмлесе!

Кунак ашларында табынга юка ипи киселгән тәлинкә өстенә өчәр-дүртәр итеп куеп чыгарыла. Юканы беркайчан да кисмиләр, башта икегә, аннан дүрткә бөкләп сындырып ашыйлар. Йоласы шундый! Гадәттә, болай итеп эшләүне, юканы «каплыйбыз» дип атыйлар. Юка белән чәй дә эчәләр, токмач ашын да ашыйлар, катык белән дә бик тәмле була. Юка тәмен югалтмый, пакетта озак сакларга мөмкин аны.

Чәй артында юканың тарихы турында да гәпләшеп алдык. Юка пешерергә кем кайнанасыннан өйрәнгән, кемгә энисе өйрәткән. Аны күпләр пешерә белә, ә менә тарихы ничегрәк, каян килеп чыкканлыгы турында иң көчле версия әтинеке булып чыкты:

– Үзбәкләрнең наны, әрмәннәрнең лавашы бар. Саный китсәң, күп халыкның юкага охшаш ризыгын атап булыр иде. Бу ризыклар барысы да, беренче чиратта, ипи ролен үти. Җиңел әзерләнә, тиз пешә. Кырда эш вакытында, өчдүрт пулән утын ташлап, учакта пешереп алган юка кайчандыр бабайларның төп ризыгы булган дип фаразласак та дөрес булыр...

Күпереп пешкән юкалар белән чәй эчү тәмле дә, күңелле дә. Икенче юлы, менә шулай җыелышып, мич кабартмасы пешерәбез дип килештек. Ә Лира апа: «Иртәгә кунакка барасы бар, кайткач тагын юка пешерәм әле, кибет күчтәнәче алып йөрисем юк», – дип, Флера апа: «Минем дә оныкларга юка пешерәсем бар», – дип, өйләренә ашыкты.

Юка рецепты:

1 литр сөт, 7 данә йомырка, 250 г сыек май, 100 г чүпрә, он, бер чеметем тоз, шикәр комы.

1. Җылытылган сөткә шикәр комы, чүпрә, йомырка, май, тоз, он кушып, арка тирләгәнче камыр басабыз. Аннан камырны җылырак урынга куеп, «күзе ачылганчы» кабартабыз. Берәр сәгать камырның күпергәнен көтәбез.

2. Камыр әзер булгач, 13-14 кисәккә бүләбез һәм һәрберсен 3-4 см калынлыкта түгәрәкләп җәябез. Әзер түгәрәкне җылытып майланган табага салабыз да утка куябыз.

3. Юканы мичтә дә, духовкада да пешерәләр. Кая пешерсәк тә, бер үк төрле камыр кулланыла.

Юка пешерер өчен духовканың өске уты да, аскы уты да янарга тиеш. Өске утны сүрәнрәк тотарга кирәк, артык кызу янса юканың өсте каралып китәргә мөмкин.

4. 8-10 минуттан юкалар әзер була. Юкаларны зур куна тактасына берәм-берәм тезә барабыз.

Юкагызның тәме татулы булсын, йөрәккә ятулы булсын!

Флера апа.

Үзбәкләрнең наны, әрмәннәрнең лавашы бар. Саный китсәң, күп халыкның юкага охшаш ризыгын атап булыр иде.

Лира апа.

Сатуда бәя иректе

ИНДЕКСЫБЫЗ– 16987

Әлфия Бикмөхәммәтова фотосы.

Кадерле укучыларыбыз!

Кошлар канатында туган якларыбызга кабат яз килде. Язның үз ямьнәре, үз гамьнәре, үз мәшәкатьләре. Язның күңелле ыгы-зыгысына бирелеп, «Түгәрәк уен»га язылырга онытып җибәрмәгез тагын.

Исегезгә төшерәбез: икенче яртыеллык өчен матбугатка язылу дәвам итә. «Түгәрәк уен»га республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә дә язылырга мөмкин. Безне МАП (Межрегиональное агентство подписки) каталогыннан эзләгез.

Индексыбыз –16987. Ярты елга язылу бәясе – 294 сум 03 тиен.

Бергә булыйк!